1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**

№ 4 / 2023


СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



110





СӨЕМБИКӘ

110

Елъязма

Без бүген: «Журналыбызны яратып, җан җылысын кушып эшлибез!» – дип кабатларга яратабыз. Алар, ягъни бездән алда килгәннәр дә шулай эшләгән... Араларында репрессияләргә дучар булганнар да бар... Төрмә салкынлыгы, гаделсезлекләр кичерүчеләр дә... Исемнәре аклану шатлыгын күтәреп алучылар да... Журнал кызыклы, файдалы булсын, укучыны уй-гамьнәргә салсын дип иҗат газапларында янганнар... «Сөембикә» журналы битләре әнә шулай тарихка кереп барган... Менә хәзер безгә шушы фотосурәтләрдән карап торучы шәхесләр аша «Сөембикә» бүгенге көнгә килеп җиткән. Кыйбласын да, максатларын да югалтмаган!
Бу сәхифәбез – кайчандыр журналыбыз өчен җан атып яшәүчеләр хакында.

«Сөембикә»нең беренче саны чыгуга быел 110 ел була! 1913 елда ул нәкъ менә «Сөембикә» исеме белән нәшер ителә башлый, революциядән соң «Азат хатын» дип үзгәртелә, ә аннан соң кабат үз исеменә – асылына әйләнеп кайта.




Рәсемдә: Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов, Асия Бикжанова, Саимә Ибраһимова, Кояш Тимбикова. 1960 ел.











Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
«Сөембикә». Графика.
Бакый Урманче. 1976 ел.

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 112 бит

Басарга кул куелды: 31.03.2023 ел.
Чыгу көне: 10.03.2023 ел.
Заказ С-0871
Тираж 8166

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

















Баш мөхәррир сүзе



Безнең команда белән якыннанрак танышу өчен:



Кадерле укучыбыз!

Безгә – 110! Тышлыгыннан ук игътибар иткәнсездер, бу санybыз үзгә – анда журналыбызның бүгенгесе тарихыбыз белән бергә үрелеп бара. «Сөембикә»нең үткәне, моңа кадәр чыккан саннары – редакциябезнең иң зур байлыгы!

Үткәннәр дигәннән. Редакциябездә 1958–1961 елгы приказлар кенәгәсе саклана. Ул кәгазь битләре инде шактый саргайган... Әмма машинкада басылган юлларны укыганда күз алдыннан тулы бер чор уза. Журналның, сугыш башланып 17 ел тукталып торганнан соң, яңадан чыга башлаган чагы бу. Баш мөхәррир Асия Хәсәнова яңа коллектив туплый: журналистлар Асия Бикжанова, Роза Хафизова, җаваплы сәркатип Рашат Гайнанов, рәссам Тимур-Булат Җәгъфәр... Көн саен яңа боерык! Эшкә алу, командировкаларга җибәрү, төрле районнарга журнал укучылар белән очрашуларга бару... Тышлык төсләре дөрес чыкмау белән бәйле приказ да бар. Хаталар өчен шелтәләр дә күренгәли...

Менә тагын берсе. «Редактора юношеско-детской литературы Таткнигоиздата тов. Ибрагимову С. И. перевести на постоянную работу в качестве литературного сотрудника в журнал «Азат хатын». Үзебезнең Саимә апа лабаса бу! Бераздан боерыкның яңасы күзгә чалына: «...тов. Ибрагимову С. И. считать находящейся в декретном отпуске...» Әйе, шулай, соңгы көненә – 95 яшенә кадәр редакция белән элемтәсен өзмәгән Саимә апаның да япь-яшь чаклары булган. Алар да нәкъ безнең кебек журнал дип җан аткан. Матур гаиләләр дә корган. Шулар янына тормышның мең төрле мәшәкате дә кушылган...

Приказлар кенәгәсен ябам да, бүгенге көнгә кайтам. Нейросеть әнә рәсем ясый, яза (хәтта шигырьләр дә!), төрле катлаулы сорауларга җавап бирә, зәңгәр экраннан һава торышы турында сөйләүче матур кыз кыяфәтенә керә... Тиздән журналистларны да нейросеть алмаштырачак дигән фаразлар күренгәли башлады... Булмас! Сез безнең бүгенге коллективыбызга гына күз салыгыз. Мондый талантлы, тырыш, креатив, күзләре янып торган, «Сөембикәне» яраткан (!) кызларны нинди нейросеть алыштыра алсын ди?!

Бәйрәмебез белән һәммәбезне!

Яратып, Лариса МАЛИКОВА



Фото: Алсу Opale

Заман һәм без

1913–1918 еллар 6

«Ак пәлтәлеләр» 10
Чулпан Галиәхмәтова

1926–1941 еллар 14

Кем белер кадерләрем? 21
Лилия Гәрәева

1958–1977 еллар 22

Гади химия түгел бу... 26
Алсу Шакирова

1977–1988 еллар 30

1988–2000 еллар 36

Татар дөньясы

Язмыш шәхесләрне нигә аямый?! 40
Тәэминә Биктимирова

Безнең лауреатлар 44

Их, буем аз гына озынрак булса... 48
Гөлнур Сафиуллина

2000–2009 еллар 52

Сахалинның кояшы 56
Алсу Шакирова

2009–2017 еллар 64

18



Тынлыкны тыңларга яратам
Чулпан Галиәхмәтова

34



Ләйсән абыйсының алдында үсте
Алсу Шакирова

60



Авыл мулласы
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш

Хыялларым – мөлдерәмә 68
Халисә Мөдәррисова

И чабата, чабата... 70
Марат Әмирханов

Китап уку – дөньяны аңлау 77
Мансур Гыйләҗев

2018–2019 еллар 78

Мәхәббәтем аңа булышсын!.. 82
Динә Насыйрова

Яшәеш

Син өйрәткәнчә яшибез, әни! 88
Эльмира Закирова

Себернең зәңгәр күзе 100
Алсу Шакирова

Хуҗабикә

Сорау–җавап 104

Сүзсез сөйләшү 106

Күзләрне ачабыз 107

92




Бәхет өчен күп кирәкми...
Гөлнур Сафиуллина

96



9 нчы катта, күрше бүлмәләрдә...
Эльмира Закирова


108



Тутырган каз муены
Рамил Хафизов тәкъдим итә

»

1913–1918 еллар


Ягъкуб Хәлили

Татар хатын-кызлары өчен чыгучы «Сөембикә» журналына журналист Ягъкуб Хәлили нигез сала. Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында туган ул. Үзләренең атаклы мәдрәсәләрендә белем ала, аннан шунда ук мөгаллим булып эшли. Нәни улларының үлемен күтәрә алмыйча, аның беренче хатыны вафат була. Нәкъ шул вакыт, патша хөкүмәте кушуы буенча, Иж-Бубый мәдрәсәсе туздырыла. Эшсез калган Ягъкуб хәзерге Яшел Үзән районының Акъегет авылы мәдрәсәсендә укыта башлый. Иркутск шәһәрендә дүрт кибет тоткан Заһидулла бай Шәфигуллинның туган авылында салдырган мәдрәсәсе була бу. Себер баеның кызы Әсма туташны исә мөгаллим Ягъкуб Хәлилинең бер-бер артлы кичергән хәсрәтләре тетрәндерә. Заһидулла хаҗиның уңган, чибәр кызына өйләнергә теләүчеләр шактый була, ә ул Ягъкубның сүз дәшүен көтә... Матур гаилә кора алар. Әсма иренең фикердәшенә, һәр эшендә беренче ярдәмчесенә әйләнә.

Ягъкуб Хәлили «Сөембикә» журналын Әсманың бирнә акчасына чыгара. Икесенең дә максаты бер була: татар хатын-кызларының дөньяга карашларын, фикерләрен үстерү, күңел офыкларын киңәйтү.

Журнал ул вакытта аена ике тапкыр чыга. Барлыгы 115 саны дөнья күрергә өлгерә. Кызганыч, инкыйлабтан соң 1918 елда «Сөембикә» ябыла – илнең яңа хуҗаларына ошамый, күрәсең.

Ә Ягъкуб Хәлили тормышында, еллар узгач, «Сөембикә» журналы кабат калкып чыга әле. 1937 елның 4 декабрендә аны «халык дошманы» дип кулга алалар. Аңа ягылган гаепләр арасында «буржуаз «Сөембикә» журналы искелек яклы реакцион көчләрне эшче сыйныфның революцион хәрәкәтенә мобилизацияләгән» дигән юл да була.

1938 елның 6 гыйнварында инде, «өчлек» карары белән, Ягъкуб Хәлилине атарга дигән хөкем чыгаралар.

Ягъкуб Хәлили Казанның Архангел зиратында җирләнгән.


Әсма туташ Шәфигуллина, Ягъкуб Хәлилинең булачак хәләл җефете

Ягъкуб Хәлили турында уку өчен:



١٥نچی محرم ١٣٣٢سنه. ١نچی دیکابر ١٩١٣سنه.



قزان «معارف» مطبعه‌سی ١٩١٣یل.

№ 3 1-го Декабря, 1913 г. 1-й годъ изданія.

ЖЕНСКІЙ ЖУРНАЛЪ

„СЮЕМЪ-БИКА“

روسیەدە بردن برگنە بولغان هم دورت یلدن بیرلی دوام ایتوب کیلە طورغان
کولکی ژورنالی

„یالط یولط“

غە 1914نچی یل ایچون آبونە دفتری آچلدی.

«یالط ـ یولط»نڭ بهاسی:

بر یلغە ٢٤ نومیر ٣ صوم یارطی یلغە ١٢ نومیر ١ صوم ٥٠ تیین
چیرك یلغە ١ صومدر. برەملەب ١٢ تییندر.

آدریس: Казань. ред. журнала „ЯЛТЪ-ЮЛТЪ“.

„آق یول“

سویوکلی بالالرینە ملی تربیە بیرورگە تلەگان آتا ـ آنالر دقتینە.

کونلرمز ـ اوقو کونلری مونی عر کم بلە، هر کم آڭلی. بالاسی بولغان آتا ـ آنا بالاسن اوقوتا. لکن اوقو بلەن تربیەنی بر ـ برسی بلەن صاتاشدرماسقە کیرەك. بالانی تربیە ایتو، آڭا ملی روح کرتو، اوزینڭ خلقن سویدرو، یارلی، مسکین ویتیملرگە بالانڭ کوڭلندە محبت ومرحمت اویاتو، باشقەلر بلەن یوموشاق وگوزەل معاملەگە اویرەتو، شفقتلی آتا هم نفیس ادبیات ورچیدر. دیمك کوب آتا ـ آنالرنڭ اوزلری تییشنچە تربیە آلماغانغە، حاضرگی زمان بالالرینڭ کوب سواللرینە جواب بیرودن عاجز بولسەلردە، عجب توگل. دیمك، بالالرنی تربیە بابندە بزم «بالالر ادبیاتی»نە زور احتیاج کورونە. مونە، ملتمزدەگی کیمچیلکنی کوروب، سویوکلی ملت بالالرینڭ ملی، دینی وادبی تربیە آلولرینە اهمیت بیرو نیتی ایلە، بالالرغە مخصوص «آق یول» اسملی ژورنال چغارا باشلاغان ایدك. «آق یول» اوزینڭ بای مندرجاتی، بالالر اوچون کوڭللی ونفیس رسملری هم منتظم وقتندە چغوب طورووی بلەن تاتار وحتی روس مطبوعاتینڭ دقتن جلب ایتدی. تاتار دنیاسندە بالالرغە مخصوص بردنبر بولغان اوشبو ژورنالنی مذکور ایکی مطبوعاتڭ ایکیسیدە القشلاب قارشی آلدی. ملی مطبوعاتمزنی قوەتلاب باروچی آتا ـ آنالر مونی اوزلریدە کورگانلر، دیب اویلیمز. «آق یول» کبك مهم ونفیس بر ژورنالنی بالالرینە آلوب بیرو، اوز بالالرن سویگان و آلارنڭ تربیەلرینە اعتنا ایتکان هر بر آتا ـ آنانڭ بورچیدر.

بهاسی بر یلغە ٤ صوم، یارتی یلغە ٢ صوم ٥٠ تیین؛ اوچ آیغە ١ صوم ٣٥ تیین بر نومیری ٢٠ تیین.

ناشر ومسئول محرری: فخر الاسلام آگییف.

آدریس: Казань. номера Музурова редак. „АКЪ- ЮЛЪ“.

Казань, электро-тип. „МААРИФЪ“. 1913 г.

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР

Кадерле дуслар!

«Сөембикә» журналын нәшер итүчеләрне, редакция коллективын, авторларын һәм журналны укучыларны – барыбызны да яраткан журналыбызның 110 еллыгы белән чын күңелдән тәбрик итәм! Халкыбызның дәрәҗәсен һәм үзаңын күтәрү, милләтебезнең иминлеген ныгыту, хәтта санын арттыру, милли яшәешебезнең ямен һәм гамен саклау хакына куйган олы хезмәтегез өчен ихлас рәхмәтебезне юллыйм.

«Сөембикә» журналы 110 ел дәвамында халкыбыз белән бергә төрле заманалар, авыр сынаулар һәм хәлиткеч үзгәрешләр кичерде. Әмма ул беркайчан да үз кыйбласын һәм әһәмиятен югалтмады, чөнки бу дөньяда тормыш җебе – хатын-кызлар кулында, димәк, алар мәнфәгате һәрчак игътибар үзәгендә булырга тиеш. Журналның бүген дә, милли рухиятебезне саклап, яңа, заманча мәгънәгә ирешеп нәшер ителүе – татар халкының олы казанышы дип саныйм. Һәр санында кешелекнең мәхәббәт, гүзәллек, ана булу, игелек һәм шәфкать кебек мәңгелек хәзинәләрен чагылдыра торган башка басма юктыр, мөгаен. Шуңа күрә сөекле дә, сөйкемле дә ул безгә!

Борынгы көнчыгышта: «Ир бала тәрбияләсәң – ир-ат тәрбиялисең, кыз бала тәрбияләсәң – милләт тәрбиялисең», – дигәннәр. Халкыбыз яшәешен лаеклы дәвам итәргә сәләтле буыннар тәрбияләү – гомуми бурычыбыз, әлбәттә. Әмма тәрбияләү-өйрәтү сәләте хатын-кызның табигатенә үк салынган. Балага ана сөте белән керә торган төп хәзинәләребезне, шул исәптән, ана телебезне күздә тотып әйтәм. «Тел – ананың баласына иң кадерле бүләге» дип юкка гына әйтми безнең халык. Шуңа күрә без бирeдә хатын-кызларыбызга аерата зур өметләр баглыйбыз. «Сөембикә»нең һәр санын башыннан ахырынача укып баручы тугры укучыгыз буларак, журналның хәзерге вакытта төп вазыйфасын шунда күрәм һәм әлеге юнәлештә үтемле һәм эзлекле эшләвегезгә сөенәм.

Гасырлар буена хатын-кызның гүзәл һәм серле образы меңәрләгән иҗади чагылыш тапкан, ләкин барыбер нидер әйтелми-язылмый, нидер сурәтләнми калган кебек тоела. Бу мәңге шулай булачак, чөнки хатын-кыз матурлыгының, уңганлыгының һәм игелегенең чиге юк. Сезгә әлеге асыл сыйфатларны дөньяга чыгару юлында яңа иҗади ачышлар һәм уңышлар телим.



Минтимер ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасының Беренче Президенты



Журналның һәр санын ачыш тулы хәзинә сандыгына тиңләр идем. Һәркем өчен ачык һәм аңлаешлы тел белән, күңелләргә үтеп керерлек итеп язылган тормышлар, иң каты бәгырьлеләрне дә эретерлек тылсымлы каләм көче бар анда. Һәр битендә яңалык, тарих төпкелендә сакланып калган серләр, яралы язмышлар, бүгенге көннең героена тиң хатын-кызлар, ерак кыйтгаларда милләтен, динен һәм гореф-гадәтләрен онытмыйча яшәүче татарлар, һәркемгә ярдәмгә омтылучы фидакарь җаннар, ахырга кадәр сере ачылып бетмәгән хатын-кыз галәме – болар бар да журнал битендә генә басылып калмыйча, күңел түрендә «әнә ничек икән» дигән уй-фикергә күчеп, һәркемнең язмышын үзеңнеке итеп кабул итәргә этәрә.

Балалар китап укымый дигән бу заманда да журналны һәр әдәбият дәресенә алып кереп, нинди дә булса бер рубрикасы белән менә дигән кызыклы дәрес үткәреп чыгам. Саф татарча, камил тел белән язылган җөмләләр эченә бары матурлык, киләчәккә өмет, булганына шөкер итә белү, язмышка буйсыну яки аны үзең буйсындыру кебек сабырлык сыйфатлары сеңдерелгән.

Зөбәрҗәт ФАТЫЙХОВА.
Балтач районы, Салавыч мәктәбе.


Фото: арт-группа Явь

САНКТ-ПЕТЕРБУРГТА «АК ПӘЛТӘЛЕЛӘР»ГӘ ҺӘЙКӘЛ КУЙГАННАР. БАШСЫЗ МАНЕКЕНГА КИГЕРТЕЛГӘН АК ПӘЛТӘДӘН ГЫЙБАРӘТ УЛ. АНЫҢ ҖИҢНӘРЕ, ТЫНЫЧЛАНДЫРУ КҮЛМӘГЕ КЕБЕК, АРТКА БӘЙЛӘНГӘН. БУ ЭШЛӘРЕН АВТОРЛАР ИКЕЙӨЗЛЕЛЕККӘ ҺӘМ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘДӘГЕЛӘРДӘН ҮЗЛӘРЕН ӨСТЕН КУЙГАННАРГА БАГЫШЛАГАН. ТИК АРТ-ОБЪЕКТ БЕР КӨННӘН ЮККА ЧЫККАН.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«Ирең хыянәт иткәнгә үзең гаепле, тота белмәдең, ә менә мин...», «Син нинди күлмәк кидең, мин моны киеп ишегалдына да чыкмас идем», «Ничек бала төнлә йокламасын инде, режим гына кирәк, ә мин баламны...», «Хәзерге яшьләр өметсез инде, ә менә без яшь чакта....», «Ничек инде син мөселман булып яулык япмыйча йөрисең, ә менә минем балалар...» Килешерсез, шушындыйрак «киңәшләр» бирергә яратучыларны еш булмаса да, очратканыгыз бардыр. Алар, әйтерсең бу гөнаһлы җиргә төшкән ак фәрештәләр. Фәрештә булу-булмаулары бәхәсле анысы, әмма андыйларны «ак пәлтә киючеләр» дип йөртәләр. Тормышыбызда социаль челтәрләр бик зур урын алып торган чорда мондый киңәш бирүчеләр аеруча күбәйде һәм дөньяда яңа диагноз туды. Дөрес, рәсми медицина әле аны танымады, әмма ул популярлашты.

«Ак пәлтә» феномены кайдан килеп чыккан? Бәлки, һәрберебез дә «ак пәлтә кию»дән кыенсынып тормыйдыр...

«АК ПӘЛТӘЛЕЛӘР»

«Ак пәлтә» феномены

Бу күренеш кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле булса да, аңа исем күптән түгел һәм очраклы гына бирелә. Барысы да интернет-мемнан башлана. Гомере буе оппозициядә булган совет диссиденты, сәясәтче Валерия Новодворскаяның плакат тотып төшкән фотосы интернет челтәрләрендә тарала. «Сез барыгыз да ахмаклар һәм дәваланмыйсыз! Бер мин генә акыллы һәм ак пәлтәдән матур булып басып торам» дип язылган була анда. Әлеге сүзләрнең кемгә адресланганы билгеле түгел, әмма Россия сәясәтчесенең пальто төсе шундук феноменга әйләнә. Баксаң, җәмгыятьтә бер Новодворскаяга гына мондый уйлар килми икән бит. Моны раслар өчен әңгәмәдәшеңне игътибар белән тыңлау йә социаль челтәрләрдәге шәрехләмәләрне уку да җитә. Бу синдром – күпләребездә, әмма аны үзебездә танырга гына теләмибез. Кара булса күрер идең, ә ак төсне күреп булмый шул. Аны башкалар күләгәсендә генә күрә аласың. Ап-ак итеп! Андыйларны әле д'Артаньяннар да дип йөртәләр. Яшьләр арасында популяр булган җырда да шундый сүзләр бар бит: «Бар кешеләр дә кешеләр төсле, ә мин – йолдыз». Хәер, ничек дип исемләсәң дә, җисемнәре бертөсле кала. «Акпәлтәлелек» ул – кемнеңдер проблемасын югарыдан торып гаепләп, үз бәяңне күтәрү. Уңышка ирешү формуласын теләсә кем сөйли алган хәзерге чорда интернет киңлекләрендә, гомумән, «ак пәлтәлеләр» армиясе барлыкка килде.

«Ак пәлтә»дән булган кеше камил булып тоела. Камиллегенә үзе дә ышана. Аның балалары һәрвакыт сүз тыңлый, ире авызына гына карап тора, менә дигән хуҗабикә дә, бервакытта башы да авыртмый, кәефе дә китми, бизнеста да уңышлы, һәрнәрсәне хәл итү юлын белә һәм... һәрвакыт хаклы. Ул ирен читләре белән генә елмаеп сөйләшә, вакыт-вакыт үзе дә сизмәстән күзләрен зурайтып ала. Аның бар кыяфәте: «Син инде лаек түгел, ярар соң, өйрәтермен, сөйләрмен», дип әйтә кебек. Әмма ул авызын ачып сөйли башлауга, хисләреңне һәм эмоцияләреңне юкка чыгаруын, бары үзен яхшы яктан күрсәтергә тырышуын гына аңлыйсың. Килеп туган проблеманы хәл итү кыяфәте чыгару – ул аның битлеге генә. Чынлыкта, үзенең өстенлеген тоеп, канәгатьлек хисе аласы килә (бәлки, сезнең хисаптан акча эшлисе дә). Шуның өчен «ак пәлтә киючеләр» сорамасаң да, «кыйммәтле киңәшләрен» бирә башлый. Ә сезгә ул киңәш кирәкме, юкмы, бу хакта уйлап та тормыйлар. Тел төбеннән шунысы да аңлашыла: сез очраган хәлгә беркайчан да юлыкмаячаклар, чөнки алар акыллырак. Һәм иң кызыгы шул: «ак пәлтә киючеләр» җәмәгатьчелеккә бары тик аклык, дөреслек, яхшылык таратуларына, шәп киңәш бирүләренә чын күңелдән ышаналар.



Психология фәннәре магистры, арт-терапевт, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева: «Ак пәлтәлеләр»гә энергиягезне сарыф итмәс өчен иң яхшы чара – аларга игътибар итмәү».

Мин-минлек

– Бу күренеш аралашу этикетында урынсыз, – ди аралашу культурасы һәм этикет буенча тренер-консультант Марина Шәмсетдинова. – Мөгамәлә үзара хөрмәттә корылырга тиеш. Ә «ак пәлтә киючеләр» яхшылык теләүче битлеге артында әңгәмәдәшен хурлау, аны түбәнсетү теләген качыра. Гаепләү дә сизелә, янәсе, менә син минем кебек ак пәлтә кия алмыйсың, чөнки син аны тиз арада пычратачаксың, ә мин бервакытта да синең хәлгә төшмәячәкмен. «Ак пәлтә киючеләр» иң беренче чиратта үзләрен күрсәтергә тели. Пьедесталда алар гына, һәм бөтен игътибар аларга гына булсын. Этикетка өйрәнү яхшы манералар гына алу дигән сүз түгел, уй-фикер дә чиста булырга тиеш. Әйләнәтирәдәгеләргә карата хөрмәт булмаса аралашу культурасына өйрәнеп булмаячак, андыйлар бары «ак пәлтәлеләр» булып калачак.

Реаль тормышта мондый синдромлы кешеләр бераз тыелып торырга мөмкиннәр әле, ә социаль челтәрләр алар өчен менә дигән мәйдан. Анда ирек, анонимлык, җавапсызлык... Төрле битлек киеп карый, тискәре сыйфатлары булган якларын күрсәтә ала. Шуңа шәрехләмәләр язып рәхәтләнәләр генә. Әле җавап та бирсәләр, зур җиңү яулагандай, тагын да кызып язалар һәм виртуаль дөньяда үзләрен маякка санап яши башлыйлар.

– Социаль челтәрләремдәге аккаунтымда төрле фикерләр укырга туры килә, – ди телевизион алып баручы, блогер Гөлназ Сәфәрова. – Мыскыл итәм дип язучылар да, чын-чынлап үзләренчә борчылып киңәш бирүчеләр дә бар. Соңгыларына хөрмәт белән карыйм. Ә инде «акыл өйрәтүчеләргә» берничек тә игътибар итмим, язалармы-язалар: миңа барыбер. Бары тик рәхмәт дип кенә язып куям. Үзеңне әллә кемгә куеп йөрү гадәте, нигездә, биш тиенлек кешеләрдә була ул. Даһи шәхесләргә килешә әле ул,



Илсөя БӘДРЕТДИНОВА,
Татарстанның атказанган артисты

Әгәр дә кеше ниндидер эшне миннән яхшырак эшләп күрсәткән, аннан үрнәк алырлык икән, миңа карата булган искәрмәләрен кабул итәм. Ә менә ул өлкәдә берни аңламаган кеше нидер өйрәтә башлый икән, әйдә, күңеле булсын дип тыңлыйм инде, әмма сүзләренә колак салмыйм.

Социаль челтәрләрдәге аккаунтымда язган шәрехләмәләрне балама тәрбия биргәндә кулланам. Урта яшьләрдәге ир-ат язган «сезнең авызыгыз зур» дигән сүзләрне малайдан укытам. «Беркайчан да хатын-кызга менә болай итеп язма», – дим. Миңа ул ир-атның нәрсә язуы барыбер. Ә менә ул үзенең ир-ат түгеллеген күрсәтә. Нормаль ир атна уртасында эш сәгатендә социаль челтәрләргә кереп, хатын-кыз белән булышып утырамы инде, йә?

Минем гомер ике түгел, хәл итәсе проблемаларым күп, киңәш, фикер сорамыйлар икән, эндәшмим. Бервакытта да! Кемгәдер фикерем кызык булса, кайбер чакта алдан гафу үтенеп, әйтәм. Мин әйткән сүз ошамаска да мөмкин бит. Әмма мин ничек уйлыйм, шулай әйтәм. Кемгәдер яраклашырга тырышып, үзеңнең фикерең белән тәңгәл килмәгән фикергә баш кагып утырыр яшьтән чыккан инде мин. Ә кеше белән булышырга яратканнар шуннан тәм табадыр, мөгаен. Минем берничә шундый язылучым бар. Шәхси тормышлары бөтенләй юктыр, чөнки көннәре минем тормышым белән уза. Нәрсә кигәнемне, кая барганымны тикшерәләр. Алар, гомумән, минем турында миннән күбрәк белә. Кайчагында рәхәтләнеп көлә-көлә укыйм. Язсыннар, әйдә. Реаль тормышта аралашкан вакытта дорфа гына бәяләп куялар икән, шундук үземә сабак алам. Болай әйтергә ярамый дип күңелемә сеңдерәм.

кичерелә дә, алар бит нәрсәдер эшләгән, тырышкан, уңышка ирешкән. Андыйларга сокланасың гына. Итагатьле, тәрбияле, белемле һәм акыллы кеше беркайчан да масаеп йөрмәячәк инде.

Сизгәнсездер, «ак пәлтә киючеләр»гә тәкәбберлек, масаю сыйфаты хас. Ә бу – ислам динендә иң зур гөнаһларның берсе. Дини китаплардан укып беләсездер, шайтан да бит оҗмахтан тәкәбберлеге өчен куылган. «Мин – уттан, адәм балчыктан яралган. Ут балчыктан яхшырак», – дип, Аллаһы Тәгалә кушса да, Адәм галәйһиссәламга сәҗдә кылмаган.

«Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте нәрсәгә төшкәнен беләбез, шуңа күрә дә бу феномен диндә булырга тиеш түгел. Әгәр дә кеше дини кануннар буенча яши, Аллаһы Тәгаләдән курка икән, димәк, иң хәерле кеше. Бу хакта хәдис тә бар. Ул кеше телен тыя, күп сөйләшми, чөнки һәр гамәле өчен җавап бирәсен белә. «Гаиләбездә бер апа дин юлына кереп китте дә, хәзер аның белән очрашырга да куркабыз, ул безне гел орыша», – дип әйтүчеләр бар. Бары яхшылык кына теләсә дә, ул апаның да гамәле тәкәбберлек булып саналырга мөмкин, шуңа күрә дә хикмәт белән матур итеп вәгазь укый белергә кирәк – куркытып, түбәнсетеп түгел. Имамнарыбызның вәгазьләрендә тәкәбберлек юк бит», – ди «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин. Димәк, дин буенча да «ак пәлтә кию» гөнаһ булып чыга.

Феноменның тамырлары

«Ак пәлтә» – «акыл саткан» шәрехләмәләр авторы, минминлекле кешеләрнең бер сыйфаты гына түгел, ул психологик феномен. Шуңа да аны аңлау мөһим. Ни өчен «ак пәлтә» киябез? Әле бит җәмгыятьтә һәр кеше үз фикерен белдерергә хаклы дигән язылмаган канун да яши. Тик кайчак үз фикере белән ул башкаларның шәхси чикләренә үтеп керергә мөмкин. Соңгы вакытта психологиядә шәхси чикләр турында күп сөйлиләр. Шуны аңларга кирәк, ул ниндидер тренд йә замана модасы түгел, аның нигезендә гап-гади әдәп-әхлак ята. Димәк, бу феномен тәрбиясезлектән килә. Әмма тәрбиясезлек тамыры кайда? Үз-үзен бу рәвешле тоткан кешеләр комплексларга бай түгел микән?

– Күпләрнең ишеткәне бардыр: башкалардагы ниндидер бер сыйфат ачуыбызны китерә икән, димәк, без аны үзебездә кабул итә алмыйбыз. «Ак пәлтә» феномены барлыкка килүнең бер сәбәбе шул, – ди психология фәннәре магистры, арт-терапевт, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева. – Моннан кала, үзеңдә ышаныч булмау, негатив эмоцияләреңне дөрес күрсәтә белмәү, җавапсызлык, төрле комплекслар да китереп чыгара бу синдромны.

Белгеч фикеренчә, үзен бик әһәмиятле итеп тоярга теләгән кешеләр «ак пәлтә кия», чөнки күңел төпкелләрендә үзләрен бәяләнмәгән кеше дип саныйлар. Шуңа күрә дә сорамаган киңәшләрен биреп, файдалы кеше булуларын җәмгыятькә, ә иң элек үз-үзләренә расларга тырышалар. Үзенә ышанычы булмаганнар да күзгә күренмәгән пәлтә кия. Башкаларны нәрсәгәдер өйрәткәндә, үзләрен укытучы итеп тоялар да, шул рәвешле үзбәяләрен күтәрәләр. Бу синдромга ия булганнар өчен үзен һәрвакыт башкалар белән чагыштырып тору мөһим. Һәм ул күпкә өстен торырга тиеш. Шул вакытта гына канәгатьләнү хисе булачак.

«Ак пәлтә» балачак травмалары белән дә бәйле булырга мөмкин», – ди психолог. Ягъни балачакта күргән түбәнсетелүләр, кадерсезләнүләр, кабул итмәүләр тор-

мышта башкалар хисабыннан үзбәяңне арттырырга мәҗбүр итә. Әти-әни тәрбиясе кеше тормышында мөһим роль уйный. Аларның мөнәсәбәте, әйткән сүзләре гомергә истә кала.

Чынлыкта, бу кешеләр бик бәхетсезләр. Беренчедән, һәрвакыт камил булып күренергә тырышып йөрү бик авыр эш. Икенчедән, «актан киенүчеләрне», ни дисәк тә, җәмәгатьчелек кенә түгел, якыннары да яратып бетерми. Аны «яхшы түгел» дип кенә кунакка чакырырга, бер сүзен ишетмәсәләр дә, әдәп саклап, тыңлаган кыяфәт чыгарып утырырга мөмкиннәр. Ә күпчелек очракта аралашудан качачаклар. Кемнең инде һәрвакыт түбәнсетелеп, сорамаган киңәшләрне тыңлап торасы килсен!

Шунысы да бар: һәрвакыт «ак пәлтәдән йөрүчеләр» үсештән туктап кала. Камиллеккә чикләр юк дигән гыйбарә бар. Үзебезгә тәнкыйть күзлегеннән чыгып караганда гына үсештә булабыз. Мотивация булып, һәрвакыт алга омтылганда гына кеше кызыклы шәхес була ала. Ә инде үзен камил дип санаган кеше үсүдән туктый.



Ландыш ӘБҮДӘРОВА,
язучы, журналист

Сорамасалар да, үз фикерен белдерергә, ул фикерне эталон итеп тагарга, бәхәстә соңгы сүз итеп калдырырга тырышу сыйфаты нәселдән килгән очракларны күзәткәнем бар. Ягъни моны әр-яңа күренеш дип уйламыйм. Андый «персонажлар» элек һәр авылда булган, аларның балалары белән бергә уйнап үстек. Балаларында да «ак пәлтәлек» сизелә иде. Нәкъ шулар, безне оештырып, бер команда итеп туплап йөртте дә инде. Ошамаса да, аларның сүзләренә колак саласың, күңелне тырнаса да, кабул итәсең. Хәтта берзаман эчке тавыш аларның тавышы белән кисәтә башлый да, кыласы гамәлләреңне, әйтәсе сүзеңне җиде кат үлчәп, бер кат кисә башлыйсың...

Хәзер «ак пәлтәле»ләрнең мәйданы башка: алар виртуаль дөньяда. Ул тәкәбберлекнең үзенә бер чагылышы, дияр идем. Ә бүген тәкәбберлек «уңышка ирешкән кеше» феноменының бер компоненты, атрибуты (гәрчә гел алай булмаска да мөмкин), шуңа да җәмгыятьтә ул кискен каршылыкка очрамый.

Бер караганда, «ак пәлтәлеләр» әйләнә-тирәдәге мохитне тәртиптә тоту өчен үзләре теләп, сакка баса. «Ак пәлтә кигәч», аны чиста, пөхтә итеп сакларга да кирәк, ә бу, блогерлар, инфочегәннәр яраткан төшенчә белән әйткәндә, «үз өстеңдә нык эшләүне» таләп итә. Өстәвенә, тагын да уңганрак, булдыклырак «ак пәлтә»леләр табылып тора. Андыйлардан бер генә нәрсә коткара: битарафлык, соралмаган киңәшкә җавапсыз калу. Хәтта әнә шул җавапсыз калу аларны чыгырыннан чыгара: ул бит «ә менә мин...» дип, үзен күрсәтмәкче иде... Шуннан ак пәлтәне күзәтү кызыклы бер уен төсен алырга мөмкин. Гәрчә бу синдромның да башка бер исеме бардыр әле.

Әңгәмәдәшегезнең «акыл сатарга» керешүен аңлыйсыз икән, тыныч кына, дустанә атмосферада «миңа бу сөйләшү кызык түгел», дип әйтергә киңәш бирә психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева. «Акпәлтәлеләр»гә энергиягезне сарыф итмәс өчен иң яхшы чара – аларга игътибар итмәү. Онлайн форматта, билгеле, бик җиңел: йә җавап бирмисез, йә бу кешене «кара исемлек»кә кертәсез. Ә җанлы сөйләшү вакытында игътибар итмәү авыррак. Сөйләшү урамда икән, гафу үтенеп, тизрәк китү ягын карый аласыз, бинада булса, эш табып, башка бүлмәгә чыгып китү хәерле. Тәрбиягез моны эшләргә ирек бирми икән, «сүзсез сөйләшү» дә бар бит әле. Вербаль булмаган сигналлар җибәрегез: телефон алып карыйсыз, колакчыннар киясез, күзләрегез белән кемнедер эзлисез... Һәм тагын бер алым – сөйләшү барышында әңгәмәдәш белән һәрвакыт килешеп, баш кагып тору. Әмма «ак пәлтә» бер генә киңәш бирер дә туктар дип уйлап ялгыша күрмәгез.

Мондый әңгәмәдәш, гадәттә, бәхетле, үзеннән, тормышыннан канәгать булганнарның ачуын чыгармый. Алар тыңлаган кыяфәт чыгара йә бу сөйләшүгә нокта куя. Әгәр дә инде аның сүзләре күңелегезгә тиеп, үзегезнең хаклы булуыгызны үҗәтләнеп расларга тотынасыз икән, моның сәбәбен аңларга тырышыгыз. Бәлки сез дә бүген «ак пәлтәдән»дер?!

Белгеч киңәше

«Ак пәлтә» «киеп» йөрүчеләрнең биш билгесе бар. Тикшереп карагыз әле, үзегез, йә якыннарыгызда юкмы алар?

- **Сорамаса да, үзләре турында сөйлиләр. Аларга моңа кадәр сүз нәрсә турында барганы бөтенләй мөһим түгел.**
- **Гаепләүне киңәш бирү битлеге астына яшерәләр. Гадәттә, аларның киңәше «ә мин сезнең урында булсам...» сүзләре белән башлана.**
- **Башкаларның тәҗрибәсен юкка чыгаралар.**
- **Барысы да кешенең үзеннән тора дип саныйлар. Барып чыкмый икән, димәк, тырышмый. Үзенең уңышсызлыклары булса, тышкы факторлар гаепле, шәхси сыйфатлары түгел.**
- **Үзләренең бары яхшылык кына теләвенә ышаналар, чөнки башкаларның хисләре турында уйламыйлар, бөтен игътибары үзләрендә.**

1926–1941 еллар


Гөлчирә Гафурова

«Иптәш Азановага, А. Сәйфигә, Ибраһимовка, Мансуровка, Фатыйх Сәйфигә 21 ноябрь көнне, чәршәмбе көнне сәгать икегә, өлкә комитетына, 7 нче бүлмәгә татар крестьян хатын-кызлары өчен журнал чыгару комиссиясе утырышына килергә».

Татарстан партия архивында саклаган чакыру бу (фонд – 15, дело – 315, 301 нче бит). Монда сүз безнең «Азат хатын» журналын оештыру турында бара. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Секретариаты карары нигезендә «Азат хатын» 1926 елның август аенда чыга башлый. Журналның исемен «Кызыл Татарстан», «Крестьян газетасы» һәм «Яңалиф» журналы баш мөхәррире Фатыйх Сәйфи-Казанлы тәкъдим иткән дигән фараз бар.

Басма СССРда яшәүче барлык татар хатын-кызлары арасында таралуны, аларның иҗтимагый аңын күтәрүне максат итеп куя. Беренче һәм икенче саннарын чыгарганда штатта әле бер кеше дә булмый – редколлегия имзасы белән генә чыга. Өченче саннан башлап редакциягә секретарь булып үткен каләмле журналист, талантлы шагыйрь, оста оештыручы Һади Такташ килә. 1927 елның июль санына журналның беренче редакторы Ш. Кәримова кул куя. 1928–1931 елларда Ш. Азанова мөхәррирлек итә. Коллектив зурая, әкренләп редакциягә танылган журналистлар, язучылар туплана. Стахановчылык хәрәкәте киң колач алган чак бу. Язмаларның һәркайсы диярлек шуңа чакыру белән башланып китә.


Мәрзия Шахмаева

1931–1937 елларда редакцияне Гөлчирә Гафурова җитәкли. Тарихка ул Һади Такташның беренче мәхәббәте булып кереп калган. Алар ничә еллар бер бүлмәдә, кара-каршы утырып эшлиләр. Әмма Гөлчирә шагыйрьгә шундый ук хисләр белән җавап бирә алмый... Журналыбыз тарихында Гөлчирә Гафурованың исеме күз яшьләре белән язылган. «Халык дошманы» исемен күтәрә ул, төрмә юллары аша уза... Сигез елын ГУЛАГта, ун елын сөргендә уздыра. Ике кызы әнисез үсә... 1937–1941 елларда журналны Рокыя Әхмәтшина җитәкли. «Күренекле әдипләребез Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Мирсәй Әмир, Әхмәт Исхак, Гали Хуҗиев, Габдрахман Әпсәләмов, Гази Кашшаф, Сәхаб Урайский үзләренең каләмнәре, кирәкле киңәшләре белән редакциягә күп ярдәм иттеләр», – дип яза ул үзенең истәлекләрендә. Сугыш башлангач, журнал чыгудан туктый.


Шәмсия Кәримова, Һади Такташ, редколлегия әгъзасы Насыйров, Гөлчирә Гафурова.

Гөлчирә Гафурова турында уку өчен:



ئازادهاتن

6



Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

Азат Хатын

№ 12 июнь 1941



Татар Дәүләт опера һәм балет театры тарафыннан куелырга хәзерләнә торган „Алтынчәч“ операсыннан бер күренеш.

Мясников фотосы.

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР



Фәрит МӨХӘММӘТШИН, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе

Кадерле хатын-кызларыбыз!

Сезне «Сөембикә» журналының күркәм юбилее белән ихлас күңелдән тәбрик итәм.

Моннан 110 ел элек нәшер ителә башлаган журнал милләтебез хатын-кызлары белән бергәләп озын һәм гыйбрәтле юл узды. Халкыбыз кичергән барлык вакыйгалар – канлы инкыйлаб, колхозлашу чорлары, Икенче бөтендөнья сугышы, Бөек җиңү, җимерелгән илебезне яңадан торгызу, үзгәртеп корулар, ватаныбызның яңа тарихын яза башлау – боларның барысы да хатын-кызларыбыз язмышлары аша журнал битләрендә чагылыш тапты. Гасырдан артык инде әлеге басма гүзәл затларның өстәл китабы, киңәшчесе, сердәше, дусты булып тора.

Һәр заманның үз геройлары була. Бүгенге көндә хатын-кызларыбызның җәмгыятьтә тоткан роле аеруча зур. Алар – иң элек ана. Илебез киләчәге бүгенге аналар, алар тәрбияләп үстергән балалар кулында. Кешелекнең төп кыйммәтләре балага ана сөте аша керә, ана тәрбиясе аша сабый күңеленә салына. Гасырлар дәвамында формалашкан милли тәрбия, күркәм гореф-гадәтләр гаиләдә саклана һәм киләчәк буыннарга тапшырыла. Гаиләнең тоткасы – хатын-кыз.

Гүзәл затларыбыз үзләрен төрле тармакларда оста белгечләр, талантлы оештыручылар итеп танытты. Мәгариф, медицина, социаль өлкә булсынмы, катлаулы җитештерү тармагы яисә фән дөньясындамы – кайда да хатын-кызларыбыз яңа үрләр яулый.

Инде елдан артык илебез тормышында катлаулы вакыйгалар бара. Безнең халыкка хас булмаган кыйммәтләрне кертергә теләгән дус булмаган илләр белән халыкара алышта хатын-кызларыбызның тоткан ролен, башкарган эшләрен аеруча зур хөрмәт белән атап үтәсем килә. Алар – «Сөембикә» журналының геройлары – ятим балаларга җан җылысын биргән аналар, ташландык җирләргә җан өреп гөлбакча үстергән, фермер хуҗалыклары һәм башка җитештерү тармаклары, халыкка хезмәт күрсәтү объектлары ачып, матур итеп эшләп ятучы кыю кызлар, алгы сызыкта булганнарга ярдәм итү өчен хәйрия чаралары оештыручы тәвәккәл ханымнар, тормыш иптәшләрен махсус хәрби операциягә озатып, балалар өчен, ирләре башлаган эшләрне алга алып бару өчен бөтен җаваплылыкны үз өсләренә алган башимәс хатыннар...

Журналда шактый вакытлар чыгып килгән «Ут күршеләр» проектына да аерым игътибар юнәлтәсем килә. Төрле халыкларның милли рухын, яшәү рәвешен чагылдырган әлеге кушымта Татарстанда гомер итүче йөз җитмештән артык милләт вәкилләре арасында дуслыкны, татулыкны ныгытуга зур өлеш кертә. Республикабызның, илебезнең көче – татулыкта!

Кадерле «Сөембикә»леләр!

Халкыбызның телен, мәдәниятен, барлык асыл сыйфатларын саклап калу нисбәтеннән башкарган эшләрегез өчен сезгә зур рәхмәт! Барчагызга нык сәламәтлек, гаилә иминлеге, иҗади уңышлар телим. Журналның һәр санын көтеп алучы дусларыгыз һәрвакыт сезнең белән булсын!



osta_bordo_bika «Һәр язмагызны кат-кат укыйбыз! Шулкадәр тәмле итеп чыгарасыз журналны! Башкортстанда яшәүче әтием: «Сөембикәне» укып күңел генә түгел, тән дә туя», – дип әйтергә ярата. Шуны әйтергә кирәк, әти укып чыкмыйча, журналга беребез дә тотынмыйбыз. Ярамый! Шуңа икешәр сан алдырабыз! Искиткеч бердәм, тату гаиләләр хакында укып киләчәгебез өчен өмет уяна. Фәһемле язмаларыгыз, зирәк сүзләрегез өчен зур рәхмәт сезгә, хөрмәтле «Сөембикә»леләр!»

БЕЗНЕҢ ХАКТА — СОЦЧЕЛТӘРЛӘРДӘ

ТЫНЛЫКНЫ ТЫҢЛАРГА ЯРАТАМ

ТЕАТРДА КЕЧЕ СӘХНӘНЕ ЯРАТАМ. Анда аура көчле. «Подвал театр»да иҗат итеп яту һәр режиссёрның, актёрның хыялыдыр ул.

Режиссёр булырга укыдым, әмма ул теләк хәзер юк. Һәрнәрсә өчен талант һәм интуиция кирәк. Айдар Җаббаровның эшләгәнен карыйм да, болай эшли алмас идем, дим. Булдыра алмагач, нигә тотынырга инде?! **ҺӘР ҺӨНӘР ИЯСЕНДӘ ҮЗЕ ДӘ АҢЛАТА АЛМАГАН ТОЕМЛАУ, СИЗЕМЛӘҮ БАР.**

«Син уйнаган спектакльгә килдек тә, театрга йөри башладык», – диләр миңа кайчак. **АКТЁР ӨЧЕН ҖИҢҮ МЕНӘ ШУЛ УЛ.** Тамашачының шушы сүзе миңа иң дәрәҗәле театр белгече сүзенә караганда да кадерлерәк.

Бүген театрда җитлеккән чорым. Күп әйберләрне аңлый башладым. Кайбер рольләремне яңадан уйнар идем. Мәсәлән, «Мулла»дагы Әсфәндиярне. **ҺӘР РОЛЬ ӨЧЕН ӨЛГЕРЕРГӘ КИРӘК ИКӘН.**

Айдар Җаббаров белән эшли башлагач икенче сулышым ачылды. Тормышымда яңа бер этап башланды. Айдар белән туктаусыз иҗат итеп була. Борылышлар белән эшләве, көтмәгәндә спектакльне бөтенләй үзгәртеп атуы канымны кыздыра. Мин аны аңлыйм, тоемлыйм. **РЕЖИССЁР БЕЛӘН АКТЁР БЕР-БЕРСЕН АҢЛАМАСАЛАР, БЕРНИ КИЛЕП ЧЫКМАЯЧАК. ЭШЛӘҮ ПРОЦЕССЫ ҖӘФАГА ӘЙЛӘНӘ.**

Образны тудырыр өчен бөтен җанымны-тәнемне биреп эшлим. Аның өчен яңа һөнәр өйрәнергә кирәк дисәләр, аны да үзләштерәм. «Рәшә» спектакле өчен репетитор ярдәмендә – саңгыраулар алфавитын, «Көл» өчен барабаннарда уйнарга өйрәндем. Үземә карата таләпләрем бик зур. **БЕРКАЙЧАН ДА ҮЗЕМНӘН КАНӘГАТЬ БУЛГАНЫМ ЮК.** Әйе, мин аннан интегәм, әмма ул мине үсешкә алып бара.

Эшли башлагач, әти белән әнине «Бәби» спектакленә чакырдым. Карагач, юньләп бер сүз әйтмәделәр. Татар халкы тыйнаграк бит инде ул, ярылып, чәчелеп мактау дигән нәрсә юк анда. Алар хәзер минем белән горурланадыр инде. Әти белән әни алдында бик яхшы артист буласым килә. Иң саллы тәнкыйтьчеләрем алар. Әти-әнием, туганнарым, хатыным спектакльгә билет сатып алып килә икән, уем гел залда. Әмма мин аларны кертеп утыртмыйм, игътибар күрсәтә алмыйм. Бәлки, үпкәлиләрдер дә. Мин алардан гафу үтенәм! Эш процессым шундый инде. **ҺӘР СПЕКТАКЛЬГӘ ПРЕМЬЕРАГА ӘЗЕРЛӘНГӘН КЕБЕК ӘЗЕРЛӘНӘМ.**

БЕРЕНЧЕ ОСТАЗЫМ – ӘТИЕМ. Әти Казан янындагы Кадыш бистәсендә гомере буе татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләде. Сәнгатьне яратты. Җырлый да, рәсем дә ясый, шигырьләр дә яза. Беренче җырларны, шигырьләрне әти өйрәтте. Мәктәптә укыганда ул алып барган драмтүгәрәккә дә йөргән идем.

УРАМДА ТӘРБИЯЛӘНГӘНГӘ ДӘ САМИМИЛЕК ЮГАЛМАГАНДЫР УЛ. Безне өйгә ашарга гына чакырып алалар иде. Урамның үз кагыйдәләре бар иде. Аннан соң авыл тәрбиясе дә ихласлык бирә. Балачакта җәйге каникулларны Мамадыш районы Ташлык һәм Яңа Комазан авылларында үткәрдек. Табигать искиткеч ул авылларда. Мин аларны Татарстан Швейцариясе дип атыйм.

САЙЛАУ МӨМКИНЛЕГЕМ БУЛСА, АКЧА БУЛМАГАН ИЛДӘ ТУАР ИДЕМ. ЛӘКИН АНДЫЙ ИЛ ЮК.

Җирдән мәхәббәт фәрештәсе куылган кебек. Кирәксезгә әйләнгәндер ул. Сүз ир белән хатын мәхәббәте турында гына түгел. Табигать белән элемтә дә, бер-береңә карата игътибарлы булу да мәхәббәт. Хәзер фаҗигагә ис китми башлады бит. Тыңлыйсың да ике минуттан соң ук онытасың. **КЕШЕЛЕК ВӘХШИЛЕККӘ, ХӘВЕФ-ХӘТӘРГӘ КҮНЕКТЕ БУГАЙ.** Әйтерсең лә җирдә мәхәббәткә урын калмаган кебек. Ә бит мәхәббәтсез адәм баласы яши алмый.

Адәм баласы бер дә акыллы түгел инде ул. Акыллы булса, гасырдан-гасырга бер үк хаталарны кабатламас иде. **ВАКЫТЛАР ГЫНА ҮЗГӘ, КЕШЕ ҮЗГӘРМИ.** Аны бары нәфес җиңә икән.

УСАЛЛАНА БАРАМ. Кунык җыям бугай. Миндә гаделлек хисе бик көчле. Аңлыйм: ул хис белән мин монда беркемгә кирәкмим. Шуннан өзгәләнә башлыйм, ачуым чыга.

Бу дөньяда Аллаһы Тәгаләгә ышанмасаң бөтенләй яшәп булмас иде. **ЫШАНЫЧТАН БАШКА ЯШӘП БУЛМЫЙ.** Ул булмаса, кеше бу дөньядан китү юлын эзли, йә югалып кала. Ышанасың икән, Аллаһы Тәгалә калдырмас әле дисең, һәм ул калдырмый да.

ТУГАН ТЕЛНЕ БЕЛМӘҮ – НАДАНЛЫК. Без балаларыбыз өчен җаваплы. Телен белмәгән бала үзенең кем икәнен белмәячәк. Кеше үз нәселен белеп, шәхес булып формалаша. Һәр җан иясенең нәселе бар.

М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган артисты, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актёры Эмиль ТАЛИПОВның тормыш кагыйдәләре



Фото: Анна Арахамия

ТЕАТРЫБЫЗНЫҢ ЗУР ВАЗЫЙФАСЫ – МИЛЛӘТНЕ САКЛАП КАЛУ. Татарлыгыбыз шул театрларыбыз, сәнгатебез тирәсендә генә бит инде. Бездә милли музыка уйный, үз язучыларыбызның әсәрләрен куябыз, үз телебездә сөйләшәбез. Килгән тамашачы шуларны ишетеп китә дә, милли әсәрләребезгә тартыла. Булганы бетмәсен иде дигән курку хисе бар безнең тамашачыда.

Кеше хәзер табигатьтән ерагая. Карагыз, балаларны ничек саклыйлар. Комлыкта уйнарга ярамый, җиргә кагылырга ярамый. Табигатьтә йөрмиләр, соклана белмиләр, бары телефонда утыралар... **КЕШЕ ТАБИГАТЬТӘН, БЕРБЕРСЕННӘН ЕРАКЛАША ИКӘН, АНЫҢ КҮҢЕЛЕ САЕГА.** Иң шәп ялым – табигатьтә йөрү. Вакытны уемда теркәп калдырырга тырышам. Берәр матур җир күрсәм, бик озак аны төшемдә күрәм.

МИН БЕР СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ ДӘ ЮК, Ә МЕНӘ УРАМДА ЙӨРЕП, КЕШЕЛӘРНЕ КҮЗӘТӘМ. Бу минем һөнәрем өчен дә кирәк. Кечкенә чакта абзыйлар капка төбенә чыкса, шулар янына килеп утыра идем. Шуңа күрә һәр өлкән кеше хәтеремдә уелып калган.

ТЫНЛЫКНЫ ТЫҢЛАРГА ЯРАТАМ. Иртә белән тынлыкны гына түгел, үз-үзеңне дә тыңлыйсың кебек.

Иҗади кризисларда барыбер булдырам дигән үҗәтлек алга барырга ярдәм итә. Урамда тәрбияләнгәч, югалып кала торган кеше түгелмен. Элек төшенкелеккә бирелә идем, хәзер юк. Тыл бар. Илсөяргә рәхмәт, тынычландыра. Кызым Зифа, улым Хәким турында һәрвакыт уйлыйм. Мин аларның этиләре, минем өчен оялырлык булмасын, дим. **МИН – ГАИЛӘ КЕШЕСЕ.** Зифа туганда локдаун иде, хатыныма балабызны карарга ярдәм иттем. Кызым белән бик якынайдым. Ул бик кирәк икән. Хәзер менә Хәкимне рәхәтләнеп карашам. Күтәреп йөргәндә аңа җырлар җырлыйм, сүрәләр укыйм. Улым белән кызыма бик бәйләнгән мин. Алар көч бирә. «Син – бәхетле кеше», – диям үземә.

Авыр вакытта яшибез дияргә яратабыз. Әмма безнең башка вакыт юк. **БЕЗ ШУШЫ ВАКЫТТА, ШУШЫ КӨНДӘ ИҖАТ ИТӘРГӘ ТИЕШ.**

Картаю театрда бик тиз күренә. Кеше сүлпәнләнә башлый, темпы, уйнау манерасы үзгәрә. Сәхнә хәрәкәтчәнлек ярата бит ул. Картаюдан курыкмыйм үзе. Картлык – акыл җыйган чак дип әйтү үзеңне юату гынадыр. Ул – гомер ахырына җитү. **КАРТЛЫК ТЫНЫЧ КИЛСЕН ӨЧЕН МАТУР ИТЕП ЯШӘРГӘ КИРӘКТЕР. НӘФЕСЛӘНМӘСКӘ, КЕШЕ РӘНҖЕТМӘСКӘ.** Ул вакытта әҗәлдән дә курыкмыйсыңдыр дип уйлыйм. Аллаһыга ышанган, матур яшәгән кешене бакыйлыкка күчү куркытмыйдыр...

«Мәхәббәт FM» спектаклендә ничәмә егет йөргән кызларына тәкъдим ясады, яңа парлар кавышты. Кем өчендер гомер буена кадерле спектакль булып калачак.

УЛ ДӨНЬЯГА КҮПМЕ ПАКЬЛЕК, МАТУРЛЫК ӨСТӘДЕ. СӘНГАТЬ ШУНДЫЙ БУЛЫРГА ТИЕШТЕР ИНДЕ УЛ.

Абсолют бәхетле булып булмый. Бәхетнең тәме, кадере мизгел булуында гына. Гомер шикелле. Ул да мизгел генә бит. Әгәр дә бетми торган булса, мәгънәсе, тәме булмас иде. **КЕШЕНЕҢ БӘХЕТЕ – БУ ДӨНЬЯГА КИЛЕП КИТҮЕНДӘ.**

СПЕКТАКЛЬ ТӘМАМЛАНЫП, БАШ ИЯРГӘ ЧЫККАЧ, ӨСКӘ КАРАП АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ РӘХМӘТ ӘЙТӘМ. Бу – минем ритуалым.

Тамашачы театрга бушанырга килә. Әгәр дә ул спектакльне караганда бушана алмый икән, канәгать булмыйча кайтып китә. Эмоцияләрен чыгара икән, аңа ошаячак. Спектакль карап, ул үзен тикшерә кебек. **АКТЁР, РЕЖИССЁР, ТАМАШАЧЫ АДӘМ БАЛАСЫНЫҢ ТАБИГАТЕН КҮЗӘТӘ, СОРАУЛАРЫНА ҖАВАП ЭЗЛИ.**

Үземне тугры кеше дип әйтә алам. Бу минем урам тәрбиясеннән дә, гаилә тәрбиясеннән дә киләдер, мөгаен. Дусларым, танышларым белән мөнәсәбәтләрне дә ахыргача кадәр сакларга тырышам. Иҗат кешеләре гашыйк булучан дигән фикер штамп кына ул. Һич алай түгел! Якыннарымның гаиләсе таркалса, алар өчен бөтен барлыгым белән борчылам. **МӘХӘББӘТ – УЛ ТОРМЫШ КЕБЕК, БЕРДӘНБЕР БУЛА.** Илсөяр белән без – җандашлар. Бертөрле уйлыйбыз, бер-бер артлы бер үк фикерләрне әйтәбез. Һәрбер гаиләдәге кебек бездә дә аңлашылмаучылыклар булып ала, әмма ул безне якынайта гына.

Минем хатыным хыялый. Ул хыял белән яши. Шуңа да яратам мин аны. Андый кеше белән рәхәт. Бергәләп хыялланыбыз. Безне ул да берләштерә. **ХЫЯЛЛАНА БЕЛГӘН КЕШЕ АЛГА ТАБА ОМТЫЛА, ҖЫЛЫЛЫК, БӘХЕТ, ЯКТЫЛЫК КӨТӘ.**

Бернәрсә дә җиңел бирелми. Тормышның рәхәте дә – булганны саклауда. **АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ БИРГӘН БӘХЕТКӘ ТЕЛӘСӘ НИЧЕК КАРАРГА ЯРАМЫЙ.**

ИҖАТ КЕШЕСЕ СЕРЛЕ БУЛЫП КАЛЫРГА ТИЕШ. Фокусның да бит ничек күрсәтелгәнен аңлатырга ярамый, алайса кызыгы бетә. Театрда экскурсия уздырганнарын да яратмыйм, чөнки сере югала. Кеше бит могҗизага, тылсымга ышанып яши. Ә театр күпләр өчен сер дөньясы ул. Мин аны хәтта гыйбадәтханә дип әйтер идем. Анда чистарынасың, тормышыңны читтән карыйсың, үз-үзең белән ялгыз каласың.

ТАМАШАЧЫМ БУЛГАНГА БӘХЕТЛЕ МИН. Ул сине кабул итсә, сине яратып спектакль карарга килсә, шул тамашачы белән бергә җитлексәң, картайсаң... Шуннан да бәхетле актёр юктыр.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.



КЕМ БЕЛЕР КАДЕРЛӘРЕМ?

Гүзәл ХИСМӘТУЛЛИНА, олылар һәм балалар психологы, гештальт-терапевт

Мин нәрсә генә эшләсәм дә, ирем күзлегеннән караганда, кирәксез, гел юк-бар белән генә шөгыльләнәм булып чыга. Мәсәлән, мин бакчада казынырга бик яратам, ләкин ирем өчен бу кирәксез бер эш. «Кибеттән сатып алу арзангарак төшәчәк», – ди. Өй җыештыру, идән юуларны да «кычытмаган җирне кашу», дип кенә бәяли. Берәр планым белән уртаклашсам, җавабы бер генә – «барыбер булдыра алмыйсың, тотынма да!» Башкалар янында бәямне төшерә бит әле. Аның шул сүзләреннән соң үземне бер булдыксыз, уңмаган кеше итеп тоя башлыйм. Эшкә дә күңел үсми хәзер. Иремнең гел тәнкыйтьләп торуы, тырышлыгымны күрмәве мине хатын-кыз буларак тәмам юкка чыгара. Егерме ел бергә яшәп, аның бер генә эшемне дә мактаганын ишеткәнем юк дисәм дә ялган булмас. Мондый мөнәсәбәтне туктатасым килә, ләкин ничек итеп? Нурания Х. Буа районы.

– Берәү икенче бер кешенең эш-гамәлләрен, хисләрен, казанышларын кирәксезгә санап, аның мөһимлеген киметә икән – димәк, ул аның бәясен төшерергә тырыша булып чыга инде. Русча моны «обесценивание», диләр.

Бер-береңне гел тәнкыйтьләп тору, гаеп табу гаиләдә җылы, матур мөнәсәбәтләрнең булмавын күрсәтә. Ирең гел тәнкыйтьләп кенә торса, эшеңне килештермәсә, билгеле, хатын-кызга бик авыр. Күп очракта хатын-кыз үзен гаепле итеп тоя башлый. «Чынлап та мин дөрес яшәмимдер, дөрес эшләмимдер. Моны эшлисе булмагандыр», – дип, ире алдында гел акланырга тырыша, һәрбер төртмәле сүзне күңеленә йотып, гаиләне таркатмыйм дип, үз эченә бикләнеп яши башлый. Безне кечкенәдән гаилә мөнәсәбәтләрен сакларга кирәк, хатын-кыз түзәргә тиеш дип өйрәтәләр. Гаиләдәге җылы мөнәсәбәтләр – ике кешенең бер-берсенә карата булган игътибарына, ихтирамына, хөрмәтенә нигезләнгән берлек ул. Бер генә кеше тырышып, мондый мөнәсәбәтләрне булдырып булмый.

Ни өчен ир кеше үзе яраткан хатын-кызның бәясен төшерергә тырыша? Ни өчен хатын-кыз моңа юл куя? Кыз баланы кечкенәдән гел ачуланып, оялтып, үзен гаепле тояргa өйрәтеп тәрбияләләр икән, үскәч, аның үз-үзенә бик түбән бәя куюына, кәефе башкаларның аны үсендереп, мактап торуына бәйле булуга һич аптырыйсы юк. Мондый кызлар мөстәкыйль тормышта да әнә шундый манипуляцияләргә тиз бирелә. Якын кешегез сезне тиешенчә бәяләми, эшләгән эшегезнең кыйммәтен төшерә, кадерсезли икән, димәк, аны манипулятор дип әйтергә җирлек бар. Сез нәрсәгә генә тотынсагыз да, ирнең канәгатьсезлеге, хатынын килештермәве, кайчак хәтта күрә алмавы, мин-минлеге, агрессиясе алгы планга чыга. Мондый ирләрне нарцисслар дим мин. Гаиләдәге властьны үз кулларында тоту, үзен көчле итеп күрсәтү, үзен яхшырак итеп таныту өчен ул янындагыларны – бу очракта хатынын кимсетә, түбәнсетә, аның эшләренең мөһимлеген бетерә. Кайбер хатын-кыз иренә караганда уңышлырак була. Андый хатын-кыздан ир-ат көнләшергә, аны конкурент итеп күрергә мөмкин. Хатынының бәясен төшерү бәрабәренә ул үзенең абруен күтәрергә, үзен мөһимрәк кеше итеп күрсәтергә тырыша.

Мондый мөнәсәбәтләрдә хатын-кызга нишләргә? Иң беренче кагыйдә – акланмаска. Аклану ул – гаебеңне тану. Ә бит сезнең гаебегез юк. Шулай булгач, берничек тә акланмагыз. Икенче кагыйдә – манипуляторның гаепләүләренә игътибар итмәскә өйрәнегез. Сүзләрен йөрәккә артык якын алмагыз. Сез бит инде сабый бала түгел, ялган белән дөреслекне, хис белән фактларны аера белергә кирәк. Бәхәсләшмәгез. Акланып, бәхәсләшеп, энергиягезне генә сарыф итәсез. Мондый сөйләшүләрдән качарга тырышыгыз. Сезнең үзегезчә уйлап, үзегезчә эшләргә хакыгыз бар. Башкалар фикеренә бәйлелектән котылырга кирәк.

Әгәр ирегез бүтән мәсьәләләрдә сезнең таләпләргә туры килә икән, аның бу гадәтенә бер кимчелек итеп кенә карагыз. Сез бу кешене ни өчендер яраткансыз, аның матур сыйфатларын күргәнсездер бит. Алар хәзер юкка чыкмагандыр лабаса. Ирегезнең яхшы якларына күбрәк игътибар итеп, аны күреп, мактап, рәхмәт әйтеп, ике арадагы мөнәсәбәтләрне җайларга була.

Ирегезгә хис-кичерешләрегезне белдерегез. Әйткәнемчә, «мин – хәбәр» ысулын кулланыгыз. «Син шулай әйтеп торганда, үземне кадерсез итеп тоям. Миңа авыр бу сүзләрне ишетү», – диегез.

Әгәр дә сезгә чынлап та бик авыр булса, ирегезнең сүзләренә үртәлеп, кимсенеп яшәсәгез, белгечләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Шунысын белеп торыгыз: үзегезнең бәягезне үзегез белмисез икән, аны беркем дә белми. Үзбәягезне күтәрү өстендә эшләгез.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

1958–1977 еллар



Татар матбугаты өчен истәлекле ел бу. Унҗиде ел туктап торганнан соң, 1958 елның гыйнварында 10 мең тираж белән «Азат хатын»ның сугыштан соңгы беренче саны чыга. Аны яңадан торгызуны Татарстан партия обкомы талантлы журналист һәм оста оештыручы Асия Фәрит кызы Хәсәновага тапшыра.

Язучы-журналистлар арасында: «Асия Хәсәнова ачтыра алмаган ишек юк», – дигән легенда әле дә йөри. Ул аны егерме ел (1958–1977) буе раслый. Журнал үз йөзен таба. СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче татар халкы арасында бик тиз таныла. «Азат хатын»ны тарату, читләргә таныту өчен редакция коллективы ниләр генә эшләми! (Үзләре нибары 5 кеше!) Илһам Шакиров бригадасы Урта Азия якларына гастрольгә җыена икән – аларга журнал тоттырып җибәрәләр. Себергә китүче галимнәр дә, Балтыйк илләренә баручы туристлар да үзләре белән «Азат хатын»ны алып бара. Тираж күзгә күренеп үсә: КПСС Үзәк Комитетының матбугат бүлеге биргән кәгазь теләгән бөтен кешене журналга яздырырга җитми башлый. Редактор бу мәсьәләне Мәскәүгә барып үзе җайлый: кәгазь табыла. «Азат хатын» бу чорда 26 битле булып чыга, язылу бәясе 1 сум 25 тиен тора.

Татарның өч талантлы кызы бер редакциядә эшләгән чор бу – Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова, Диләра Зөбәерова. Чын йолдызлык! «Азат хатын»ның иң популяр милли басма булып җитешүендә редакциядә эшләгән Хәсән Сарьян, Габдулла Шәрәфи кебек талантлы язучы-журналистларның да роле зур.

Редакция ул елларда «Кызыклы очрашулар» клубы оештыра. Шәһәребезнең «Ёлочка» кафесында узган ул очрашуларга кемнәр генә килми?! Советлар Союзы Геройлары очучы Мәгубә Сыртланова, генерал-лейтенант Гани Сафиуллин, беренче татар профессионал артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская... Андагы рух соңрак журнал битләре аша укучыларга да барып ирешә.

1976 елда, 50 еллык юбилее уңаеннан «Азат хатын» СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә. Журналның иҗади коллективы өчен зур бүләк, зур хөрмәт була ул.




Редакция «Азат хатын»ның чираттагы санын планлаштыра.

Асия Хәсәнова турында уку өчен:




Азат хатын
№ 1 КАЗАН 1958



КПССның Татарстан Өлкә Комитеты республикабызның барлык хатын-кызларын иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис «Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавы белән тәбрик итә.

Коммунистлар партиясе хатын-кызларны илебездәге хуҗалык һәм культура төзелешенә тарту эшенә һәрвакыт зур әһәмият бирде.

«Азат хатын» журналы чыгу республикабыз хатын-кызларының политик һәм иҗтимагый тормышта тагын да активрак катнашуларына булышлык итәр, аларның хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшыртуда, промышленностьта, авыл хуҗалыгында, фән, культура һәм сәнгать өлкәсендә эшләүче хатын-кызларыбызның алдынгы эш тәҗрибәләрен таратуда ярдәм итәр.

КПСС Өлкә Комитеты «Азат хатын» журналы хатын-кызларыбызның иҗат инициативасын һәрвакыт күтәреп алыр, аларның хезмәт активлыкларын арттырыр, аларны югары аңлылык рухында, совет патриотизмы һәм халыклар дуслыгы рухында, коммунизм төзү эшенә турылыклы хезмәт итү рухында тәрбияләр дип ышана.

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ.



«Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавы — республикабыз хатын-кызлары тормышында зур вакыйга. Бу журнал битләрендә алар үзләренең дәүләтебез тормышында, хуҗалык һәм культура төзелешендә актив катнашуларын, хатын-кызларның төпле акылын, рухи матурлыгын, оештыру талантын һәм иҗади сәләтен күрсәткән очерклар, хикәяләр укырлар.

Безнең теләк шул: «Азат хатын» журналы татар хатын-кызларының өстәл китабы булсын. Ул аларны илебез алдына Коммунистлар партиясе куйган бурычларны үтәүгә тупласын, Ватаныбыз файдасына героик хезмәтләрен һәм тормышларын киң чагылдырсын. Тату семья кору, бала тәрбияләү, тегү-чигү, аш-су хәзерләү мәсьәләләрендә акыллы һәм файдалы киңәшләр бирсен. Без газета-журналларның артуы, журналистлар гаиләсенең ишәя баруына шатланабыз.

Журналның чыга башлавы уңае белән аның меңнәрчә укучыларын чын күңелдән котлыйбыз.

СССР ЖУРНАЛИСТЛАР СОЮЗЫНЫҢ
ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ ОЕШТЫРУ БЮРОСЫ



Кадерле иптәшләр! «Советская женщина» журналы редколлегиясе һәм аның коллективы «Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавына чын күңелдән шатлана. Чыннан да, элек коллыкта һәм изелеп яшәгән татар хатын-кызы — хәзер азат, ирләр белән тигез хокуклы, үз язмышына үзе хуҗа. Сезнең журналыгыз киләчәктә зур уңышларга ирешсен, Татарстан хатын-кызларына яңа коммунистик тормыш өчен, балаларыбызның бәхете һәм шатлыгы өчен тагын да активрак көрәшергә ярдәм итсен. Республиканың барлык хатын-кызларына сәламәтлек һәм эштә уңышлар телибез. Журналның тиражы елдан-ел артуын, хатын-кызларның үз журналларын яратуларын һәм, аңа киңәшләр белән мөрәҗәгать итеп, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавапны һәрвакыт алуга ирешүләрен телибез.

Редколлегияне һәм редакция коллективын «Азат хатын»-ның яңадан чыга башлавы белән кайнар тәбриклибез.

«СОВЕТСКАЯ ЖЕНЩИНА» журналы
редколлегиясе исеменнән:

Овсянникова, җаваплы редактор;
Муравьева, РСФСР социаль-тәэминат министры;
Дубровина, РСФСР мәгариф министры урынбасары;
Караваева, язучы.

ИКЛИБЕЗ

«Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавын чын күңелдән котлыйбыз һәм журнал редколлегиясенә уңышлар телибез.

«ҮЗБЕКИСТАН ХОТИН-КИЗЛАРИ» журналы редколлегиясе исеменнән журналның редакторы ЗӨЛФИЯ.



Бик матур эш башлагансыз. Редакциядә эшләүчеләрне һәм журнал укучыларын кайнар котлыйбыз. «Азат хатын» барлык татар хатын-кызларының яратып укый торган, сагынып көтеп ала торган журналы булыр дип ышанабыз.

Без дә аңа язылдык, көтәбез. Сезгә бүләк итеп үзебезнең «Қазахстан әйелдери» журналын җибәрәбез.

Ә. ЖӘҚЕТОВА, журналның баш редакторы.



«Азат хатын» редакциясе эшчеләрен туганнарча котлыйбыз. Зур иҗат уңышлары телибез.

«Азәрбайҗан гадыны» журналы редакторы Р. ЗӘЙНАЛОВА.



Литвадан сәлам! Татарстан республикасында хатын-кызлар өчен журналның яңадан чыга башлавы уңае белән чын күңелебездән котлыйбыз. Бу зур һәм мактаулы эштә иҗат уңышлары телибез.

ИРЕНА ПОВИЛАВИЧЮТЕ, «Тарибине мотерис» журналының җаваплы редакторы.



Татарстан хатын-кызларын «Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавы белән котлыйбыз һәм эшегездә уңышлар телибез.

«Совет Туркменистанының аяллары» журналы редакторы Г. МӘМИЕВА.



«Совет Татарстаны» газетасы редакциясе коллективы «Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавы уңае белән аның барлык работникларын, укучыларын һәм хәбәрчеләрен чын күңелдән тәбрик итә.

Коммунистик төзелеш бурычларын үтәү өчен көрәштә, безнең киләчәгебез — яшь буынны тәрбияләүдә үзләрен дан белән бизәгән совет хатын-кызларының фидакарь хезмәтләрен журнал киң һәм эзлекле яктыртыр, яңа алымнарны, алдынгы методларны пропагандалау трибунасы булыр дип ышанабыз.

«СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» редколлегиясе.



Без, татар язучылары, күп санлы укучылары күптән көткән «Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавын чын күңелдән котлыйбыз. Журналның туган көненә бүләк итеп без аңа беренче кулъязмаларыбызны — яңа шигырь, хикәя һәм очеркларыбызны китерәбез һәм ЗУР бер теләк әйтәбез: «Азат хатын» журналы безнең илебездәге азат хатыннарның үзләре кебек үк эшлекле, ачык йөзле һәм киң күңелле, бай хисле һәм тулы канлы булып яшәсен!

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПРАВЛЕНИЕСЕ.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты коллективы «Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавын чын күңелдән котлый.

Һәр төрле изүдән азат ителгән татар совет хатын-кызларының җәмгыятьтәге, гаиләдәге һәм балалар тәрбияләүдәге мактаулы эшләре журнал битләрендә лаеклы урын алыр дип ышанабыз.

ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ КОЛЛЕКТИВЫ



Хөрмәтле «Азат хатын»! Котлыйм күрше! Бүлмәләрең миңа якын булган кебек, юмордан да ерак торма. Битләреңдә һаман елмаю булсын!

«ЧАЯН»



«Азат хатын»ның яңадан тормышыбызга килеп керүе барыбыз өчен дә зур шатлык. Бу — безнең культурабыз, язучы кадрларыбыз үсә дигән сүз. «Азат хатын» журналы татар совет әдәбиятына совет хатын-кызларыннан дистәләрчә язучы талантлар үстерер дип өмет итәбез.

Эшләр уң булсын, иҗат мул булсын!

«СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» журналы



«Азат хатын» журналының чыгуын кайнар котлыйбыз. Журнал үзенең битләрендә эшче хатын-кызларның күпкырлы, бай тормышын, илебездә коммунизм төзү өчен көрәштә фидакарь хезмәтләрен киң яктыртыр дип ышанабыз.

В. И. ЛЕНИН ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ҖИТЕН КОМБИНАТЫ КОЛЛЕКТИВЫ.



Без, 14 нче төзү-монтаж тресты хатын-кызлары, «Азат хатын» журналы чыгуын чын күңелдән котлыйбыз һәм Татарстан хатын-кызларын илебездә коммунизм төзүгә туплау эшендә журналга зур уңышлар телибез.

Трест коллективы исеменнән ШАКИРОВА, ИЛЬЯСОВА, ЦВЕТКОВА, ЗӘЙНУЛЛИНА, ЗАРИПОВА һ. б.



Татар хатын-кызлары күптән көткән «Азат хатын» журналының яңадан дөньяга чыга башлавын шатлык белән котлыйбыз. Хатын-кызларны коммунистик җәмгыять төзү өчен актив көрәшкә туплауда журналга чын күңелдән уңыш телибез.

«КЫЗЫЛ ТАҢ» газетасы редакциясе.

Уфа шәһәре.



Редакция коллективын сөекле журналыбыз «Азат хатын»ның яңадан чыга башлавы белән кайнар тәбриклибез, зур иҗат җиңүләренә ирешүегезне телибез.

«ЛЕНИН ЮЛЫ» редакциясе коллективы.

Тобольск.



«Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавы хәбәрен мин шатланып каршыладым. Хезмәтчел хатын-кызлар турында шундый кайгыртучанлык күрсәтүе өчен партиябезгә чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә.

Без, хатын-кызлар, журнал битләрендә үзебезнең куанычларыбызны, кайгыларыбызны, эштәге уңышларыбызны һәм тәҗрибәләребезне уртаклашырбыз дип өметләнәбез.

Кайбыч районы, «Мәгариф» колхозы колхозчылары исеменнән Ш. ИБРАҺИМОВА.



ГАДИ ХИМИЯ ТҮГЕЛ БУ...

Алсу ШАКИРОВА

Түбән Кама шәһәренә «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесе кайтавазы алып килде безне. Һөнәрләре – язмышлары белән үрелгән, эшләре дә, үзләре дә – ел үрнәге. Нина ӘХМӘТҖАНОВА һәм Роза ЗАКИРОВАны ундүрт меңгә якын кеше эшләүче ПАО «Түбән Кама нефтехим» предприятиесендә эзләп табу кыен булмады. Үз геройларын беләләр бит. Өстәвенә, бу ханымнар икесе дә предприятиенең хезмәт ветераны! Карап торышка кызлар кебек үзләре... «Барысына да химия гаепле», – дип шаярталар әнә. Химик производствода эшләүләрен исәпкә алып әйтәләр, диярсез. Юк икән, күзгә күренмәслек бәйләнешләр, кешене дистә еллар буе җитештерүгә тартып торучы нечкә күңел кыллары турында икән сүзләре...

Күзләрең янып торса...

«Түбән Кама нефтехим»нең каучуклар һәм мономерлар үзәк лабораториясендә эшләүче өлкән лаборант Нина Әхмәтҗанова каршымда утырып, заводка килеп кергән беренче көнен искә ала. Зәңгәр күзләре балкып тора! Яшьлеген искә алганда гына түгел, сөйләшү тәмамланганчы сүнмәде ул күзләрнең яктысы. 34 ел эшләп тә, үз эшеңне шулкадәр яратырга, сокланып, таң калып сөйләргә кирәк бит!

Салават индустриаль техникумы дипломын алуга, 19 яшьлек кызларны Түбән Камага эшкә билгеләделәр. Укытучылары бу шәһәргә килеп, заводта семинарларда катнашып, шәһәрне ошатып кайта да: «Күтәрелеп килүче яшь шәһәр, яшь завод – сезнең өчен бер дигән мөмкинлекләр», – дип, кызларга хәер-фатыйхасын бирә. Балачагында баржалар өстерәүче бурлаклар турындагы «Над Камой гремит гроза» дигән китапны укып тәэсирләнгән Нина ике дә уйламый Чулман буендагы шәһәргә юл тота.



Завод бусагасын атлап кергән беренче көнен әле дә хәтерли ул:

– Кадрлар бүлегенә килдек. Күзләрен тутырып, язмышларыбыз ничек хәл ителер икән, эшкә алырлармы дип борчылып торган кызларны лабораториягә билгеләделәр. Проходнойларны узуга, шәһәр күз алдымда ачылды. Аз да түгел, күп тә түгел, үз инфраструктурасы булган шәһәр! Расписание буенча автобуслар йөри... Чисталыкка хәйран калдым: ямь-яшел чирәм, бордюрлар ап-ак итеп буялган... Лабораториягә җәяү дә, автобус белән дә бардык. Бутил каучук заводына билгеләделәр безне. Яшьләр күп! Лаборатория җитәкчесе әниләрчә җылы каршылады. Җитди, төпле булуыбызны шундук тоеп алды тәҗрибәле җитәкче. Беренче көннән үк остазлар билгеләделәр. Янәшәдә ярдәм итәрдәй, киңәш бирердәй кешең булса, эшләве дә җиңелрәк, күңелгә дә тынычрак икән. Шул чактагы мөнәсәбәтне саклап, яшь буынга биреп калдырасы иде...

Тиз эшләү, төгәллек, кызыксынучанлык, яңача эшләп караудан курыкмау, эзләнүчәнлек, сынап карау... Бу сыйфатлар яшь белгечкә ул чакта ничек ярдәм иткән булса, әле дә – төп ярдәмчеләре. Заводның көче, куәте белән бергә Нинаның осталыгы да арта. Бер этапта җибәрелгән хата алга таба нинди зур проблема китереп чыгарасын хәзер төгәл белә инде ул. Болары – тәҗрибә белән килә торган сыйфатлар. Ә менә бер-береңә ышану, белгәнең белән уртаклашу, остазлык кебек асыл





традицияләр «Түбән Кама нефтехим» оешмасында еллар, кешеләр белән сыналган, беркайчан да үзгәрмәгән. Кайчандыр куркып кына беренче пробаларын алган лаборант Нина Әхмәтҗанова бүген үзе остаз инде.

– Лабораториягә килгән яшьләр белән якын мөнәсәбәт урнаштырырга тырышам. Коллективта үзара ышаныч булганда гына алар миңа эш вакытында килеп чыккан проблемаларын, сорауларын курыкмыйча әйтәчәк. Тәҗрибә биреп калдырырлык яшьләр килүе сөендерә. Безгә килеп эшкә урнашкан бер кызны WorldSkills чемпионатына әзерләдем. Аның җиңүчеләр исемлегенә керүе минем дә зур горурлыгым, – ди Нина Михайловна.

Коллективта шундый дустанә, ышанычлы мөнәсәбәтләр булганда яңа эшләргә алынырга да куркыныч түгел. Өр-яңа галобутилкаучук цехын эшләтеп җибәргән чорны горурланып искә ала өлкән лаборант. Бөтен процесс җентекләп өйрәнелгән булса да, күләмле, җаваплы эш көтә коллективны. Төгәллеккә һич тә зыян килергә тиеш түгел. Һәр этапны сынап, артык дип санаганнарын төшереп калдырып, камилләштереп, цехны җибәрү эшен уңышлы тәмамлыйлар. Шул чакта үтә дә кыйммәтле тагын бер тәҗрибә туплана – командада эшли белү серенә төшенә Нина Әхмәтҗанова.

– Лаборатория – төп җитештерү түгел, ярдәмчел хезмәт күрсәтү өлкәсенә карый ул. Шулай да бездән башка завод җитештергән продукциянең сыйфаты булмый. Яхшы лаборант булу бар кешегә дә бирелми! Эшегез белән горурлана белегез, дип әйтәм коллегаларга да. Уйлап карасаң, синең шәхси сыйфатларың «Түбән Кама нефтехим»нең репутациясенә турыдан-туры бәйле. Таләпчән булмасаң процесс дөрес китми, сыйфатсыз продукция җитештерелә, оешмага штрафлар яный… Җаваплылык бик зур!

Ярдәмчел хезмәт дисәләр дә, кайвакыт бөтен заводның күзләре лабораториядә эшләүче кызларга юнәлә. Алар сынатмас инде, дистә еллар үзләренең осталыгын дәлилләп килгән лаборантлар эшли монда! Капиталь ремонттан соң заводны яңадан эшләтеп җибәрү чорында алыштырган җиһаз сынатмасмы соң? Тырыш кырмыскалар кебек, җитештерүнең һәр этабында кайнаша лаборантлар: чималга анализ ясыйлар, изма, катализатор әзерлиләр, этаплап колонналарны җибәрәләр. Уңай нәтиҗәне, яхшы хәбәрне бөтен завод зарыгып көтә! Ниһаять, барлык этаплар да тикшерелгән – аналитик контроль этабы буенча эш төгәл бара. Завод яңадан тулы куәтенә эшли башлый.

– Бертөрлелектән туймыйсызмы, дип сорыйлар кайчак. Кемдә ничектер, ә минә бездә беркайчан да бертөрлелек булмый. Һәрвакыт яңа материаллар килә, аларны өйрәнергә, үзләштерергә кирәк. Хәер, СИБУР белән берләшкәч, башка заводлар тәҗрибәсен дә өйрәнәбез, белгечлек даирәбез киңәя, үсәбез. Вебинарлар, яңа укулар оештыралар безгә. Төгәл саннар дөньясында башкарган вак эшебезне күрә белгән җитәкчелеккә рәхмәт! Эшче һөнәр ияләрен игътибар үзәгендә тоталар, төрле бәйгеләргә әзерлиләр, эшебезне күрсәтәләр. Җиңәбез дә бит! «Сезнең артта «Нефетехим», борчылмагыз!» – дип, ышаныч өстиләр. Бик тоябыз без ул нык җилкәне. Сезнең иңнәрдә илебезнең икътисадый иминлеге, дип үсендереп торганда ничек сынатасың?!

«Түбән Кама нефтехим»нең тагын бер матур традициясе белән бүлеште Нина Әхмәтҗанова. Кешеләргә рәхмәт әйтәләр монда! Эшең белән яхшы нәтиҗә күрсәтә алгансың икән, рәхим итеп рәхмәтен дә ишет. Кешенең күңеле булсын өчен кайвакыт эшен бәяләп, билгеләп үтү, бер җылы сүз әйтү дә җитә. Ә күзләре янып торган кеше таулар күчерергә сәләтле!

Бу – безнең кешеләр!

Роза Закирова «Түбән Кама нефтехим» предприятиесенә беренче тапкыр сигезенче сыйныфта укыган чагында килә. Әтисе Мөнәвир абый – үзе дә озак еллар шушы заводта эшләп киткән кеше – кызын Социологик һәм психологик тикшерүләр һәм анализ үзәгенә алып килеп, тест үткәрүләрен сорый. Үзе белән эшләгән

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



белгечләрне шулкадәр ошата Роза, киләчәктә үзенең кем буласын хәл итеп тә куя. Университетның соңгы курсында шушы ук үзәккә эшкә килеп урнаша да инде яшь белгеч. Сайланып тору мөмкинлеге булды микән? Әнисе дә оешманың кадрлар бүлегендә хезмәт куя. Очраклы килеп эләгү түгел, династия эшен дәвам итү булган бит!

«Түбән Кама нефтехим» – синтетик каучук һәм пластиклар чыгару буенча СИБУРның Россиядәге иң зур производство мәйданы гына түгел, һәрвакыт актив иҗтимагый тормышы белән аерылып тора ул. Башкача булу мөмкин дә түгел. Шәһәр булдыручы оешма тирәсендә Түбән Каманың төп тормышы тупланган. СИБУР белән берләшкәч, традицияләрне дәвам итеп, аларны яңа төсләр белән баетып, эшчәнлекне яңа биеклектә алып бара башлаганнар. Грантлар бирү системасы – шундый үрнәкләрнең берсе. Болай да актив тормыш алып барган Роза Закирова җиң сызганып «Формула хороших дел» программасы кысаларында проектлар эшләргә тотына. Уңыш озак көттерми. Иң беренче тәкъдим ителгән «Счастье рядом» проекты сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар тәрбияләүче әниләр белән эшләүгә юнәлгән. Бер ел эчендә утыз биш чара оештырганнар! Әниләр иҗади мастер-классларда катнаша, макияж ясарга өйрәнә, йога белән шөгыльләнә. Алар белән психолог эшли. Көне буе авыру баланы караган хатын-кызга бер генә сәгать булса да үзе өчен яшәп алу никадәр мөһим икәнен белсәгез...

Тагын бер уңышлы эше – «Вместе с мамой» проекты өч ел рәттән җиңү алып килә Розага.

– Бу проект сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларга һәм аларны үстерүче гаиләләргә, әниләргә ярдәм йөзеннән эшләнде. Балаларны экскурсияләргә алып йөрибез, бәйрәмнәр үткәрәбез, әниләр өчен дә, балалар өчен дә аерым мастер-класслар уздырабыз. Әниләребез иҗат дөньясына чумганда балалар белән волонтерлар шөгыльләнә. Безнең предприятиедә эшләүче хатын-кызлар гына түгел, бөтен шәһәрдән киләләр очрашуларга. СИБУР эгидасы белән бу чаралар тагын да матуррак уза, – ди Роза.



Оешманың HR-хезмәтендәге (кадрлар белән эшләү хезмәте) төп эше дә бар бит әле! «Безне бөтен кеше ярата», – дип сөенә ул. Эшең тулысынча кешеләргә ярдәм итүгә корылсын да, яратмасыннар инде! Эш урынында да, проектларында да зур нәтиҗәләргә ирешә Роза. Актив тормыш һәр кешенең кулыннан килгәнен аксиома кебек башкаларга да сеңдерергә омтыла. Хәтта гаиләдә мөмкинлеге чикле бала булса да...

– Бу гаиләләрнең күбесе, кызганыч, үзләренең ничек яши алганын үзләре дә күз алдына китерми әле. Мин әниләргә шуны аңлатырга тырышам. Үз эченә бикләнмәсеннәр, аралашсыннар, чараларда катнашсыннар. Минем үзем өчен дә бик зур ресурс бу. Бу эшләр белән шөгыльләнү авыр, дияр кайберәүләр. Бер эшләп карагыз әле, сезгә дә ошаячак. Моңа кадәр кичермәгән хисләрне кичерәчәксез!

Яхшылык тиз йогучан була икән. «Түбән Кама нефтехим» хезмәткәрләре хәзер үзләре Розаны табып, волонтерлык проектларында катнашырга теләк белдерә, төрле чаралар оештыралар. Проектларга шәхси эшмәкәрләр дә үз теләкләре белән ярдәм итәргә тора.

– Бу бик яхшы күрсәткеч бит инде. Битараф түгел нефтехимиклар. Бу – безнең шәһәр. Бу – безнең кешеләр. Шәһәр хакимиятенә дә рәхмәт, җитәкчелек белән уртак тел табып, һәрьяклап ярдәм итәләр, биналар, автобуслар бирәләр. Махсус хәрби операция башлану белән волонтерлык хәрәкәтенең тагын бер юнәлешен ачып җибәрдек. «Близкие люди» проекты аша хезмәт итүчеләрнең гаиләләре белән эшли башладык. Болай да тотрыксызлык, билгесезлек чорында яшәгәндә андый гаиләләргә тагын да авыррак икәнен социолог, психологтан да яхшырак аңлаучы бар микән...

СИБУРның экологиягә бәйле «Формула хороших дел» проекты исә Розаның тормышында аерым урын алып тора. Әйләнә-тирә мохиткә булган мөнәсәбәте күптән тормыш рәвешенә әйләнгән. Агачлар утырту, сулыклар тирәсен, паркларны чүптән арындыру эшләре дисеңме – берсе дә Розадан башка узмый. Үзең катнашу бер яхшылык булса, артыңнан башкаларны да ияртә белү – сәләттер ул!

– Мин үзем генә түгел, бөтен гаиләм шундый. Әни гомере буе кешеләрне кайгыртып яшәде, әле дә безнең белән. Кызым Сабина мастер-класслар уздыра, улым Булат чарага коляска белән килгән балаларга ярдәм итә, аларны йөртә. Урамда калган хайваннарны алып, аларны дәвалап, яңа гаилә табу эшен дә улым башлап җибәрде. Йөздән артык җан иясен яңа гаиләләргә урнаштырдык инде. Хәтта сеңлем дә – үзе биш бала әнисе, үзләренең җәйге кэмпингларында «Юртфэст» фестивале уздырырга ярдәм итеп, проекта катнашучы гаиләләрне, балаларны колач җәеп каршы ала. Үзгәрешләр чорында яшибез. Җәмгыять тә, кешеләр дә үзгәрә... Игелеккә, изгелеккә гел вакыт булырга тиеш!

Фото: НКНХ матбугат хезмәте

БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛГА НИЧЕК ЯЗЫЛЫРГА

Почта аша язылу

«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча
Татарстанлылар өчен бер елга индекс – **П8299**
ярты елга индекс – **П2204**
Республикадан читтә яшәүчеләр өчен индекс **– П0279**

ОНЛАЙН ЯЗЫЛУ

Компьютер аша

1 Почта России сайтына керегез: **https://podpiska.pochta.ru/**

2 Төбәкне/шәһәрне үзгәртегез

«Сююмбикэ» дип язып, журналны эзләп табыгыз

3 Тәкъдим ителгән алгоритм буенча барыгыз

Смартфон аша

1 
QR-код буенча керегез

2 Менюга кереп, төбәкне/шәһәрне үзгәртегез

«Сююмбикэ» дип язып, журналны эзләп табыгыз

3 Тәкъдим ителгән алгоритм буенча барыгыз

РЕДАКЦИЯДӘ

Килеп алу шарты белән
ярты елга язылу бәясе – **360 сум.**
Теләсә кайсы айдан язылырга мөмкин.

Яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар һәр айның 15 нә кадәр язылып, журналны киләсе айдан алдыра ала.

Хәзер «Сөембикә» журналын Wildberries, Kazan Express, Ozon, «Татмедиа» онлайн кибетеннән дә сатып алырга була.

БЕЗНЕ УКЫГЫЗ
Сайтта: **www.syuyumbike.ru**
ВКонтактеда: **vk.com/suumbike**
Телеграммда: **https://t.me/suumbike**

РЕКЛАМА 16+

1977–1988 еллар



1977–1988 елларда «Азат хатын»ны танылган журналист Венера Фәиз кызы Ихсанова җитәкли. Бу инде милли мәсьәләләргә йөз белән борылуга омтылыш ясаган чор. Журналда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, тарихы, теле турында язмалар күренә башлый. Тарихи Ватаныбыздан читтә яшәүче татарлар Татарстандагы хәлләр белән «Азат хатын» аша таныша:
ул елларда татар кешесе илнең кайсы гына почмагына барып урнашса да, иң беренче булып безнең журналга язылган. «Азат хатын» аларны туган яклары белән бәйләп торган, сагынуларын баскан...
Журналның тиражы иң күп булган еллар бу. Венера Ихсанова җитәкли башлаганда ул 350 мең була, ә аннан, күп тә үтми, 487 меңгә кадәр күтәрелә. Чыга башлавына 60 ел булган көннәрдә журнал: «Безнең нигез авыр елларда салынган, ләкин нык итеп, киләчәкне күздә тотып салынган. Халык барда, халыкның журналга булган ышанычы, хөрмәте барда «Азат хатын» да яшәр, яңадан-яңа саннары белән сөендерер. Халкына мәңге хезмәт итәр», – дип яза. Редакциягә ул елларда хатлар ишелеп килә! «Халыкның нинди уйлар белән яшәвен беләсем килгәнгә, һәр хатны үзем укый идем», – дип сөйли Венера Фәиз кызы үзенең истәлекләрендә. Ул аларның күбесенә җавапны да үзе биргән. Журналның баш мөхәррире Мәскәүдә хатын-кызлар комитеты әгъзасы булып тора, аның рәисе Валентина Терешкова белән еш очраша. Татарстанда да хатын-кызлар комитеты оештыруда катнаша – журнал һәрвакыт республиканың иҗтимагый тормышында зур роль уйнаган. Кайгы-хәсрәтен сөйләргә халык обкомга түгел, ә «Азат хатын»га йөргән. «Азат хатын»да укучылар яратып каршы алган «Кич утырганда» рубрикасы барлыкка килә, хатын-кызның хезмәтен җиңеләйтү, бала тәрбияләү, гаилә тормышына караган мәкаләләр дөнья күрә. Сиксәненче еллар ахырына журнал милли фикер үзәгенә әверелә бара. Авторлар белән элемтә ныгый, редакция үзендә бик күп күренекле кешеләрне кабул итә: шагыйрьләр Мостай Кәрим, Хәсән Туфан, Нәби Дәүли, композитор Заһид Хәбибуллин, СССРның халык артистлары Азат Аббасов, Фуат Халитов, Шәүкәт Биктимеров... «Азат хатын»-да күренекле журналистлар Диләра Зөбәерова, Кояш Тимбикова, Эльмира Әдиатуллина, Рәйсә Юсупова, Хәмзә Зарипов, Марс Шабаев, Сәйдә Зыялы, Мидхәт Хөснимәрдановлар эшләгән еллар бу.



Редакциянең бергә җыелган чагы.

Венера Ихсанова турында уку өчен:





АЗАТ ХАТЫН

1926 ЕЛДА ЧЫГА БАШЛАДЫ СЕНТЯБРЬ • 1977



«АЗАТ ХАТЫН» журналына язылырга онытма!



1978 нче ЕЛНЫ «АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫНДА БАСЫЛАЧАК КАЙБЕР ӘСӘРЛӘР, ЯЗМАЛАР

Ибраһим ГАЗИ. Укылмаган хат (әдәби мирастан).

Габдрахман **ӘПСӘЛӘМОВ.** Ил кайгысы (хикәя).

Фатих ХӨСНИ. Артист хикәяләре.

Әхсән **БАЯНОВ.** Үзәндә атлы арба (хикәя).

Туфан **МИҢНУЛЛИН.** Кәримә әби (хикәя).

Роберт БАТУЛЛИН. Ташламам, җанкисәгем (нәсер).

Мәдинә МАЛИКОВА. Сары тюльпаннар (хикәя).

Габдулла ШӘРӘФИ. Үлгәннән соң тәүбә юк (хикәя).

Ләбибә ИХСАНОВА. Кечкенә Шамилнең олы хәсрәте (хикәя).

Дания БАҺАВЕТДИНОВА. Шәриф Камал хатлары.

Хәсән **ТУФАН**, Мостай **КӘРИМ**, Илдар **ЮЗЕЕВ**, **Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА, Клара БУЛАТОВА, Сәлисә ГӘРӘЕВА, Фәйрүзә МӨСЛИМОВА.** Шигырьләр.

Шахсанәм ӘСФӘНДИЯРОВА, РСФСРның атказанган артисткасы. Артист булам дисәң...

Зәйнәп ЯКУПОВА, профессор. Дуслар кадере.

Баһрам САДЫЙКОВ, медицина фәннәре докторы. Менә син дә җиткән кыз булдың (үсмерләр клубы).

Мәрьям ДИБАЕВА. Уллар үстергәндә.

Кояш ТИМБИКОВА. Кайнанам яшәсен.

Диләра ЗӨБӘЕРОВА. Күңелең пакь булсын.

Журналның һәр санында авыл хуҗалыгыннан, промышленность предприятиеләреннән очерклар, репортажлар, фоторәсемнәр бирелеп барачак.

В. Кудελькин картинасы.

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР



Хөрмәтле Лариса Николаевна, кадерле «Сөембикә» журналы коллективы!

Бөтен татар дөньясы исеменнән сезне шушы тарихи бәйрәм – хатын-кызлар өчен беренче татар журналы чыга башлауның 110 еллык юбилее белән тәбрик итәм. Бүгенге көндә Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә яшәгән милләттәшләребез өчен дә әлеге басма рухи азык, яшәешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Шушы бер гасырдан артык вакыт аралыгында «Сөембикә» – үз исеменә һәм кыйбласына тугры калган сирәк басмаларның берсе. Хаклы рәвештә татар хатын-кызлары хәрәкәтенең елъязмасы булган журнал алга таба да үз дәрәҗәсен югалтмыйча, заман белән бергә атлаучы мәгълүмат чарасы булып тагын да югарырак үрләргә ирешсен. Күркәм юбилеегыз киләчәккә максатлар билгеләү өчен бер мөмкинлек булсын. Халкыбызның телен, динен, мәгърифәтен, мәдәниятен үстерүгә һәм саклап калуга сез үзегездән зур өлеш кертәсез.

110 еллык юбилеегыз уңаеннан коллективыгызга саулык-сәламәтлек һәм уңышлар телим. Милләтебез алдында башкарган хезмәтегез өчен сезгә чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәбез, киләчәктә дә эшлекле һәм дустанә мөнәсәбәтләребез сакланыр дигән өметтә калабыз.

Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе



sufiiamostafina «Без – Татарстаннан читтә яшәүче татарлар, «Азат хатын» журналына язылып, кулдан-кулга йөртеп укый идек. Үзебезгә кире әйләнеп кайтканчы таушалып, ертылып беткән була иде журнал. Яңа сан белән дә шул ук кабатлана...»

Фәрвизә Сафина «Сөембикә» журналын 58 ел алдырам инде. Нинди авыр вакытлар булса да, һәрвакыт янәшәмдә булды. Язмыш мине бервакыт Үзбәкстан якларына алып китте, берничә ел шунда яшәдем. Анда да «Азат хатын»нан өзелмәдек, яздыртып алдык. Тугызынчы дистәмне вакласам да, әле дә журналның һәр битен хәрефенә кадәр укып чыгам!

Zuhrarustamovna Тәмен табып бер кичтә укып чыгам. Журналны ничә ел алдыруымны хәтерләмим дә инде. «Сөембикә»нең теле ошый. Бүтән бер генә журнал да чын безнеңчә, татар хатын-кызлары теле белән язмый, рәхәтләнеп – «маен чыгарып» укыйм. Кайда гына барсам да, нинди генә республикакүләм чараларда катнашсам да, үзебезнең абруйлы хатын-кызларыбызны (рәссам, сәясәтче, галимә, эшмәкәр һәм башка) таныйм. «Син кайдан беләсең аларның барысын да?» дигән сорауга: «Сөембикә»не укып барам, барысы белән дә журнал аша таныш», – дип җавап бирәм.

«ЛӘЙСӘН АБЫЙСЫНЫҢ АЛДЫНДА ҮСТЕ»

Уңыш формуласыниләрдән гыйбарәт? Сәләт, тырышлык, үҗәтлек, максатчанлык таләп итә ул. Бу исемлекне уңышка ирешкән һәр кеше үзенчә дәвам итәр иде. Ләкин тагын бер мөһим әйберне билгеләп үтми мөмкин түгел. Бу шәхес артында кем тәрбиясе тора? Кемнең үгет-нәсыйхәте, изге теләге, үрнәгә белән уңышка ирешкән? Кем баласы ул? Бу проектта шул сорауларга бергәләп җавап эзләрбез.









Римма ИБРАҺИМОВА – җырчы, Татарстанның халык артисты, Муса Җәлил премиясе иясе.
Балалары: Фәрит Таишев – җырчы, продюсер, 2008 елга кадәр «Барс-Рекордс»ның генераль продюсеры, эшмәкәр.
Ләйсән Таишева – радиода алып баручы.

Римма ханым, балаларыгыз турында сөйләшә башлаганчы сезнең гаилә тарихына тукталыйк әле. Ирегез – цирк артисты, трюклар күрсәтүче Равил Таишев. Аның белән кайда, ничек таныштыгыз?

– Безне – бер төркем 17–18 яшьлек егет-кызларны, сайлау уздырып, Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясеннән Мәскәүгә Бөтенроссия эстрада студиясенә укырга җибәрделәр. Бөек җырчы Георгий Виноградов җитәкчелегендә шөгыльләндек. Татарча да, русча да җырлатты ул безне. Равил дә Омск шәһәреннән укырга килгән иде. Чыгышы белән Украинадан, үзе – татар егете. Татарча сөйләшә генә белми! Шунда танышып киттек. Равил үзе филармониягә шалтыратып, сөйләшеп, эшкә урнашып, бездән бер ел алда Казанга кайтып төпләнде. Тагын бер елдан мин дә укуны тәмамлап кайттым. Шуннан очрашып йөри башладык, гаилә кордык.

Гаиләдә ике артист... Фәрит тугач, бала карау мәсьәләсе ничек хәл ителде?

– Әйе, концертлар белән еш чыгып китәргә туры килде. Җәй көне өчәр айга китә идек. Фәритне үзебез белән дә алып йөрдек. Әтисеннән күреп моноциклда йөрергә, жонглёрлык итәргә өйрәнде. Равил бик кызыклы трюклар ясый: шул моноциклга утырган килеш аягы белән самаварны чөеп, башы белән тота иде. Фәрит тә шунда: ярдәм итеп тора, сәхнәгә булавалар алып чыга, әтисенә бирә. Үзен артист кебек хис итеп, куанып йөри.

Үзебез белән алып йөреп булмаганда күрше Фатыйма апага калдыра идек. Бик рәхәт кеше булды ул! Фәритне карап, тәрбияләп торды. Нәрсә генә булса да, бала иң кадерле кеше бит... Бервакыт Ульяновск шәһәрендә чакта Фәрит нык авырый башлаган. Безгә хәбәр килүгә үк Равил, ике дә уйламый, шундук кайтып китте.

Малай кеше бит... Сез дә һәрвакыт янәшәсендә була алмыйсыз. Мәктәптә укыган чакта кыенлыклар китермәдеме?

– Әйе, гел контрольдә тотып булмады, ләкин ул да, без дә ияләшкән идек андый тормышка. Мин Фәриткә бик рәхмәтле, авырлык китермәде ул безгә. Без гастрольдә чакта олимпиадаларда катнашып, урыннар алып, укырга да имтихансыз гына керде. Менә шундый бала иде... Аңа да читен булгандыр, әти-әниең китсен дә... Кайвакыт искә ала, ләкин үпкә сакламый. Искә төшереп, үземнең йөрәк сызып үтә, әлбәттә.

Фәрит белән Ләйсәннең яшь аермасы – 16 ел. Ике балага вакыт җиткерү авыр булыр дип тәвәккәлләми тордыгызмы?

– Әйе, болай да бер баланы калдырып йөрергә мәҗбүрбез, ике белән тагын да кыенрак булачак дип, анысын да уйладык. Әш шундый булгач, йөрмичә дә булмады... Ләйсән тугач, филармониянең лекторий бүлегенә эшкә урнаштым, завод-фабрикаларга барып эшләп, җырлап йөрдек. Ләйсәнне калдырып йөрмәдек алай. Ул чакта инде Фәрит тә зур иде. Бик кирәк булганда аңа ышанып тапшырдык. Фәрит Ләйсәнне шулкадәр ярата иде! Алдына гына утыртып карады ул аны. Фәрит дәрес әзерләгәндә дә Ләйсән абыйсының алдында утыра, нәрсәдер сыза, яза, кисә...

Үзебез ирешә алмаган хыялларны балалардан ирештерәбез кайчак. Фәрит белән Ләйсәнне дә артист итеп күрергә тели идегезме?

– Балаларга артист булыгыз дип әйткән булмады. Беренчедән, Фәрит үзе дә теләмәде. Алай да университетта укыган вакытта вокал белән шөгыльләнә башлады. Концертлар куялар, җырларның русчасын, татарчасын, инглизчәсен башкара. Диплом алгач та үзе теләгән эштә эшләп, үз юлы белән йөрде. Аннары барыбер артистлар белән эшли башлады, продюсерлык белән шөгыльләнде, үзе дә сәхнәдә җырлар башкарды. Балачакта безнең белән концертлар оештырып йөргәндә күргәннәре, өйрәнгәннәре дә ярап куйгандыр, дим.

Ләйсәнгә 7 яшь булганда тормыш алып бару авырлыгы үз җилкәгезгә генә кала. Равил абый вафат була...

– Белеп торсак та, бик авыр булды ул. Авырый башлагач, бик яхшы табибларга күрендек. Нәрсә эшләргә кирәк, чит илгә җибәрергәме, берәр дару табаргамы – машинаны сатып барысын да эшләргә әзер идем. Өметсез, диделәр шул... Өйгә кайткач, ваннага бикләнеп бик каты еладым да, Равил янына чыгып: «Бар да әйбәт булачак!» – дидем. Бер ел яшәде шуннан соң Равил... Иң зур терәгем Фәрит булды. Укуын да укыды, акчасын да эшләде. Бик рәхмәтле мин балаларга.

Уңышка ирешкән әти-әнинең исеме балаларына ияреп йөрүчән була. Аларга таләпләрне зурдан куялар, уңышка ирешүен көтәләр. «Римма Ибраһимова улы бу, кызы бу» дигән сүзләрне балаларыгызга еш ишетергә туры килдеме?

– Әйтүчеләр бар иде инде ул, бу тамгадан качып булмый, ләкин балалар үзләре беркайчан да моның белән мактанып йөрмәде. Ләйсән абыйсының, минем кем булуны яшереп тә йөргән иде әле. Беркайчан да берәр җиргә урнаштыруымны сорамадылар. Ләйсәнне музыка училищесына кертәсем килеп тыңлатырга да алып барып карадым. Рәхәтләнеп алалар иде, үзе теләмәде, үз юлы белән китте. «Яланаяклы кыз» фильмында төшкәч, икенчесенә дә чакырганнар иде, аннан да баш тартты.

Ләйсән бер интервьюда «Минем җырлавымны күрү – әниемнең иң зур хыялы» дип әйткән иде. Хәзер инде Ләйсән ике бала әнисе. Әле дә аның җырлавын көтәсезме?

– Элек, чыннан да, хыяллана идем. Тавышы матур, сәхнәгә чыкканы бар. Без аның белән дуэтлар да җырладык, үзе генә дә җырлады. Сабантуйларга да икебезне бергә чакыралар иде хәтта. Римманың яшь чагы дип әйтәләр иде Ләйсәнне. Хәзер көтмим инде. Һәрвакыт үзенчә эшли ул. Әйе дип кенә тормый, үзенә ни кирәген, ничек эшлисен белә. Минем дә киңәшчем – Ләйсән. «Алай кирәкми, болайрак эшлә», – дип киңәшен бирә, аңа колак салам.

Сезнең гаиләдә өченче буын артистлар үсеп килә. Ләйлә Таишева – тумыштан бирелгән сәләтме, уңдырышлы мохиттә тәрбияләнгән баламы?

– Ләйлә шундый булып туган кебек. Кайсына тотынса да, нәрсә теләгәнен үзе аңлап эшли торган бала ул. Әле бер көнне 3 яшьлек чактагы видеосын карадым. Курчагын бишеккә салган да, йокламаган өчен ачулана. Аннары тагын кызганып, матур итеп сөйләшә. Акцентларын дөрес куеп, артистларча сөйләп җибәрә! Шунда бар, болай эшлә дип өйрәтеп торучы да юк аны, үзе шундый. Фәрит белән Ландышның балалары дүртесе дүрт төрле. Әнвәр музыкага һәвәс, фортепианода уйный, көйләр дә чыгара. Гомәр фән юлыннан китәрдер кебек. Аның һәрвакыт дәресе эшләнгән, сумкасы тутырылган, бөтен әйбере тәртиптә. Каюм үзенә бер кеше, аның карап торулары ук искиткеч! Ландышның (*җырчы Ландыш Нигъмәтҗанова – авт.*) әти-әнисенә рәхмәт, бик булышып торалар. Кода гармунда уйнап җырлата оныкларыбызны. Бөтен халык җырларын, танылган композиторларны өйрәтеп бетерде инде. Балалар да аптырап тормый, сүзләрен өйрәнеп, рәхәтләнеп җырлыйлар. Фәрит белән Ләйләнең җырлаганын карап сокландым әле, тавышы бар баланың...

Киләчәктә Римма Ибраһимова оныклары дип әйтерлек талантлар үсә сездә алайса?

– Белеп булмый... Үсәселәре бар, тавышлары үзгәрәсе бар. Әле шул булганнары өчен генә дә сөенеп бетә алмыйм. Училищеда эшем беткәч тә Ләйсәннәргә йөгерәм: Ролан улым, Эмма кызым белән рәхәтләнеп уйнап, аларны сөеп кайтам. Хәзергесе сөбханаллаһ, алдагысы да хәерле булсын!

Алсу ШАКИРОВА



Римма Ибраһимова белән тулы интервью »

Фото: Алсу Opale. Видео: Дмитрий Цумарев

1988–2000 еллар



1988 елдан 2000 елга кадәр журналның баш мөхәррире булып Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова эшләде. Бу чорда журнал үзенең исемен үзгәртә: 1991 елда ул кабат «Сөембикә» булып чыга башлый. Үз үсешендә ул яңа баскычка күтәрелә – халыкара аренага чыга. Хатын-кызларыбызда милли рух, милли горурлык хисләре уяту нияте белән редакция җиң сызганып эшкә керешә. Киләчәгебез яшь кызларның, яшь әниләрнең рухи халәтенә бәйле булуын журналистлар язмадан-язмага исбатлый. Туган телебез язмышы да беренче чиратта ана кеше кулында икәнлеген аңлаталар. Журналда «Гасыр чаңы ни хакында?», «Буыннарның көмеш чылбыры», «Мәшһүр татар хатын-кызлары», «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре...», «Татар кызы сылуым-иркәм» дигән яңа рубрикалар барлыкка килә. «Бишек», «Оя-нигез», «Хәзинәбикә» дигән кушымталар чыга.

«Сөембикә» бөтен татар хатын-кызларын туплап, берләштереп торучы ролен үти. Казанның зур сәхнәләрендә «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» кебек бәйге-тамашалар үткәрә. Татар хатын-кызларының бүгенге көндә дә гөрләп эшләүче «Ак калфак» иҗтимагый оешмасына нигез салучы да «Сөембикә» журналы, аның баш мөхәррире була.

Редакция ул елларда көн саен диярлек кунак кабул итә: илләр арасында чикләр ачылгач, тарихи Ватаннарына беренче тапкыр аяк баскан читтәге милләттәшләребезнең күбесе якын итеп «Сөембикә»гә дә килә. «Без сезне гомер буе алдырдык, яратып укыдык, һәркайсыгызны беләбез», – дип, редакция ишеген ачып керә алар. Журналның беренче саны чыгуга 70 ел тулу уңаеннан исә редакциягә иң зур кунак – Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев килә. Ул журнал коллективын Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкли.

Журналның баш мөхәррире Роза Туфитуллова, «Ак калфак» оешмасы рәисе булу белән беррәттән, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары вазыйфасын да башкара. 1999 елда ул Татарстан халык депутаты булып сайлана һәм парламентка эшкә күчерелә.

Бу чорда «Сөембикә»дә журналистлар Филисә Хәкимова, Роза Камалетдинова, Марат Әмирханов, Нәҗибә Сафина, Нурсөя Шәйдуллина, Әлфия Сәгъдиева, Мәдинә Авзаловалар эшли.




Президентның «Сөембикә»гә килүе бөтен татар матбугаты өчен вакыйга була. 1996 ел.

Роза Туфитуллова турында уку өчен:



СӨЕМБИКӘ



1

1991

سيوم بيك

Д. БУНТУКОВ
Р. ГАЛИЕВ
фотосы.



СВИДЕТЕЛЬСТВО

о регистрации средства массовой информации

регистрационный № 36

Учредитель Татарский республиканский комитет КПСС, издательство Татарского республиканского комитета КПСС и коллектив редакции журнала "[illegible]"

Название, язык (языки), адрес средства массовой информации "[illegible]", татарский яз.; г.Казань, ул.Декабристов, 2

Предполагаемая аудитория рассчитан на женскую аудиторию

Программные цели и задачи содействовать нравственному обновлению общества, повысить социальную и политическую активность женщин, обеспечить социальную защищенность женщин, материнства и детства

Предполагаемая периодичность выпуска, максимальный объем средства массовой информации и источники финансирования 1 раз в месяц, 4,6 печ.л.; финансирование осуществляется через Управление Делами ЦК КПСС

Председатель
Госкомиздата ТССР

Ш. Ш. ХАММ[illegible]



«Сөембикә»не иҗат итүчеләрдән бер төркем: фотосурәтче **Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ**, бизәлеш мөхәррире **С. ИБРАҺИМОВА**, мөхәррир **Р. ЮСУПОВА** (беренче рәт); мөхәррир **Ә. СӘГЪДИЕВА**, баш мөхәррир урынбасары **М. ӘМИРХАНОВ**, мөхәррир **Н. ШӘЙДУЛЛИНА** (икенче рәт); мөхәррир **Р. КАМАЛЕТДИНОВА**, баш мөхәррир **Р. ТУФИТУЛЛОВА**, гамәли мөхәррир **Э. ӘДИАТУЛЛИНА**, фотохәбәрче **Д. БУНТУКОВ** (өченче рәт); әдәби хезмәткәр **З. ӘКБӘРОВА**, рәссам **И. РОДИОНОВА**.

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР



Айдар СӘЛИМГӘРӘЕВ, **«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе**

Хөрмәтле коллегалар!

Уртак бәйрәмебез – «Сөембикә» журналының күркәм юбилее белән котлыйм сезне!

«Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!» шигаре белән нәшер ителүче бу затлы журнал үзенең җылылыгы, тирән эчтәлеге, зәвыклы бизәлеше белән укучыларын сөендереп, ай саен кадерле кунак булып өйләребезгә килеп керә. Балачактан ук таныш күренеш: «Сөембикә» килгән көн – әни өчен бәйрәм! Без дә ул журналга аерым бер хөрмәт белән карап, аны гаиләбезнең бик кирәкле киңәшчесе урынына күреп үстек. Ә әни бүген дә аның тугры укучысы.

«Сөембикә» – татар телендә нәшер ителә торган иң популяр басмаларның берсе, дөнья стандартларына туры килә торган замана журналы. Татар милләтен берләштерү, телне, гореф-гадәтләрне, милли гаилә нигезләрен саклау буенча бик күп күркәм эшләр башкара. Басма һәрвакыт журналистлары, иҗади көчләре, колачлы проектлары, яңа башлангычлары белән дан тотты. Матбугат чараларының Бөтенроссия конкурсларында яулаган призлы урыннары үзләре генә дә Россия матбугатының Алтын фондына кергән журналның югары дәрәҗәсе турында сөйли. Ул милләтара һәм этноконфессиональ мөнәсәбәтләрне яктыртып, «Многоликая Россия», «СМИротворец» конкурсларында җиңүче, Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы уздырган «Моя земля – Россия» проектында «Авыл гаиләсенең заманча йөзе»н яктыртучы дипломына лаек булган басма. Ә Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм» конкурсы исә «Сөембикә»не 2020 елда кабат «Иң яхшы журнал» дип бәяләде. «Фотообъективта – әни» фотоконкурсы, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә уздырылган «Татар гаиләсе», «Килен һәм кайнана» конкурслары да журнал һәм аның укучыларының бер дулкында яшәвен раслады.

«Сөембикә» киләчәктә дә үз укучыларын яңадан-яңа проектлары, кызыклы бәйгеләре, чын журналистик язмалары, заманча сәхифәләре белән сөендерсен. Сәламәтлек, иҗат уңышлары, зур җиңүләр телим сезгә, дуслар!



«Сөембикә» журналының «Азат хатын» булган заманнарын да хәтерлим әле. Анысы минем балачак һәм яшүсмер еллар хатирәсе. Хәзергесеннән бераз юкарак, сары битле бу журналның килгәнен түземсезләнеп көтеп алабыз да иң элек һәр битен өстән-өстән карап чыгабыз: алдан кайсын укырга (ул вакытта озаклап кулга китап, журнал тотып утырырга вакыт юк, иң элек син өйдәге эшләрне эшләргә тиеш). Иң беренче кем кулына эләгә, шул укый. Хәзерге кебек интернет булмаган заманда аш-су пешерү рецептлары, тегү, чигү үрнәкләре табу өчен дә безгә төп ярдәмче иде ул. Истәлек дәфтәрләренә рәсемнәр дә шуннан алынган, аш-су әзерләү, чигү үрнәкләрен дә шуннан күчереп язганмын.

Бүгенге көндә дә «Сөембикә» гаиләбездә иң яратып укылган һәм һәркем кулыннан үткән журнал. Иң элек ул дизайны белән җәлеп итсә, икенчедән, нәзберек заман укучысының да ихтыяҗларына җавап бирерлек. Журналист булырга укыган кызыма фәнни эшләр язганда яисә өй эшләре эшләгәндә дә үрнәкләрне гел шуннан алабыз. Шуңа күрә укыганда төрле-төрле кыстыргыч (закладкалар) куеп барам: яшел төслесе – кызым өчен, ә аллары – үземә. Тагын да файдалырак өлеше шул: студентларыма тәрбия сәгатендә уку өчен материалларның да иң үтемлесе – «Сөембикә»дә. Бары тик кызлар гына укыган төркемемдә анда басылган һәр тема тормышка өйрәтү материалы: төрле дәрәҗәләргә ирешкән хатын-кызлар язмышыннан алып, аш-су, бизәндерү, үз-үзеңне карау, мода, психолог киңәшләре һәм башкалар. Җаның ни тели шунысын укы. Әни буларак, балалар тәрбияләү мәсьәләсендә дә күп тәҗрибә тупларга ярдәм итте миңа «Сөембикә».

Яраткан журналымны зур юбилее белән котлыйм! Булганың өчен рәхмәт! Эшләрең дәвамлы, укучыларың күп булсын! Уңышлар сиңа!

Әлфия ТӨХФӘТУЛЛИНА.
Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятенең милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары.

БУ СӘХИФӘДӘ ДӘ – БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛ ТАРИХЫ. ДӨРЕСРӘГЕ, КАЙЧАНДЫР «АЗАТ ХАТЫН» («СӨЕМБИКӘ») РЕДАКЦИЯСЕНДӘ ЭШЛӘГӘН ЖУРНАЛИСТЛАР ЯЗМЫШЫ. ХӘЕР, АЛАР ЯЗМЫШЫ ИЛНЕКЕННӘН АЕРЫЛМАГАН ДА УЛ ЧАКТА...

ЯЗМЫШ ШӘХЕСЛӘРНЕ НИГӘ АЯМЫЙ?!

Бөтен гомерен хатын-кызларның мәгърифәтен күтәрү-агарту эшенә багышлаган, хезмәтләре әле бүген дә кыйммәтләрен югалтмаган татар мәгърифәтчесе һәм педагогы Фәхрелбәнат Сөләймания – XX гасыр башында беренчеләрдән булып матбугат дөньясына аяк баскан татар кызларының берсе. Ләкин никтер шушы көннәргә кадәр тормыш юлы ныклап өйрәнелмәгән, хәтта ки туган елы да төрле чыганакларда төрлечә язылган аның. Мәкаләм шушы бушлыкны бераз гына тулыландыру нияте белән языла да инде.





Тәэминә БИКТИМИРОВА

Халкыбызда «Оясында ни күрсә...» дигән мәкаль бар. Бу кыз баланы очырган ояга күз салсак, анда хөрмәтләп искә алырга лаеклы шәхесләребез барлыгын ачыклый алабыз. Фәхрелбәнат 1865 елда (аен, көнен ачыклап булмады) Казан губернасы Чар өязе (хәзер Татарстанның Арча районына керә) Түбән Оры авылында туа. Аның әтисе Сибгатулла хәзрәт Сөләйман гомеренең күп өлешен шушы авылда имамлык хезмәтендә үткәрә. Шунысы безнең өчен әһәмиятле булыр дип уйлыйм, Сибгатулланың улы Лотфулла хәзрәт Сөләйман Орыдан ерак түгел урнашкан Котаймас (хәзерге исеме – Кышлау) авылы имамы булган. Лотфулла хәзрәт хәзерге татар зыялыларына

азмы-күпме билгеле шәхестер дип уйлыйм, чөнки аның кызы Галимәтелбәнат Биктимерия – танылган әдибәләребезнең берсе. Әтисендә укып, 16 яшендә ул әтисенең кызлар мәктәбендә мөгаллимәлек эшенә керешә. 1895 елда кияүгә чыгып, Касыйм шәһәреннән ерак түгел урнашкан Янбаш (Җаубаш) дигән авылга китә. Анда да кызлар мәктәбе оештырып, аларны заманча укыта башлый. Алай гына да түгел, язучылык эше белән шөгыльләнә һәм кыз балалар тәрбиясенә багышланган китапларын бастырып чыгарырга өлгерә. Тик бик яшьли – 30 яшендә үк вафат була. Олуг әдибебез Фатих Әмирхан аның хезмәтләренә зур бәя биреп, «Тәрбиятел-этфаль» журналында (№ 1, 1907) махсус мәкалә язып чыга.

Галимәтелбәнатның сеңелләре Затессәгадәт, Фатыйма, Гайшә, Гафифәләр – барысы да заманы өчен алдынгы белемнәр алган һәм, кабатлап әйтәм, барысы да төрле җирләрдә кызлар мәктәпләре оештырган игелекле, булдыклы шәхесләр булган.

Аларга белем бирүдә әтиләре куйган көч-хезмәтне әйтеп бетереп булмый. Лотфулла хәзрәт, беренчедән, үзе үзәк шәһәрләрдән читтәрәк яшәсә дә, «Тәрҗеман» газетасын укучыларның берсе булган һәм яңа метод (аваз методы) турында сүз кузгалгач та, аны тормышка ашырырга керешкән. Кызларын мөгаллимәлеккә ул үзе әзерләгән. Махсус уку планнары, программалар, кулланмалар төзегән, төрле фәннәрдән төпле белем бирергә тырышкан. Хезмәте, шөкер, бушка китмәгән.

Фәхрелбәнат та шушында – кардәш кызлары янында белем туплаган. Әтисе Сибгатулла мәдрәсәсендә алган башлангыч белемнәрен шулай баетырга тырышкан. Лотфулла хәзрәт кызларга системалы рәвештә сарыф (морфология), нәхү (синтаксис), бәлгаять (поэтика), әдәбият гарәбия вә төркия (төрки һәм гарәп әдәбияты), гаруз (шигырь төзелеше), гакаид (дин нигезләре), хисап, тарих,

Фәхрелбәнат Сөләймания – 1914 елда татар зыялылары арасында исеме инде танылган шәхесләрнең берсе була.

география, ысул тәгълим (укыту ысулы – методика) һәм башка фәннәрне өйрәткән. Лотфулла хәзрәт хакында безнең олуг галимебез Мәсгут ага Гайнетдин язып чыккан иде, рәхмәт аңа.

Ә менә Фәхрелбәнатның Лотфулла хәзрәт кызлары янында белем өстәгәнен әдәбиятчы һәм тарихчы буларак танылган шәхесебез Габделбари Баттал (1880–1969) «Йолдыз» газетасының 1914 ел, 24 гыйнвар санында әйтеп үтә.

Габделбари Баттал үз мәкаләсендә болай дип яза: «Күптән түгел үз йомышым белән Мәскәүгә барган идем. Анда Фәхрелбәнат ханым Сөләйманиянең яңа гына Истанбулдан кайтып, Мәскәүдә мелла Габдулла Шәмсетдинов ханәсендә тукталганын ишеттем. Фәхрелбәнат ханым... Оренбург духовный собраниесендә әгъзалык иткән... Нижний имамы Хәлил хәзрәт Сөләйманның рафикасы (хатыны) вә хәзер... мәгъруф (атаклы, танылган) яшь имам Габдулла әфәнденең вәлидәседер (әнисе)... Фәхрелбәнат ханым... бик иртә танылган ханымнарыбыздан Галимәтелбәнат Биктимериянең хәмширәсе...»

Габделбари Баттал мәкаләсе эчтәлеген тулысы белән китерү максатым түгел. Әмма, аңлашылганча, Фәхрелбәнат Сөләйманиянең исеме 1914 елда татар зыялылары арасында инде танылган һәм хөрмәт казанган кеше булганлыгы ачык беленә. Шулай булмаганда, аның белән очрашуны махсус эзләп кем барсын ди?

Фәхрелбәнат матбугатка 1905 ел революциясе чорында килеп керә. Аның беренче шигырьләре «Казан мөхбире» газетасында 1905 елда ук басыла башлый. Дөрес, иҗатының башлангыч чорында хатын-кызлар мәгарифе мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре ничектер төрекләргә якынлаштырырга тырышкан кебек. «Башлангыч мәктәпләр өчен, – дип яза ул, – бөтен дәрес китапларын, программаларны госманлылардан күчереп алып, ирләр һәм кызлар мәктәпләребез өчен бастырылып кулланылса, башлангыч мәктәпләребез алга китәр иде».

Тормыш аның бу өлкәдә бераз ялгышканын бик тиз аңлаткан. Ник дигәндә, 1908 елда алар ире Хәлил хәзрәт һәм Алма-Ата бае Габделвәли Исхаков белән хаҗга барырга чыгалар. Тик ни сәбәптәндер, Фәхрелбәнат Төркиядә кала (элек хатын-кызларның хаҗга барулары хәзерге кебек гадәти күренеш булмаганы билгеле). Өч ай буе ул Истанбулда яшәгән: күзе ачык хатынга төрек хатын-кызлары тормышы белән якыннан танышырга мөмкинлек шулай ачылган. Тагын Габделбари Баттал истәлегенә мөрәҗәгать итик. «Фәхрелбәнат ханымның әйтүенчә, – дип күрсәтә ул, – төрекләрдә гаилә тормышы бик начар: ирләр тәүлекнең иң күп өлешен каһвәханәләрдә уздыралар, хатыннары моңаеп вә зарыгып аларны көтәләр. Гаиләдә өлфәт, иттифак вә киңәш белән эш кылу юк икән... Хәзер Истанбулда «Мөтәрәха хокук нисван» («Хатын-кыз хокукын яклау») җәмгыяте нигезләнгән. Җәмгыять «Кадыннар дөньясы» исемле бер журнал чыгара... Журнал хатын-кызлар арасында мәгариф тарату өчен дә тырыша икән...»

Фәхрелбәнат ханым «Кадыннар дөньясы»на күп кенә мәкаләләр язган. Татарларның гаилә тормышын, бездәге хатын-кызлар әхвәлен төрекләргә танытырга тырышкан һәм төрек хатын-кызларын Русиягә чакырган...

Шушы сөйләшү барышында Габделбари Баттал Фәхрелбәнаттан киләчәккә нинди ниятләре барлы-

«Сөембикә» журналының редакторы Якуб Хәлили белән алар фикердәшләр булып эшлиләр.

гын сорый. Ул аңа «Аналар» исемендә журнал чыгарырга теләге барлыгын, әмма Казанда чыга башлаган «Сөембикә» (1913, октябрь) журналы яхшы гына чыгып китсә, анда эшләргә, шуңа күрә Казанга күчеп китәргә дә теләге барлыгын әйтә.

Истанбулдан кайткач, Фәхрелбәнат Казанга килә һәм 1914 елдан 1918 елга кадәр «Сөембикә» журналының сәркатибе булып бәрәкәтле хезмәт итә. Журналның редакторы Якуб Хәлили белән фикердәшләр булып эшләве аның иҗтимагый һәм иҗади активлыгын яңа югарылыкка күтәрә дияр идем. Ул бу чорда уку-укыту, бала тәрбиясе, гаилә, әхлак мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрне күп яза һәм алар укучыларның игътибар үзәгендә була. Чыннан да, Оренбургта яшәгән чорда (ире Хәлил хәзрәтнең Диния нәзарәтендә эшләгәнен әйтеп үткән идек) язылган «Иршад яки көзге» (1905), «Кызлар тәрбиясе» (1906), «Микъраз-әт-тәгас-сыб фи рәддимиръат-әт тәәсеф» (1907) кебек әсәрләрендә күбрәк гарәп сүзләре өстенлек итә. «Сөембикә» журналындагы мәкаләләрнең теле үзебезгә, халкыбызга якын. Темалары, эчтәлекләре, куелган проблемалары бүген дә әһәмиятен, кыйммәтен югалтмаган. Мисал өчен, «Без хәйәткә ничек хәзерләнәбез», «Татар хатын-кызлары дикъкатенә», «Балалар тәрбиясе», «Булдыксызлыгымыз», «Исмәгыйль Гаспринский», «Бөек фаҗига», «Идел буе матбугаты» – барысы да укучылар көтеп алган, көн кадагында торган мәсьәләләргә багышланган мәкаләләр.

Әйтеп үтик, Фәхрелбәнат журналга хатын-кыз авторларны чакыра, аларның мәкаләләре дә торган саен ешрак күренә башлый. Шундыйлардан Маһруй Мозаффария, Мәхбүбҗамал Акчурина, Әминә Төхфәтуллина, Багбостан Мөэминовалар журналда каләм чарлаган шәхесләр.

Фәхрелбәнатның кызлар мәктәпләре, андагы уку-укыту тәртипләре белән бик нык кызыксынып йөрүе гаҗәп түгел. Имтихан вакытларында мәктәпләр аны үзләре үк чакыра торган булган, чөнки алар өчен ул гади күзәтүче генә түгел, ә бәлки якын киңәшче, ярдәмче.

Уллары Габдулла (1886–1937) – аның горурлыгы да, мәңгелек йөрәк ярасы да.

Яшьтән үк бик сәләтле булган бу бала башта әтисендә, соңрак Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Соңрак (еллары билгеле түгел) Бәйруттагы Америка көллиятендә, университетта укый. Россиядә чакта татар, рус, гарәп телләрен белгән булса, Бәйруттан француз, инглиз телләрен өйрәнеп кайта. Кайткач, 1912–1917 елларда Түбән Новгородта мулла булып тора.

1917 елдагы вакыйгаларда ул актив көрәшче, татар милли азатлык хәрәкәте лидерларының берсе була. 1917 елның апрелендә Түбән Новгород губерна мөселман комитетын оештыра. Бөтенроссия мөселманнар корылтайларының барысында да катнаша һәм үз сүзен әйтми калмый. Чыгышларында хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклы булуларын яклап чыга. 1917–1918 елларда Милләт мәҗлесе делегаты, шул ук вакытта Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте казые (1917 елдан), Голямалар шурасы әгъзасы (1926 елдан), Мәскәүнең Җәмигъ мәчетендә мулла (1929–1930) булып игелекле хезмәт итә.

Инде мәгълүм булганча, 1924–1927 елларда Диния нәзарәтенең казые, актив җәмәгать эшлеклесе Кәшшафетдин Тәрҗемани редакторлыгында Уфада «Ислам» мәҗәлләсе (журналы) чыгып килә. Габдулла Сөләймани – журналның иң актив авторларының берсе. Ул дини йолаларга үзгәрешләр кертү турында уйлана, эзләнә башлый. Гает, җомга көннәрендә сөйләнә торган вәгазьләрне үзе саф татар телендә алып бара. Хәтта Коръәнне татар теленә тәрҗемә итеп, намазда укыла торган сүрәләрне дә татарча уку мәсьәләләрен күтәрә. Әмма мондый «бидгать» хәрәкәткә каршы барлык иске руханилар баш күтәрә. Диния нәзарәтенә гаризалар ява: «Динне бетерәләр...», «Харап итәләр...», «Коръән татар телендә булса, аның бер изгелеге калмаячак...»

Репрессияләр чорында ул Диния нәзарәте әгъзалары белән берлектә 1930 елда кулга алына һәм 1937 елда үтерелә. Аның белән бергә халкыбызның горурлыгы, мактанычы булган зыялы шәхесләребез Җ. Абызгилдин, К. Тәрҗемани, Һ. Атласи, З. Камали, М. Бубыйлар юк ителә. Урыннары җәннәттә булсын...

Фәхрелбәнат ханымга бу хәсрәтләрне дә кичерергә туры килә... 1918 елда журнал ябылгач, ул Сабада кызлар мәктәбе ачып, бер ел укыта. Соңгы гомере хакында беркем дә язмаган – мәгълүматым юк. Вафаты – 1959 елда.

Уйланам... Күпме эшләр башкарган, милләтебезнең горурлыгы була алырлык акыллы бала тәрбияләп, заманында иң хөрмәтле ханымнарыбызның берсе саналган Фәхрелбәнат Сөләймания белән дә язмыш ничек рәхимсез кыланган икән. Ник талантлы шәхесләрне тормыш, язмыш бер дә аямый?! Ә без хәзер нигә мондый шәхесләребезгә, аларның тормыш юлларына, хезмәтләренә битараф? Нигә онытабыз икән аларның халыкка күрсәткән изге гамәлләрен?

Урыннары җәннәттә булсын. Рәнҗемәсеннәр инде безгә...

Фото: автор архивыннан

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР



Зилә ВӘЛИЕВА, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе

Үзем әле журналны артык мавыгып укымаган яшь чакларым. Мин – шәһәр кызы – яшь килен булып иремнең авылы Дүсәнгә кайттым. Бөтен эшләрен тәмамлагач тынычлап калган кайнанамның, тәрәзә янына килеп, «Азат хатын» журналын укып утырганын хәтерлим. Ул аның, онытылып, сирәк тия торган бөтенләй башка бер дөньяга күчеп, ял иткән рәхәт сәгатьләре иде. Бу аның театрга баруы да, сәфәргә чыгуы да, төрле артистлар, язучылар белән очрашып, аларның тормышы белән якыннан танышып, аларга кунакка барып кайтуы кебек тә булгандыр инде. Үземнең инәй – дәү әни дә «Азат хатын»ны көтеп ала, бер санын калдырмый укып бара иде. Журнал ул елларда ук әнә шулай мәдәни структура хезмәтен үтәгән икән. «Азат хатын»ны укып барган татар хатын-кызлары гомер-гомергә белемгә омтылганнар, зыялы, тәрбияле, алдынгы карашлы булганнар, аң-белем тарату өчен Урта Азия якларына ук чыгып киткәннәр, югары белем алмасалар да, зур максатлар куеп яшәгәннәр. Хәзер дә журнал шул сайлаган юлына тугры калып, татар хатын-кызларының өстәл китабы ролен үти торган матбугат чарасы. Башка басмалардан аерылып торган үз стиле, үз йөзе, үз мохите, традицияләре бар. Шул ук вакытта бүгенге көн таләпләренә туры килерлек заманча да ул. Үз кыйбласын югалтмыйча, язмышын ил тормышы белән бәйләгән хатын-кызлар – аның геройлары. Барысы да дәүләтнең дә, республиканың да ышанычлы таянычы, терәге булган, заман белән бер адымда атлый торган кызлар, ханымнар. Тарихтан да беләбез: иңсәгә көянтә асып кына йөрүчеләр түгел, җигелеп тормышны алып баручы фидакарьләр дә әле алар. Кызларыбыз тракторын да йөрткән, ирләре Бөек Ватан сугышына киткәч, Татарстанда иң беренче нефтьчеләр дә хатын-кызлар булган!

Баш мөхәррирләр турында аерым әйтәсем килә. Сугыштан соң чыга башлаган «Азат хатын»ның баш мөхәррире Асия Хәсәновадан башлап, аның эшен дәвам иткән баш редакторларның һәрберсе белән якыннан аралашырга туры килде. Алар барысы да – шәхесләр! Бу инде дәүләтнең дә, хөкүмәтнең дә шундый җаваплы эшкә җитди якын килеп, иң лаеклы хатын-кызларны журнал җитәкчесе итеп билгеләве иде. Бүген менә шундый җиденче баш мөхәррир белән кулга-кул тотынышып эшлибез. Ил башлыгы, кызыксыну белдереп, иҗат коллективы белән танышыр өчен махсус килгән редакцияләр күп түгелдер. Ә менә «Сөембикә» ул яктан бәхетле! 1996 ел. Редакция журналистларының сөенеч һәм горурлык катыш бераз борчылып та Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевне каршыларга әзерләнеп йөрүләре күз алдымда. Соңрак Минтимер Шәрипович: «Ә минем ничек дулкынланганны белсәгез иде!» – дип куйды. Бу инде республика җитәкчесенең «Сөембикә» журналына тирән хөрмәте дә, ул тоткан кыйблага хәер-фатыйхасы да иде.

Бүген зур юбилеен каршылаучы «Сөембикә» – исеме җисеменә туры килеп торган легендар журнал. Ул безнең үткәнебез дә, бүгенгебез дә, киләчәгебез дә! Бәйрәмегез котлы булсын, кызлар!



Ramilia6958 Рәхмәт сезгә! Кечкенә чактан ук укыдык. Бер ел да язылмыйча калган юк! Элек әти-әниләр яздырды, хәзер үзем язылам. Соңгы вакытта бик яхшы якка үзгәрде «Сөембикә»! Укып туеп булмый! Рәхмәт сезгә! Гел шулай яхшы булсын иде! Уңышлар телим!

Liailiagalim Искиткеч журнал! Рәхмәт, «Сөембикә», гомерем буе озатып барасың. Кыйбат дип, бер тапкыр язылмыйча калган идем, икенче айда ук барып язылдым. Бик кадерле әйберемне югалткан кебек булды, йөрәк «жу» итте... Мәңге яшә, «Сөембикә»!

БЕЗНЕҢ ХАКТА — СОЦЧЕЛТӘРЛӘРДӘ

«Сөембикә» журналы 1999 елдан башлап үзенең бүләген булдырды. Бу бүләк Җир шарының теләсә кайсы кыйтгасында яшәүче, татар дөньясында – дәүләт эшчәнлегендә, иҗтимагый тормышта, мәгариф, югары мәктәп, журналистика өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен күренекле татар хатын-кызларына бирелә. Әлеге бүләк – кашына Сөембикә ханбикәнең мәшһүр рәссам Бакый Урманче ясаган сурәте уеп төшерелгән көмеш беләзектән гыйбарәт. Авторы – рәссамнарның Б. Урманче исемендәге бүләге лауреаты Наилә Кумысникова.

БЕЗНЕҢ ЛАУРЕАТЛАР

2000 ел
ГАФУРОВА Әлфинур Шәрәфетдин кызы (Санкт-Петербург), җәмәгать эшлеклесе, журналист, Санкт-Петербург шәһәрендә татар милли матбугатын торгызу һәм үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен;
САФИУЛЛИНА Флера Садрый кызы (Казан), галимә; татар телен пропагандалау һәм дәүләт теле буларак татар телен гамәлгә кертү буенча башкарган басма хезмәтләре өчен;
ТУФИТУЛЛОВА Роза Рәхмәтулла кызы (Казан), публицист, җәмәгать эшлеклесе, Дәүләт Советы депутаты; «Сөембикә» журналында, «Ак калфак» бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында аналарны һәм балаларны социаль яклау, хатын-кызларның хокукларын кайгырту буенча алып барган эзлекле эшчәнлеге өчен;


2001–2002 еллар
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗан кызы (Казан), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе; республикада хатын-кызлар хәрәкәтен оештыру, хатын-кызларның тормыш-көнкүрешен яхшырту, «хатын-кыз», «ана» исеменең абруен күтәрүдәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен;
КУДАШЕВА Фәридә Яһүдә кызы (Уфа), җырчы; төрле елларда татар халык җырларыннан төзелгән концерт программалары өчен;
УРАЛЛЫ Гөлтән (Төркия), җырчы, музыкант; төрки-татар фольклор сәнгатен пропагандалаудагы хезмәтләре өчен.

2003 ел
АПАКАЙ Шәмсия Хәсән кызы (АКШ), җәмәгать эшлеклесе; чит мәмләкәтләргә сибелгән татарларны берләштереп, аларда татар телен, милли рухны, милли моңны, милли гаилә нигезләрен саклап калуга юнәлдерелгән күпьеллык игелекле гамәлләре өчен;
КӘРИМОВА Нәзифә Харис кызы (Мәскәү), җәмәгать эшлеклесе, публицист; халыкара һәм милли журналистикада ирешкән казанышлары, Россия Федерациясе күләмендәге милли хәрәкәттәге хезмәтләре өчен;
ХӘМИДУЛЛИНА Камәрия Зиннур кызы (Казан), педагог, җәмәгать эшлеклесе; хатын-кызларның иҗтимагый активлыгын үстерү, аналар һәм балаларны социаль яклау, яшь буынга милли тәрбия бирүдәге эзлекле эшчәнлеге өчен.

2004 ел
ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ Флора Ваһап кызы (Казан), галимә: татар халкының рухи мирасын, халык эпосын, дастан-бәетләрен җыйнау, барлау өлкәсендәге гыйльми хезмәтләре һәм халкыбызның бөек рәссамы, скульпторы Бакый Урманченың иҗади мирасын саклауга, пропагандалауга, яшь буынга мәдәни-эстетик тәрбия бирүгә керткән өлеше өчен;
САБИРОВА Бибинур Нигъмәтҗан кызы (Төмән), җәмәгать эшлеклесе, журналист; «Ак калфак» бөтентатар хатын-кызлар иҗтимагый хәрәкәтен үстерүгә керткән өлеше, «Ак калфак» журналын чыгарудагы фидакарь хезмәте, татар гаиләсен, телен, гореф-гадәтләрен саклауда концептуаль проектлары, конкурслары өчен.

2005 ел
ЗАҺИДУЛЛИНА Лия Михайловна (Казан), тележурналист, диктор, җәмәгать эшлеклесе; халыкара һәм милли журналистикада ирешкән казанышлары, республика телевидениесе үсешенә керткән күпкырлы хезмәтләре өчен;
ПОТЕЕВА-ФАТЫЙХОВА Наилә Шакирҗан кызы (Әстерхан), табибә, җәмәгать эшлеклесе; читтә яшәүче татарларның милли аңын үстерүгә керткән күпкырлы гамәли хезмәтләре, публицистикада ирешкән казанышлары өчен.

Котлыйбыз!



"Сөембикә" беләзеге лауреатлары

"Сөембикә" журналы 1999 елдан башлап үзенең абруйлы бүләген булдырды. Аның сурәтен, шартларын басмабызның май санында укучыларыбызга җиткергән идек инде. Редколлегия үзенең 20 августта үткән утырышында "Сөембикә" беләзеген түбәндәге күренекле хатын-кызларга бирү турында карар чыгарды:



София Әсгать кызы ГОБӘЙДУЛЛИНАга – музыкада Сөембикә ханбикә образын тудырудагы олы хезмәте өчен.

София Гобәйдуллина – дөньякүләм танылган композитор. Казанда туган, Казан, Мәскәү консерваторияләрендә укыган. Җитди музыка жанрына мәшһүр А. Шнитке белән бергә революцион үзгәрешләр алып килде. Зур Энциклопедия сүзлегендә аның "Мемфис төне", "Марина Цветаевага багышлама" кантаталары, "Ишетәм... Тынды..." симфониясе һ. б. билгеләп үтелә.

Сөембикә ханбикәгә багышланган симфониясе – композиторның соңгы елларда язылган әсәрләренең берсе.

С. Гобәйдуллина Германиядә яши.



Фатма Музаффер КАЙАга (Төркия) – "Казан мәликәсе Сөембикә" дигән драма әсәре өчен.

Фатма Музаффер Кайа Төркиянең танылган драматургларының берсе. Анкара шәһәрендә туган. Төркиянең сәнгать сөюче кешеләре аны үзенчәлекле рәссам буларак та беләләр.

Казан ханбикәсе Сөембикәгә багышланган драма әсәрен Фатма Музаффер Кайа 1964 елда язарга керешә һәм 1968 елда тәмамлый. Шул ук елны "Төрек культура җәмгыяте" игълан иткән конкурста әлеге әсәре белән катнашып, беренче урынга лаек була.

"Казан мәликәсе Сөембикә" драмасы быел беренче мәртәбә Истанбулда сәхнәгә куела.

Фатма Музаффер Кайа Истанбул шәһәрендә яши.



Лена Рәшит кызы ГАЙНАНОВАга – Гаяз Исхакый иҗатын халыкка кайтарудагы зур хезмәтләре өчен.

Лена Гайнанова – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре. Башкортостанда туып үскән. Үзенең фәнни эзләнүләрен Г. Исхакый әсәрләрен иленә кайтару һәм дөньяга чыгару кебек игелекле эшкә багышлаган галимә. Аның тырышлыгы белән әдипнең беренче биш томы матбугатка әзерләнде. Ул "Зиндан" җыентыгын, күптомлыкның 1нче, 2нче томнарын бай искәрмәләр белән бастырып чыгарды. 70 ел онытылып торган бөек шәхеснең нәсел шәҗәрәсен төзеде.

Лена ханым Гайнанова – Г. Исхакыйның туган авылы Яшьчирмәдәге музеена нигез салучыларның берсе. Казанда яши.

2006 ел
БИКТИМЕРОВА Тәэминә Әхмәт кызы (Казан), галимә, җәмәгать эшлеклесе; XX гасыр мәгърифәтче татар хатын-кызларының эшчәнлеген хак тарихи кануннар нигезендә өйрәнү өлкәсендә алып барган гыйльми хезмәтләре, ул шәхесләрне пропагандалау буенча матбугаттагы публицистик язмалары, китаплары өчен;
ЛАТЫЙПОВА Мөслимә Хәбри кызы (Казан), эшмәкәр, Татарстан Республикасы икътисадын базар мөнәсәбәтләре нигезендә үзгәртеп кору, эшмәкәрлек хәрәкәтен җәелдерү, халыкны югары сыйфатлы милли азык-төлек белән тәэмин итү, эчкерсез хәйрия гамәлләре кылу буенча башкарган хезмәтләре өчен.

2007 ел
ГАЛИЕВА Гөлчәчәк Кәрим кызы (Казан), язучы; татар милли мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү максатларында кылган хәйрия гамәлләре, әдәбият-сәнгать эшлеклеләрен, татар китабын, милли матбугатны пропагандалау буенча алып барган иҗади-иҗтимагый эшчәнлеге өчен;
САФИУЛЛИНА Гөлзадә Гомәр кызы (Казан), җырчы, җәмәгать эшлеклесе; төрки-татар дөньясында яшь сәнгати талантларны ачу, барлау һәм үстерүгә юнәлдерелгән Халыкара «Сөембикә варислары» фестивале проекты, шушы максатта башкарган күпьеллык нәтиҗәле иҗади-иҗтимагый эшчәнлеге өчен.

2008 ел
ӘДИАТУЛЛИНА Эльмира Лотфулла кызы (Казан), журналист, җәмәгать эшлеклесе; татар милли хәрәкәтен, милли үзаңны үстерүгә керткән фидакарь хезмәтләре, мөселман хатын-кызларын берләштерү, аларның хокукларын яклау буенча башкарган гамәлләре һәм журналистика өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен;
ӘБСӘЛӘМОВА Фирүзә Хәсән кызы (Оренбург), журналист, җәмәгать эшлеклесе; Оренбург төбәге радио-телевидениесендә татар халкының рухи кыйммәтләрен пропагандалау һәм үстерүгә багышланган тапшырулар оештырудагы нәтиҗәле эшчәнлеге өчен;
ГЫЙРФАНОВА Лемма Исхак кызы (Мәскәү), педагог; Мәскәү шәһәрендә Муса Җәлил исемендәге этно-мәдәни мәктәп оештыру, татар халкының җәмгыяви ролен, ирешкән казанышларын киң җәмәгатьчелеккә җиткерү, татар милли мәгарифен үстерү буенча башкарган нәтиҗәле эшчәнлеге өчен.

2010 ел
ХӘКИМОВА Филисә Нәҗип кызы (Казан), журналист, җәмәгать эшлеклесе; халкыбызның милли үзаңын, телен, мирасын, гореф-гадәтләрен, рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклауда һәм үстерүдә керткән өлеше, халыкара бәйге-тамашалар оештыруы, «Ак калфак» оешмасының эшен яктырткан күпсанлы проектлары өчен;
САФИУЛЛИНА Фәвия Әхтәм кызы (Екатеринбург), журналист, җәмәгать эшлеклесе; читтә яшәүче татарларның милли үзаңын үстерүгә керткән күпкырлы гамәли хезмәтләре,
Урал төбәгендә яшәүче татар хатын-кызларын берләштерүе, журналистика өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен.

2011 ел
КӘРИМОВА Нурия Шамил кызы (Оренбург), эшмәкәр: татар милли мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү максатларында кылган игелекле эшләре, М. Фәйзи исемендәге Оренбург татар дәүләт драма театрына күрсәткән хәйрия гамәлләре өчен;
ДЖУМАЕВА Мөнирә Мәүлет кызы (Ульяновск өлкәсе), педагог, Димитровград шәһәрендә татар мәктәбе оештыруы, читтә яшәүче татарларның милли үзаңын үстерүгә керткән күпкырлы гамәли хезмәтләре, татар милли мәгарифен үстерү буенча башкарган нәтиҗәле эшчәнлеге өчен;
ӘХМӘДУЛЛИНА Рәзилә Ардинат кызы (Түбән Новгород), җәмәгать эшлеклесе; татар гаиләсен, телен, гореф-гадәтләрен саклауда концептуаль проектлары өчен.

2012 ел
ЧАЙДАМ Хәмидә (Финляндия), Финляндия татарларының «Исламия» җәмгыяте каршында эшләп килүче якшәмбе татар мәктәбендә күп еллар буе алып барган фидакарь эшчәнлеге, читтә яшәүче татарларның милли үзаңын үстерүгә керткән күпкырлы гамәли хезмәтләре өчен.

2016 ел
ӘБСӘЛӘМОВА Альбина Фаил кызы (Оренбург), эшмәкәр; халкыбызның гореф-гадәтләрен, милли һөнәрчелеген саклауга керткән өлеше өчен.

2021 ел
САДРЕТДИНОВА Ләйсәнә Илгиз кызы (Казан), тележурналист: татар халкының телен, гореф-гадәтләрен, рухи кыйммәтләрен пропагандалау һәм үстерүгә багышланган тапшырулар оештырудагы нәтиҗәле эшчәнлеге өчен;
ИБРАҺИМОВА Саимә Ибраһим кызы (Казан), язучы, тәрҗемәче, журналист; Сөембикә ханбикә образын өйрәнүгә һәм аның исемен, рухын саклауга керткән хезмәтләре өчен.

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР



Ирада ӘЮПОВА,
Татарстан Республикасы
Мәдәният министры

Театр, опера-балет, музыка, яраткан җырчылар, рәссамнар дөньясы... Китапханәләр, музейлар... Халкыбызның күңел җәүһәрләре булган күркәм йолалар... «Сөембикә» журналына шуларның барысы да сыеп беткән! Татар хатын-кызларының эстетик зәвыгын, рухи байлыгын, матурлыкны күрә белү сәләтен үстерә торган бик затлы, дәрәҗәле, сәнгатьчә югары кимәлдә бизәлгән бу журнал – үзе үк бәйрәм! Тышлыгыннан ук Әлфия Авзалова балкып өйләргә килеп керсен әле! Зилә Сөнгатуллина йә Винера Ганиева, Алсу Гайнуллина йә Дания Нурлы, Альбина Шаһиморатова, Аида Гарифуллиналар... Талантларга бай безнең халык. Ә «Сөембикә» журналы шул гүзәл затларның уңыш серләрен ача, рәссамнар картиналары белән таныштыра, Сабантуй, Нәүрүз бәйрәмнәренә алып китә, сәнгать кешеләре белән гамьле әңгәмәләр тәкъдим итә... Менә шундый саллы, тирән эчтәлекле, сылу, сөйкемле, сөемле журналы бар татар хатын-кызларының! Ул үзенә күрә матурлык энциклопедиясе дә, нәзакәтлелек әлифбасы да, әдәп-әхлак сандыгы да. Яраткан журналыбызны зур юбилее белән котлыйм! Гүзәллек дөньясы тудыручы иҗат коллективына яңадан-яңа уңышлар телим!

110

БЕЗНЕҢ ХАКТА — СОЦЧЕЛТӘРЛӘРДӘ

Гүзәл Галләмова Бүген «Сөембикә» килде безгә. Көтелгән открыткасы да бар. Рәхмәт яусын «Сөембикә»-леләргә! Журналның исе башка бу юлы! Целлофанга төрелгән булгач, миңа үзенчәлекле хуш исе югалмыйча килеп җитте. Бары «Сөембикә»не укыганда гына хатын-кызның саф хисләре кузгала сыман. Тагын шунысына игътибар итәм: хисле язмалар булгангадыр, тыныш билгеләре мул очрый аларда. Нокта, өтерләренә кадәр тәмләп укыйм!

gelnur_akhmadullina Әлфия апа төшкән тышлык. Балачагым хатирәсе! Җырлаганын радиодан гына ишетә идек. Телевизор юк. Бервакыт журналның шушы саны килде. И карадык инде Әлфия Авзалова дип. И әби белән әнинең сөенүләре! Рәхмәт сезгә!

rezeda10.59 Бер биш ел элек почта бүлекчәсенә кереп «Сөембикә» журналына язылмакчы булдым. Кердем дә, каталогтан «Азат хатын» журналын эзлим. Һич таба алмыйм! Почта хезмәткәрләреннән сорыйм, алар да эзли... Тәки таба алмадык. Өйгә кайткач кына барып җитте. Йә Раббым, нинди «Азат хатын» инде, кадими замандагы исем түгел бит! Яңадан барып «Сөембикә»гә язылып кайттым.



Нурия ҺАШИМОВА,
Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәни үсешкә ярдәм фонды Башкарма директоры

«Сөембикә» журналын хаклы рәвештә милли матбугатыбызның йөзек кашы дип атар идем мин. Затлы, матур, тирән эчтәлекле, акыллы басма. Ил күләмендә билгеле популяр журнал булып, Россия матбугатының алтын фондына кертелүе үк аның абруен сөйли. Гомер-гомергә әниләребезгә, әбиләребезгә балалар тәрбияләргә булышкан, гаилә ныклыгы сагында торган, йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне яшәткән, хатын-кызларыбызның кыйдай нечкә күңелен аңлый белгән журнал ул. Замана хатын-кызының югары таләпләренә туры килеп, укучыларын профессиональ югарылыктагы язмалары белән даими сөендереп тора. Татарстаныбыз илчесе булып, ерак-ерак илләргә барып җитә, башка халыкларда да соклану уята.

«Сөембикә»не бик яратам, үземне белә-белгәннән бирле журналны укып барам. Бер генә елда да язылмыйча калганыбыз юк. Балачакта әниләр һәр санын җыеп бара иде. Журнал белән бәйле матур хатирәләр саклана күңелдә, шулкадәр якын ул миңа.

Медиаиндустриядә зур тизлек белән барган үзгәрешләр чорында, массакүләм матбугат чараларында интернет, цифрлаштыру өстенлек иткән бер вакытта «Сөембикә» һаман да укучыларының көтеп алынган кадерле басмасы булып кала. Бүген журнал иң матур сүзләргә, иң олы рәхмәтләргә лаек. Гасырны узып нәшер ителгән яраткан «Сөембикә»безне зур юбилее белән котлыйм! Яңадан-яңа үрләр яулавыгызны, укучыларыгызның күңелен яуларлык язмаларыгыз белән сөендерүегезне, заман белән бергә атлап, иҗатта зур казанышларга ирешүегезне телим!



Фото: Анна Арахамия

ИХ, БУЕМ АЗ ГЫНА ОЗЫНРАК БУЛСА...



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Үземнән беркайчан да канәгать булганым юк… – ди ул.

Әйе, бу әңгәмәне Наилә ханым: «Мин күн мозаикасына яңа сулыш өрдем, бу сәнгать төрен яңа биеклеккә күтәрдем... Эре җөйне гамәлгә керттем, җөйсез читек тегүнең борынгы технологиясен торгыздым», – дигән сүзләр белән дә башлый ала иде. Һәм хаклы булыр иде! Татар каюлы күн өлкәсендә иҗат итүче әйдәп баручы рәссамнарның берсе бит! Казан кызы ул. Иҗади гаиләдә үсә. Әнисе Асия Хәйруллина – Татарстанның атказанган артисткасы. Әтисе Халит Кумысников – сәнгать белгече, танылган театр тәнкыйтьчесе, татар театрын өйрәнгән иң зур галимнәребезнең берсе. Наилә дә шунда – театрда эшләргә тиеш була, әмма язмыш аны башка сукмакка алып кереп китә...

Театр һәм гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы Наилә Халит кызы КУМЫСНИКОВАның Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык рәссамы дигән мактаулы исемнәре бар. Б. Урманче исемендәге бүләк лауреаты ул. Без аны «Болгари» беренче халык нәфис кәсепчелек иҗат остаханәсен оештыручы дип тә хәтерлибез. Казан Кремлен казу вакытында табылган болгар костюмын һәм XVI йөз татар гаскәриенең сугыш кирәк-яракларын реконструкцияләүне аңа тапшырулары белән дә горурланабыз. Журналыбызның «Сөембикә беләзеге» авторы да – Наилә ханым Кумысникова. Аның бер генә хезмәте дә башкаларныкына охшамаган: гаҗәеп нәфис, милли һәм искиткеч югары дәрәҗәдә эшләнгән.

Тагын – Тукай премиясе белән дә яшьтәш ул. 1958 елда әнисе Асия Хәйруллинага бирелүе ике бәхет елмая: республиканың иң дәрәҗәле бүләгенә лаек беренче лауреатлар арасына да эләгә, кызы да туа.



ТАМЫРЛАР Әнием Апас районының Иске Барыш авылында туган минем. Аңа 6 яшь булганда алар авылдан китәләр. Бабам – бүрекче, аягында нык басып торган крестьяннарның берсе була. Бүрекләрен ул Казанга илтеп сата. Башкалада аның тагын ике бертуганы яши, алар да тире сату белән шөгыльләнә. Берсе – Закир абый – сабын заводында приказчик булып эшли. Ул туганнарын алдан ук кисәтә: бик зур раскулачивать итүләр көтелә, ди. 1928 ел бу. Нәкъ шул вакытта Идел ярындагы беренче татар авылына – Кызыл Байракка нигез салына. Безнең бабай да гаиләсе белән шунда килеп урнаша. Беренче кышны землянкада кышлыйлар, ә аннан инде йорт салып керәләр. Закир абый бик кызык кеше була. Чибәр! Мин аны хәтерлим әле – күреп калырга өлгердем. Әниемне кечкенә чакта ук үз гаиләсенә ала ул. Сигез баланың бишенчесе була әни. Закир абыйлар турында еш сөйли иде ул, алар гаиләсен раскулачивать итүләрен дә. Сабын складларын тартып алалар (әни кечкенә чакта аккош рәсеме ясалган атаклы сабын кәгазьләре белән уйнаган), малларын сигез ат йөгенә төяп алып китәләр… 1930 елда әнинең әтисе мәрхүм була. Шуннан соң әнием кире Кызыл Байракка – үзләренә кайта. Без аның балачак хатирәләрен тыңларга ярата идек. Барыш – тау итәгендә урнашкан. «Мин әнинең кош баласы кебек суны югарыдан – таудан ташыганын хәтерлим», – дип сөйли иде ул. Ә без Кызыл Байракта суны көянтә белән чокырдан алып менүгә ияләшкән. «Әни, суны өстән алып төшмиләр, астан алып менәләр», – дия идек… Мәктәптә укыганда әни беренче тапкыр үзешчән сәнгатьтә катнаша. Һәм шунда сәхнә аның тормышы икәнен аңлый. Сәхнәгә гашыйк була! Музыка училищесын тәмамлый, музыка укытучысы булып эшли. Ә аннан сугыш башлана… Ике абыйсы фронтка киткәч, әнисенә иптәш булыр өчен ул тагын Кызыл Байракка кайта. Югары Ослан районының Нариман авылында мәктәп директоры булып эшли: дүрт сыйныфта берьюлы укыта; мичәнә ягар өчен утынны үзе яра, атны үзе җигә… Казан педагогика институтына кереп, ике ел укыгач, Горький урамы буйлап барганда ГИТИС студиясенә студентлар җыялар дигән белдерү күреп ала… Шул ук елны, шул ук курска укырга минем әтием Халит Кумысников та керә. Соңгы курста гына өйләнешә әле алар. Кызык өчен: без дә ирем белән соңгы курста кавыштык. Улыбыз да үзенең группадашына соңгы курста тәкъдим ясады. Эти – Мәскәү егете. Казанга ул эвакуация белән килә. Сәнгать училищесында укый. Ул да шул ук белдерүне күреп, ГИТИСка укырга китә. 1944 ел бу. Әле сугыш бара. Ә студиягә инде, күрәсез, кеше җыялар…

Эти ягыннан бабамнар, әйткәнемчә, Мәскәү татарлары. Сәүдәгәр бабамның хәтта Цветной бульварда кечкенә генә кибете дә була. Муса Бигиев белән алар дуслар була. Бездә бергә төшкән фотосурәтләре дә саклана: хатыны белән Муса Бигиев, әби белән бабай һәм кечкенә эти анда. Кызганыч, үзләренә кунакка килүләрен сөйләгәндә, Муса Бигиевның кем икәнен аңлап бетерми идем шул әле. 1930 елда кибетләрен, әлбәттә, тартып алалар. Мәдәнәдәге иркен, матур йортлары шулай ук советларга күчә. Әтинең тамырлары – шуннан, Түбән Новгород өлкәсеннән. Бабай 1944 елда ук мәрхүм була. Муса Бигиевның барлык дуслары кичергәнне аңа да кичерергә туры килә… Эти гаиләдә төпчек бала. Әби аны 46 яшендә таба. Мин аны хәтерлим диярлек – ул ахирәткә күчкәндә 4 кенә яшьлек булсам да. Әнинең әнисен менә күбрәк беләм. Күкрәктән аеру өчен дә әни мине Кызыл Байракка кайтарган. Ныгысын дип, ул мине озаграк – 3 яшькә кадәр имезгән. Җитлекмичә, җиде айлык кына булып туганмын бит – 1600 грамм гына булганмын. Әни мине гел шулай дип йөртте: «1600 граммым минем», – дип… Бала тудыру йорты Әҗем мәчетендә урнашкан була. Эти көн саен килеп, белешеп йөри: мин исәнме, юкмы… Гаиләдә ике кыз идек без. Җәмилә апам театр белгече иде, мәдәният министрлыгында эшләде. 28 яшендә вафат булды.



БАЛАЧАК 4 яшьлек чагымда эти миңа кылкаләм бүләк итте. Бик затлы иде ул: кыллары тимергә түгел, ә сөяккә утыртылган. Кытайда эшләнгән! Аның белән бик калын һәм шул ук вакытта бик нечкә линияләр дә ясарга мөмкин иде. Ул чакта ясаган рәсемнәрем хәзер дә исән. Эти барысын да саклаган! Рәсем ясавым ошый иде аңа. Бу сәләтем – аңардан. Сәнгатькә багышланган күпме китап сатып алды ул миңа! Тарихны яхшы белә иде. Бөтен патшаларның идарә иткән елларын әйтә ала иде. Третьяков галереясында үскән ул! Иң яраткан урыны шул иде әтинең. Мәскәүгә еш бара идек, аның әле үзеннән 15–20 яшькә зуррак апалары да исән иде. Барган саен музейларга, сәнгать галереяларына кермичә калмыйбыз. Бездә дә сәнгатькә карата мәхәббәт тәрбияләргә тырышты. Мин авырган көннәрдә кочагы белән төрле картиналарның репродукцияләре төшерелгән открыткалар калдыра. «Наилә, миңа аларны авторлары буенча төзергә кирәк. Эшлә әле шуны», – ди. Ә анда бөтен дөнья рәссамнары: Рембрандтны Рембрандт янына куям, Тицианны – Тицианга…

Ә әни исә театрдан кайтып керми. 4 яшькә кадәр мине балалар бакчасына бирмәделәр. Эти телестудиядә эшли бу вакытта. Казандагы иң беренче режиссерларның берсе ул. Балалар кирәк булганда, тапшыруларга мине дә алып китә. Берсе бик истә. Дәү әни ролендә Гөлсем Болгарская уйный иде. Үземнең әбиләрем чибәр иде минем, ә аның борынын Убырлы карчыкныкына охшатам. Тапшыру башланыр алдыннан: «Кызым, миңа дәү әни дип әйт, яме», – диде ул. Ә мин астан өскә таба карап, аңа нәрсә уйлаганымны әйттем… Рольне, әлбәттә, башкага бирделәр.

Икенче класста укыганда Камал театры сәхнәсендә Муса Җәлилнең кызы Чулпанны уйнадым. Без хәтта Ленинградка гастрольгә дә бардык. Петергофка барганыбыз, фонтаннар караганыбыз истә – шаккаткан идем. Балаларны гел каядыр йөртергә, дөнья күрсәтергә тырышырга кирәк.



УКУ Мәктәп елларын стена газеталары чыгару белән генә хәтерлим дисәм дә була. Казанның иң яхшы мәктәпләренең берсендә – инглиз телен тирәнтен өйрәнүче 122 нче мәктәптә укыдым. Җәмилә шунда укыганга эләктем бугай анда. 8 нче класста укыганда үземнең кем буласымны инде белә идем – рәссам. Өйдәгеләр моңа каршы булмады. Хәтта әкрен генә мине шуңа әзерләделәр: «Безнең Наилә

рәссам була инде ул», – дияләр иде җай чыккан саен. Дөрес, әни 10 класс тәмамлавымны теләде. Аның Грузиягә ялга киткән вакыты иде. Документларны тапшырырга үзем генә киттем. Училищены ике сәгать эзләгәч кенә таптым. Суриков институтын да шулай озак эзләп йөрдем. Нинди-дер сәер кабатлану… Ул вакытта училищеда Әнәс Тумашев та укыта иде. Алар әти белән бергә укыганнар, театрда да бергә эшлиләр. Әти аңа шалтыратып: «Сәләте булмаса, алма, зинһар», – дигән. Кердем һәм бик теләп укыдым! 1-2 нче курсларда безне Татьяна Юдина укытты, ул рәссам Аркадий Рыловның сеңлесе иде. Әнисен исә Фешин үзе укыткан! Аннан Ташкент институтын тәмамлап Хәнәфи Нәфыйков кайтты. Юлымда гел яхшы кешеләр генә очрады минем…

4 яшькә кадәр театрда үстем – бөтен спектакльләрне карадым. Иң ошаганы – «Казан сөлгесе» иде. 1969 елда әни театрдан китте. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты ачылган ел бу. Әни дә, әти дә аннары шунда эшләделәр. Әти режиссура факультетын җитәкләде, ул ГИТИСтагы кебек укытырга – чын профессионаллар тәрбияләргә тырышты. Курс спектакльләренә декорацияләрне миннән ясата иде. Театр сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен аңлату өчен дәдер. Юкка гына Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сынлы сәнгать институтына, театраль-декорацион бүлеккә укырга кермәдем бит! Профессор Михаил Курилко остаханәсендә белем алдым.



УҢЫШ Беркайчан да үзем турында «талантлы» дип уйлаганым булмады. Уема да кермәде! Һәрвакыт үзем нәрсә теләсәм шуның белән шөгыльләндем. Мәсәлән, костюмнар эшләү рәхәтлек бирә иде – аларны ясадым. Бу минем тормышым иде. Кемдер турында «ул талантлы итеп йөри», «талантлы итеп сулый» димиләр бит. Рәсем ясау миңа сулау, йөрү кебек үк. Мавыгам икән – бу эш иң мөһимгә әйләнә.

1983 елда Мәскәүдән кайткач, мине театрга алмадылар. Театр рәссамы булырга хыялланган кешене! Шундый зур фаҗига булды минем өчен… Сәбәбе, бәлки, әти белән бәйле булгандыр. Бик туры сүзле театр тәнкыйтьчесе иде ул. Начар актерларны, начар куелышларны беркайчан мактамады. Үз-үзенә каршы бармады – принципиаль иде. Театр аксакалларының берсе аның турында: «Мактарга авырмыни?!» – дигәнен хәтерлим. Әти өчен моның хыянәт белән бер булуын аңламагандыр инде ул… Әйе, алмадылар! Ә театрда эшләү теләгем шундый зур иде минем. Шуңа күрә бер тәкъдимнән дә баш тартмадым. Минзәлә театрында Әхтәм абый Зарипов белән Гогольнең «Өйләнү»ен куйдык, Бөгелмәдә – Горькийны. Камал театрында Батулланың «Елантау» әкиятенә декорацияләр ясадым. Фәрит Хәбибуллин татар яшьләр театры ачарга хыялланды – аңа эскизлар эшләдем. Сүз уңаеннан, әниләрне дә кайчандыр ГИТИСка шушы максат белән җибәрәләр бит. 1949 елда кайта алар, тик яшь тамашачы театры ачарга мөмкинлекләр генә табылмый. Ул чакта да, аннары да… Цехсыз, материалсыз – кул астында нәрсә бар, шуннан декорацияләр әзерләгән чаклар булды. Әмма миңа кызык иде! Казан сәнгать училищесында – театр бүлегендә укыта башладым. Талантлы шәкертләрем бар. Сережа Рябинин курчак театрының баш рәссамы бүген, Елена Ермолина мультфильмнар эшли. Рәссамнар Асель Исмәгыйлева, Диләрә Нәүрүзова, Ләйлә Җәләлетдиновалар да – минекеләр.

Ә аннан читекләргә тотындым. Элек аның күне май кебек йомшак булган бит. Камал театрында тузган бер читек табып алдым. Буяуга буялган! Ацетон белән ул буяуны юдым. Һәм шундый матур бизәкләр килеп чыкты. Кабатласаң иде боларны дип уйладым. Модельер таптым, итекче, тегүче, чигүче… Биш пар шундый читек ясадык. Күн мозаикасына шулай кереп киттем…

Мин бик нык татар орнаментын ясарга яратам. Иң кызыгы, училищеда укыганда орнамент буенча заданиелар еш була иде бездә. Күралмый идем ул дәресләрне! Кызыл чәчәк, янында ике яшел яфрак һәм шуның белән вәссәлам дип белә идем татар бизәген. Бөтен җирдә шушы орнамент иде бит. Шулкадәр примитив! Ә читекләргә тотынгач, татар бизәгенең байлыгына шаккаттым. Италияләр бер читтә торсын! Шуннан башланды… Фуад Вәлиевның «Казан татарлары орнаменты» китабын өйрәндем. Элементлар – бер нәрсә, композиция төзү кирәк бит әле. Мин беренче панноны аның китабы буенча эшләдем. Иң авыры бу орнаментлар белән уйлый башлау – кечкенә детальләрне бизәк итеп җыю булды. Ул орнаментларны бөтен җирдә ясыйм хәзер. Әгәр сезнең белән телефоннан гына аралашсам, кул астымда кәгазь, кулымда карандаш булыр иде һәм ясый-ясый сөйләр идем. Миндә ул рәсемнәр, бизәкләр бер әрҗә. Кошлар – алары аерым мәхәббәт! Күпме ясаганымның санын да белмим. Кайсылары әйбәт кенә килеп чыга, кайсылары юк. Әмма берсен дә ташламыйм – элемент буларак кирәк булулары бар. Әйткәнемчә, орнамент ясау – уйлау ысулы ул минем өчен. Яшьләргә дә орнамент аша уйларга киңәш итәм.



МӘХӘББӘТ Мәхәббәт үрнәге бар иде минем өчен: әти белән әни. Үзем дә белмичә әти кебек кеше эзләгәнмендер. Ирем хәтта тышкы кыяфәте белән дә аңа охшаган иде. Без өйләнешеп кайткан гына чакта әтидән: «Бу сезнең улыгызмы?» – дип еш сорадылар… Әни гел: «Кызым, мәхәббәт уза ул, ә берберең хөрмәт, ике арадагы дуслык кала. Ышанычлы, тугры кеше сайларга тырыш», – дия иде. Бар да ул әйткәнчә килеп чыкты.

Сашаны өйдә ничек каршы алдылармы? «Азат хатын»-ның иске бер санын таптым әле. Әни белән интервью бар анда. «Ике кызыгыз үсеп килә, булачак кияүләрегезне ничек каршы алырсыз икән?» – дип сорау биргәннәр. «Кызларым сайлаган кешеләрне, әлбәттә, кабул итәчәкмен», – дигән ул. Акыллы хатын иде әни. Иремнең рус булуы белән генә килешеп бетә алмады, билгеле.

Саша Рязаньнан иде. Бөтен институт аның эшләрен карарга йөрде. Ә мин йөрмәдем. Аны, беренче чиратта, яхшы кеше дип кенә белә идем. «Син чынлап та эшләремне күрмәдеңме?» – дип аптырады ул соңыннан. «Юк шул менә, талантлы булганың өчен генә кияүгә чыккан дип гаепли алмыйсың», – дип көлә идем. Күп еллар үткәч, социаль челтәрләрнең берсенә институт фондыннан эшләр куйдылар. Иремнең ул чактагы картиналарын шул вакытта гына күрдем.

Саша Рязаньда төпләнергә теләгән иде. Казанга ул, дөресен әйтәм, теләмичә генә кайтты. Бу көннәрдә Мәскәүдә күргәзмәсе бара. Ачылышында: «Ярый әле аны үзең белән Казанга алып кайтып киттең», – диделәр. Рәссам буларак шушында ачылды. Үзенчәлекле итеп ясый иде. Казанны да еш сурәтләде. Россиянең атказанган рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәре бар. Шундый җитми ул миңа бүген… 38 ел яшәп калдык. Кечкенә оныкка бабасы хөрмәтенә Саша дип куштылар. Икенче Александр Федотов үсеп килә.

Саша бөтен башлангычымны хуплады, булышты. Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәхнәсен дә бергә бизәдек. Әйе, тормышымда бу ансамбль дә бар әле… Алар башкаруында «Көмеш беләзек» биюен караганыгыз бардыр. Минеке бит ул. Кинәт кенә башыма килгән иде. Татар хатын-кызларының күбесе көмеш беләзек кия бит. Шундый биюне, биючеләрдәге яулыкларны күз алдыма китердем: ахырда яулыкларны тараталар һәм анда беләзектәге бизәкләр кабатлана… Идеям үземә шулкадәр ошады – иртәгәсен үк ансамбльгә киттем. Лима Кустабаева белән аңарчы таныш түгел идек. Урамнан барып кердем… Күн артыннан да шулай барып кердем мин, хәтта аның нинди булырга тиешлеген дә аңлата алмадым, йомшак булырга тиешлеген генә белә идем. Баш инженер Надия Кәримовна Мәмәдова: «Чын читекләр эшләргә телисезме, булышам!» – диде. Булышты!



ДУСЛАР Әлегәчә аралашып яши торган ике классташым бар. Берсе – Света исемлесе – Мәскәүдә яши, дини радиода эшли. Бу темага аның белән бик еш сөйләшәбез… Әмма иң якын дустым – апам Җәмилә иде, әлбәттә. Безнең яшь арабыз – сигез ел. Мин күбрәк аның белән үстем. Иртән балалар бакчасына әни илтеп калдыра, ә кичен йә Җәмилә үзе, йә аның классташлары, дуслары ала иде. Дөрес, әни белән гастрольләргә дә күп йөрдем… Авырып хастаханәгә кергән иде Җәмилә. Ул вакыт әле УЗИлар юк, рентген ярдәмендә тикшерәләр иде: аңа контраст матдә кертәләр, һәм апаның эчке органнарында коточкыч аллергия башлана. Ун көн эчендә китеп барды ул… Безнең өчен әйтеп аңлата алмаслык хәсрәт булды бу. Әти шуннан соң начар ишетә башлады. Җәмилә Ташкентта укыды, анда бик якын дуслары бар иде. Хәле авыр икәнен белүгә кайтып җиттеләр, безгә аны соңгы юлга озатырга да булыштылар. Ә аннан: «Ә хәзер билет алыгыз, безнең белән китәсез», – диделәр. Җәмиләнең кырыгына кадәр Ташкентта тордык. Кая гына йөртмәделәр алар безне! Иң авыр чагыбызны кичерергә ярдәм иттеләр.



БАЛАЛАР Бер генә бала белән калдык шул… Туксанынчы еллар бит – акча да юк, эш тә. Аннары әти белән әни авырый башлады. 2004 елда әнине озаттык, бераздан әтине… Җәмил күбрәк әтисенә охшаган. Ул Казан дәүләт төзелеш институтының дизайн факультетын тәмамлады. Аспирантурада укыды, берничә ел укытты да. Бүгенге көндә «Эрмитаж»-Казан үзәге белән хезмәттәшлек итә: афиша, баннер, чакырулар, программалар, күргәзмәләр әзерләү белән мәшгуль. Күн мозаикасы белән дә бергәләп шөгыльләнә без – ул бу эшне дәвам итәр дип өметләнәм. Оныгым Асиягә 13 яшь, сәнгать мәктәбендә укый, мультфильмнар ясый. Бик талантлы, креатив! Әмма аңа барысын да үзенчә эшләү кирәк, киңәшләремә колак сала дия алмыйм. Бу, мөгаен, дөрестер дә. Кечкенә оныгыма – Сашага 4 яшь, аның холкын әтинекенә охшатам: шундый ук нечкә күңелле.



АКЧА Әгәр шулай күп акчам булса, Сашаның күргәзмәсен ясар идем. Россиянең барлык шәһәрләрендә дә! Аның эшләрен бөтен кеше дә күрергә тиеш дип саныйм. Миңа аларның барысы да якын: һәрберсе белән тормышымның нинди дер бер өлеше бәйләнгән.



МАВЫГУ Берсендә Мәскәү журналисты шушы сорауны биргән иде миңа. Нәрсә дип әйтергә белми уйланып калган идем. Аннары җавап таптым: эшем – хоббием икән. Калган бернәрсә дә кызык түгел миңа. Нинди дер коллекция җыяргамы? Нәрсәгә кирәк ул? Кемдер бәйләү белән мавыга: бик теләсәм, мин дә бәйли алам, билгеле. Ә менә орнаментлар ясавымны хобби дип әйтергә буладыр, бәлки. Әйткәнемчә, кул астымда нәрсә бар, шуңа: салфеткага, хәтта кирәкле кәгазьгә дә ясарга мөмкин мин аларны.



КУРКУ Мине дә башка бөтен кешеләрне куркыткан әйберләр куркытадыр: якыннарны югалту, чирләр… Тагын – ялгызлык… Кайбер эшләрне эшләргә өлгермәү куркыта. Иремнең күргәзмәсен оештырырга, әнинең китабын чыгарырга телим, әтинекен… Сашаның эшләре тупланган каталог әзерлисем килә. Әти белән әнинең бик зур архивы калды миндә. Бу – шундый зур җаваплылык. Күптән түгел әнинең тууына 100 ел булды, туган авылы Барышта яңа клуб салдылар һәм аңа әнинең исемен бирделәр.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ Әгәр буем аз гына озынрак булса, яшәү җиңелрәк булган булыр иде, мөгаен. (*Көлә.*) Озын буйлыларның тормышлары уңышлырак кебек тоела миңа. Әни гел: «Кечкенә буйлы кешегә яшәүләре бигрәк авыр», – дия иде. Минем буем – 152 см, ә әни тагын да кыскарак – 146 см гына иде. Әмма әнинең бу «кимчелеге» аның өстенлеге дә булгандыр. Югыйсә сәхнәдә малайлар ролен уйный алыр идемени ул?! Бик көчле кеше иде безнең әни – ул беркайчан күз яше күрсәтмәде. Ә мин шундый еш елыйм. Көчлерәк булу беребезгә дә комачауламый, чөнки тормыш шактый катлаулы… Үземне артык яратам дип әйтә алмыйм. Бик күп нәрсә өчен ачуланам, бик еш тәнкыйтьлим үземне – «мин нинди молодец» дию юк. Югыйсә бу тормышта инде байтак эшләдем, күпкә өлгердем. Үземне яратмыйм, дигәннән. Гомер буе иренемнең зурлыгы ошамады миңа. (*Көлә.*) Әни дә: «Кызым, син иреңнең аз гына җыебрак йөр», – дия иде. Аның белән иреннәребез охшаган иде безнең. Гел ничек үзгәртергә икән дип уйлый идем. Минеке кебек зур иреннәрнең матур саналган, аны күпләр шулай махсус зурайтыр көннәр җитәр дип кем белгән?!

2000–2009 еллар



Яңа меңьеллыкны «Сөембикә» яңа җитәкче белән башлый: 2000 елның 7 февралендә журналга баш мөхәррир булып Фирая Равил кызы Бәдретдинова килә. Ул моңарчы «Яшь ленинчы» («Сабантуй»), «Салават күпере» һәм «Таһир-Зөһрә» басмаларында эшләгән талантлы журналист.
Фирая Равил кызы – журналга яңа сулыш өрә. «Сөембикә», әлбәттә, кыйбласына тугры кала. Ул җитәкчелек иткән чорда «Сөембикә»не «язмышлар журналы» дип атау гадәткә керә.
Журнал битләрендә читтә гомер иткән милләттәшләребез тормышы турында сөйләүче «Сөембикә» – сәяхәттә» дигән рубрика барлыкка килә. Журналистлар ерак-ерак командировкаларга чыгып китәләр: Оренбург, Төмән, Екатеринбург, Санкт-Петербург, Мәскәү, Әстерхан, Ульяновск...
«Сөембикә»нең яшьләр өчен «Асылъяр» кушымтасы чыга башлый (аның берничә саны укучыларга аерым басма булып та барып ирешә).
Бүген дөньяга килгән сабыйларыбыз ана телендә сөйләшерме? Безнең гореф-гадәтләрне, әхлак кагыйдәләрен үз итәрләрме? Шушы сорауларга җавап табу өчен журнал «Теле барның – иле бар» кушымтасын ачып җибәрә, күренекле галимнәр, язучылар, сәясәтчеләр, дәүләт эшлеклеләре белән җитди сөйләшүләр алып бара.
2001 елда журнал «Бәллүр каләм» республика бәйгесендә «Ел журналы» исеменә лаек була. Санкт-Петербургта узган VI Бөтенроссия матбугат фестивалендә хатын-кызлар өчен чыгарыла торган басмалар арасында иң яхшысы дип табылып, җиңүче дипломы белән бүләкләнә. Россия матбугатының алтын фондына кертелә.
Фирая Бәдретдинова баш мөхәррир булып торган чорда журнал Сөембикә ханбикәнең исемен халык арасына кире кайтару буенча нәтиҗәле эшләр башкара. Редакция Сөембикә ханбикә хакында фәнни, документаль һәм әдәби әсәрләрдән өзекләр тупланган «Сөембикә ханбикә» китабын бастырып чыгара. 2006 елда ул китапның тулыландырылган икенче басмасы чыга.
Редакция игълан иткән «Сөеклемә – сөю билгесе» дип аталган кульяулыклар бәйгесендә илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче укучылар катнаша. Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклау буенча «Сөембикә» оештырган чараларның тагын берсе – «Карга боткасы». Редакция коллективы аны үзе үткәреп, бәйрәмнең рухын журнал битләре аша укучыларга да җиткерә. «Сөембикә» журналында эшләү татар хатын-кыз журналистлары өчен һәрвакыт иң югары дәрәҗә дип саналган. Бу чорда журналда исемнәре укучыга яхшы таныш журналистлар Роза Камалетдинова, Филисә Хәкимова, Мәдинә Авзалова, Саимә Ибраһимова, Фәния Сабирова, Илсөяр Иксанова, Гөлсинә Хәмидуллина, Гөлнур Сафиуллиналар эшли.



«Сөембикә» журналына 75 ел тулган көннәр. Тарихны җанландыру!

Фирая Бәдретдинова турында уку өчен:



Сөембикә

№3 • март • 2000 ел ISSN 0869–1398

Күңелдә туган яз,
ак нур, ак теләк.





“Сөембикә”дә яңа баш мөхәррир

2000 елның 7 нче февраленнән “Сөембикә” журналында баш мөхәррир булып Фирая Равил кызы Бәдретдинова эшли башлады.
Фирая ханым 1959 елның 18 апрелендә Балтач районының Көекбаш авылында туган. Казан Дәүләт университетында журналист белгечлеге ала. “Яшь ленинчы” (“Сабантуй”) гәҗитендә эшли. “Сөембикә”гә “Салават күпере” журналыннан килде. “Салават күпере һәм Таһир-Зөһрә” басмаларында баш мөхәррир урынбасары вазифаларын башкарды.
Уңышлар телибез Сезгә, Фирая Равилевна!

“Сөембикә” журналының элекке баш мөхәррире Туфитуллова Роза Рәхмәтулла кызы Татарстанның халык депутаты булып сайлануы уңаеннан парламентның Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эше даими комиссиясе рәисе урынбасары сыйфатында Дәүләт Советына даими эшкә күчерелде. Роза Рәхмәтулловнаның 12 ел баш мөхәррир булып эшләү дәверендә басмабыз революцион үзгәрешләр кичерде, халыкара мәйданга чыкты. Шәфкатьле, эшлекле, булдыклы, абруйлы, дәрәҗәле, самими житәкчебез булдыгыз, Роза Рәхмәтулловна, рәхмәтебез зур Сезгә!

“Мин сезне яратырга дип килдем”

“Сөембикә” журналы редакциясенең бусагасын атлап кереп, моннан ары бергә эшләячәк хезмәттәшләрем белән беренче очрашу вакытында ихластан шулай диган идем. Сезгә дә, кадерле апалар, сеңелләр, тыңдашләрем, “Мин сезне яратырга килдем”, – дип әйтәм, чөнки чын күңелемнән Җир шарын мәхәббәт әйләндерә, кешене ярату яшәтә дип ышанам. Йә, әйтегез, фани дөнья кануннарына буйсынмыйча, өләшкән саен арта гына баручы тагын нинди могҗиза бар бу җиһанда?!. Якыннарыбызны, туганнарыбызны, күршеләребезне, хезмәттәшләребезне яратып яшәгәндә, аларның яратуын тоеп торганда, дөнья бик матур.

Әйе, бүгенге көнебез катлаулы, заманыбыз болгавыр булса да, дөнья көтүләре авыр булса да – матур дөнья. Хатын-кыз өчен дөнья көтү кайчан гына җиңел булды икән соң ул?

...Ятим үсеп, унсигез яшендә әтисе булырлык кешегә – Муса бабабызга кияүгә бирелгән, “Ике балага әни була алырмынмы?” – дип курка-курка капкадан кергән мәлендә үзен каршыларга чыккан дүрт баланы күреп, егылып китә язган, өлкәне белән яшьтәш булуларын белеп шаккаткан һәм аннары үзе дә биш бала табып, озын гомер кичереп, олы кызының – 61 яшендә дөньядан киткән әбиемнең вафатын ишеткәч, башка балаларын гаҗәпкә калдырып: “Йә Алла, бер хәсрәтем кимеде”, – дип, кулларын догага күтәргән Сукыр әбиемә – Бибисарага җиңел булганмы?

...Бабамны сугышка озатканда җиде бала белән калып, күп тә үтмәстән төпчеген җирләгән, газиздән газизләрен кичен сәкегә тезеп йокларга салганда: “Ятар корсак ятар, тиздән таң да атар”, – дип шаяртырга азапланган һәм алар йоклап киткәч, өсләренә капланып: “Кайсы баштан кителә башларсыз икән?” – дип сыкраган әбиемә – Бибиәсмага җиңел булганмы?

...Укыган елларында атнага алты бәрәңге белән яшәгән, педучилище бирә торган кашыклы онны янчыкка җыеп барып, атна азагында туганнарына кайтара торган, 43 нчене язында, күтәртмәле чабата белән юлга чыгып, боздан бозга сикерә-сикерә ташу кичкән, кайтып кергәч, исән калу шатлыгын өйдәгеләр белән уртаклашырга да өлгермәстән, әтисенең сугышта һәлак булу хәбәрен ишеткән һәм шунда: “Никләр генә суларга акмадым икән?” – дип илереп елаган сөекле әниемә – Фәүзиягә җиңел булганмы?

Мин монда үз җанымдагыларны әйттем. Сез үзегезнекен уйларсыз. Бәлки ул чор хатын-кызлары “ил белән килгән кайгы” дип, сабыр иткәндер. Безнең чор хатын-кызына эшсезлек, җәмгыятьнең катлауларга аерылуы кебек үзгә сынаулар кичерергә, үз хәсрәтен еш кына үзенә хәсрәтләргә туры килә. Бу рухи яктан да бик авыр.

Әйе, дөнья безнең бик азыбызга гына көчсезлегебез белән гүзәл булу мөмкинлеге бирә. Инде ир-егетләр рухыбызның көчле булуын таный һәм соклана икән, шунысына сөенеп, ир-егетләрнең дә иңнәре салынган мәлләрдә югалып калмавыбыз белән горурланыйк.

Шулай, дусларым. Үземнең дә әлегә кадәр көчсез булу бәхетенә тиешкәнем булмады. Менә хәзер бик авыр, җаваплы эшкә алынам. Сез миңа уңышлар теләсәгез иде.

Минем дә Сезгә теләкләрем бар. Һәммәгезгә сәламәтлек, гаилә бәхете телим. Парлыларга – тигезлек, сөю көткәннәргә – сөйгән яр, ялгызлыгына күнеп яшәүчеләргә – күңел байлыгы телим. Балалылар бала хәсрәте күрмәсен иде. Тагын бер теләгем – “Сөембикә”, “Сөембикә”без турында. Иртән хат ташучы калдырып киткән журналның тышлыгын гына күреп калудан да үзегезгә сиздермәстән күңелегезгә кунган сөенеч көне буе очындырып, эчтән җылытып торса иде, шул исемсез рәхәтнең ни икәнен беләсегез килеп, “Тукта, бүген нинди шатлыгым бар соң әле?” дип уйлаган уйдан исегезгә кылт итеп, “Сөембикә” килеп төшсә иде дә, кичке эшләрне тәмамлагач, аны укып ләззәтләнәсе минутларны ашыктыра башласагыз иде һәм, әлбәттә, журналыбыз сез көткән куанычны акларлык булса иде.

Бергә-бергә яшик.

Фирая БӘДРЕТДИНОВА.

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР

Кадерле «Сөембикә»леләр!

Татар журналистикасы тарихында аерым урын тоткан хатын-кызлар басмасы 110 еллыгын каршы ала. Редакция коллективын һәм журнал укучыларын ихластан әлеге бәйрәм белән тәбриклим.

Журналны белмәгән татар гаиләсе юк, чөнки аны алдыралар, укыйлар, басма битләрендә урын алган һәр язма татар хатын-кызы өчен кызыклы. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез арасында да «Сөембикә»не актив яздыралар. Бүген журнал классик басма вариантта гына түгел, популяр булган социаль медиаларда да актив. Тормыш тизләшкән чорда барлык трендларга туры китереп эшләү таләп ителә, чөнки алга таба яшьрәк аудиторияне журналга якынайту, журнал битләрен нәкь шул яшьләр тарафыннан фикер алышу мәйданы итү мөһим. Әнә шулай яңа буын укучы тәрбияләнә, басма яшәешен дәвам итә.

Шунысы аерым игътибарга лаек: журналның төрле елларда чыккан саннарын алып укысаң – әлеге дәвер өчен актуаль татар хатын-кызы образы турында фикер йөртергә мөмкин. Ул тышлыктан ук күренеп тора. Язмаларда да әлеге вакыт аралыгында татар хатын-кызын ниләр борчый, нәрсә хакында гәпләшә дигән сорауларга җавап табарга мөмкин.

Заман үзгәрүгә карамастан, тарих, милли мәсьәләләр, гаилә әхлагы, туган тел, тарих, дин, мәгариф һәм тәрбия сагында торучы, һәрвакыт актив, уңган куллы, акыллы һәм тәрбияле, укымышлы, булдыклы татар хатыны – журналның төп герое. Үсеп килүче яшь буын татар кызлары да югарыда санап үтелгән сыйфатларны үзләрендә тупласын, буыннар чылбыры өзелмәсен.

Туган телгә, милләтебезгә тугры булып, киләчәк буынга әлеге байлыкны тапшыручы нәфис, асыл затларыбыз! Һәркайсыгызга сәламәтлек, күңел көрлеге, иҗат уңышлары телим!



Шамил САДЫЙКОВ, «ТАТМЕДИА» акционерлар җәмгыяте генераль директоры



Хәерле көн, хөрмәтле редакция!

Мин бик күп еллар «Сөембикә»нең тугры укучысы. Миңа 73 яшь. Балачактан бирле укыйм. 1990–95 елларда гына алдырмадым. Калган 50–55 елын укып барам. Килгән көнне ирем укый, икенче көнне генә миңа эләгә. Мин «Сөембикә»не кайта-кайта укыйм. Миңа барлык сәхифәләр дә бик ошый, үрнәк булырдай гыйбрәтле журнал.

Сезгә зур хөрмәт белән,
Флюра ГАЛИМОВА. Богырыслан.

«Сөембикә» журналының әллә нинди сихри көче бар! Почта тартмасыннан алуга, бер мизгелдә бөтен мәшәкатьләр, авыр уйлар юкка чыга. Тышлыгын яратып сыпырам. Исе борынны кытыклый. Башта әле бернәрсә дә укымыйча, дүрт-биш тапкыр журналның битләрен барлыйм. Журнал белән бергә килә торган открытканы балачагадай сөенеп калганнары янына салып куям. (Күп минем балачак открыткалары!) «Сөембикә»не кулга алгач, бүген дә онытылдым... Һай, матур ла икән дөньялар! Яхшы кешеләр барыбер күбрәк ләбаса! Якты күңелләләр күбрәк! Шушы «күбрәк»ләр башкаларның да йөрәкләренә татлы ялкын сала алса иде... Матурлыкны таптамасак, тапламасак иде...

Илмира ГЫЙМАЕВА.
Саба районы.

Менә тагын журнал укучыларыгызны сөендереп, Яңа ел открыткасы җибәргәнсез. Рәхмәт! Сәвит заманыннан бирле открыткалар алган юк бит инде. Ул чорларда почта аша дисгәләгән открыткалар килүгә сөенә идекме икән... Әллә гадәти бер нәрсә дип кенә карадык микән... Ә хәзер сезнең открыткаларга сабый баладай куанам. «Карагыз әле, «Сөембикә» мине ничек котлый!» дип мактанып та алам ватсаптагы дусларыма, танышларыма. Иң яраткан журналыбызны кызыклы, гыйбрәтле, файдалы, сабак алырдай язмалар белән тутыручы «Сөембикә» кызларын бәйрәм белән котлыйм. Бер утыруда бертынга егылып укый торган журнал чыгаруыгыз өчен мең рәхмәт

Рәмзия ЗАРИПОВА. Әгерҗе.

САХАЛИННЫҢ КОЯШЫ


Фото: Анна Арахамия

«Чүпрәле районы Югары Каракитә авылы кызы мин. 1982 елда 19 яшемдә комсомол юлламасы белән Сахалинга чыгып киттем! Күрегез, чаялыгым да, кыюлыгым да бар, дөнья читенә – Сахалин кадәр Сахалинга китәм, имеш! Өч ай еладым... Әни белән язышкан сагыну-сагыш тулы хатлар әле дә саклана миндә».
«Сахалин өлкәсе татарларының төбәк милли-мәдәни автономиясе» иҗтимагый оешмасы советы рәисе Зәкия ВӘЛИТОВА Сахалин өлкәсендә кырык елдан артык гомер итә инде. Монда яшәүче татарларның кояшы ул. Зирәк, үткен, пакь кояшы!

Алсу ШАКИРОВА

Кычкырып укучы

Сахалинга буш кул белән килмәгәнемне хәзер бик яхшы аңлыйм. Ирешкән уңышларым, башкарган эшләремнең чишмә башы гаиләдән, балачактан икән. Җиде балалы гаиләдә кече кыз мин. Әтием Зыятдин – стаханчы шахтер. Әтисе вафат булгач, әнисе кабат кияүгә чыккан. Шахтада эшләүчеләргә ияреп, 14 яшендә Тулага киткән әти. Акча эшләп, бик күп бүләкләр белән чибәр, кәттә егет булып кайткан авылга. Шунда әнием Мәгъсүмәгә күзе төшкән дә инде. Ялга гына кайткан егетнең озаклап торырга вакыты булмаган, кире эшенә китеп барган. Ә Мәгъсүмәләр йортына әтидән яучылар килеп төшкән. Әби-бабай, ризалыгын биреп, әнине кияүгә җибәргәннәр. Җибәргәннәр шул! Агач чемоданын күтәреп, әни бер-үзе әти янына чыгып киткән. Бер ай барган ул Тулага! 1939 елның 6 маенда язылышканнар. Әти үзе эшләгән җиргә бөтен туганнарын, авылдашларны урнаштырган. Миңа бүген дә аларның балалары, очрашкач, рәхмәт әйтә моның өчен. Авыллар өчен бик авыр чор – ачлык еллары булган ул...

Сугышны да шунда, шахтада каршылаганнар. Әти алты ай хәрби учебкада әзерлек үтсә дә, аны резервта калдырганнар. Шахтада бригадир булып эшләгән. Йокы күрми авыр эштә эшләп бер күзсез дә калган.

1945 елның 9 мае Бөек җиңүне генә түгел, тәүге балаларын алып килгән яшь гаиләгә. 1953 елда өч бала белән туган авылларына әйләнеп кайтып төпләнгәннәр. Өч ел элек әтиләр яшәгән җиргә, – Тула якларына барып кайттым. Бөдрә талларга карап үзәкләрем өзелде... Сез үсәсез, әти-әни юк инде дип еладым... Гомер буе читтә сагынып яшәргә туры килде бит аларны.

Бик тәртипле гаилә идек без. Җиде бала белән башкача булыр иде микән? Тәрбияләми кара! Эшне дә белеп үстек, чыбыркы да күрдек... Иртән мәктәпкә киткәнче апа белән сыер савып, әнигә сөт кертеп китәбез. Энебез шахтер фонаре белән яктыртып тора. Кайтуга да эш көтә әле. Клубта танцы буласы көнне и тырышып эшлибез – ут уйнатабыз инде менә! Кич чыгуны әни әтидән сорарага куша. Әти: «Юк», – дип кенә әйтә, без, киемнәрне салып, йокларга ятабыз. Каршы дәшү дә, үпкәләү дә юк.

Безнең гаиләдә булган муллыгың белән бүлешү гадәте бар иде. Тимурчылар булып, тылда хезмәт иткән карчыкларны ашатабыз. Әни ашарга пешерә, ипиен кисә. Без мәктәптән кайтуга өстәлдә 10–15 әзер төргәк ята. Авылның икенче очына кадәр өләшәбез шул күчтәнәчләрне. Әбиләрнең иднәннәрен юам, кайвакыт иптәшкә кунып калам. Бәрәңге утыртканда да үз бакчабыздан элек күрше әбинекен утыртабыз, эти сукалап та бирә.

Бездә кеше өзелмәде. Күрше чуаш, мордва авылларына барып без, балалар, Пасхада йомырка җыябыз, алар безгә Корбан гаетенә киләләр. Әти-әни укымышлы булмасалар да, бөтен милләтне тигез күрергә, дус-тату яшәргә, хөрмәт белән карарга өйрәттеләр. Бер почта тартмасы тутырып газета-журналлар алдыра идек. Кич белән өйгә бабайлар җыела. Мине, сыер савудан да азат итеп, кычкырып укучы итеп билгелиләр. Яңалыкларны укып барам, берәр урында бабайлар туктаталар да, фикер алышалар. Мин тыңлыйм, сеңдереп барам. Болар берсе дә эзсез калмаган, күрәсең, киләчәгем өчен төпле нигез булып тормыш багажына салына барган...

«Максим буласым килә»

Борынгы тарихны исәпкә алмаганда, Сахалинга беренче татарлар 1928 елда килеп урнашкан, диләр. Нефть һәм күмер чыгару буенча дәүләт программасы нигезендә монда, башлыча, татарларны китергәннәр. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң сахалин татарларының яңа тарихы башлана. Татарстаннан эшелоны-эшелоны белән татарларны алып киләләр. Алар монда яңа татар авылларына нигез сала. Ай авылы – шундыйларның берсе. Соңрак исемен коммунистлар Советское дип үзгәрткәннәр. Биектау районы Дөбъяз авылыннан бик күп гаиләләр килә анда. Сахалинга болай гына эләгеп булмаган, махсус чакыру буенча гына кертәннәр. Вербовщиклар эшләгән Татарстан авылларында. Кешеләргә рәхәт тормыш вәгъдә иткәннәр, төсле фотолар күрсәтеп (ул вакытта ук төсле фото, уйлап карагыз!) кызыктырганнар. Чынбарлык кына алай төсле булмаган шул. Ат абзарына алып килеп урнаштырып: «Әнә сезгә урман, йортлар салыгыз», – дигәннәр. Сыер-бозаулар карарсыз дип алып киткән татарларга дуңгыз караткааннар. Мәктәптә балаларны русча укытканнар. Хәтта йортларга тикшерүчеләр килеп утыра торган булган – татарча сөйләшмәсеннәр өчен... Кызганыч, беренче, икенче буын бик тырышсалар да, ассимиляциядән качып кала алмаган. Телләре дә, диннәре дә сакланмаган. Татар булуларын фамилияләре генә искә төшереп тора...

> Чынбарлык башка төрле булган шул. **Тормышны ат абзарыннан башларга туры килгән.**

Мин Сахалин өлкәсенең Ударный бистәсенә килеп урнаштым. Монда яшәүче татар әби-бабайлары мине үз канаты астына алды. Бабам мулла иде, «Ясин» сүрәсен дә беләм, татарча бәетләр, җырлар башкарам, чипчиста татарча сөйләшәм, ризыклар пешерәм. Бик куандылар инде миңа. Үзләре озак еллар яши, минем яшьтәге балалары руслашкан, татарча сөйләшмиләр... Шул әбиләр мине мәет юарга алып йөри башлады. Куркам... «Курыкма, кызым, үлгән кеше сиңа тими ул», – дип яза әни, тынычландыра. Беренче югаңда су гына салып торасың, диде әбиләрем. Икенчесендә кәфенлеккә төрештем, өченчесендә: «Әйдә, гел су салып кына булмый, үзеңә юарга вакыт», – дип, үземә тапшырдылар. Менә нинди зирәклек! Хәзер бу эшләрне тулысынча үзем башкарам. Татар әбиләре: «Үлемтекләремә тимәгез, Зәкия генә башкарсын, аны тыңлагыз», – дип әйтеп калдыра балаларына.

Шәхси тормышыма килгәндә... Ульяновск шәһәре егетенә кияүгә чыктым, улыбыз Эльмир, кызыбыз Эльвира бар. Ләкин унөч ел яшәгәннән соң башка хатынга китте ул. Зур авырлыклар белән балаларны үстереп аякка бастыргач, үз тиңемне, мине чынлап кайгыртучы кешемне таптым...

Авырлыклар дигәннән... Улым 5 нче сыйныфта укыган чакта бер көнне урамнан тәре табып алып кергән. «Әни, бөтен кеше тәре таккан, минем дә тагасым килә. Эльмир исеме кирәкми миңа, Максим буласым килә», – ди. Күрше малаеннан исемнәр китабы да алган. Йөрәгем ярыла язды шунда... Икенче көнне үк билет алып Эльмирны әтиләр янына алып кайтып киттем. «Әти, тота алмыйм бу малайны, ярдәм ит, югыйсә югалтам аны», – дим. Эльмирны өч айга авылда калдырып киттем. Әти йомшак кына итеп аны намазга бастырды, мәчеткә йөртте. Эльмир татар телен өйрәнеп, «Мин – татар!» – дип килде авылдан. Без яшәгән җирдә мәчет юк иде. Һәр атнаны җомга көнне алты сәгатьлек юл узып, балаларымны Южно-Сахалинск шәһәренә мәчеткә йөрттем. Кунып калабыз да, икенче көнне кайтырга чыгабыз... Шундый авырлыклар белән дә диннән аермадым балаларны! Балаларым диндә, ураза тоталар, Эльмир биш вакыт

Барлык ишеклəр дə ачылды безгə, Камил Исхаковка рəхмəт!



■ 2022 елда Владивосток шəһəрендə «Дети Азии» халыкара спорт уеннары оештырдык. Проектның директоры – улым Эльмир. Татарстаннан тулы бер команда һəм 150 волонтер килде. Сахалин утравы һəм Приморье крае татарлары белəн аларны каршы алып, озатып йөрдек.

намаз укый. Оныкларыма исемне дə Казанга барып мөселманча куштырдылар... Балаларда телне, горефгадəтлəрне саклап калыр өчен дин иң җиңел юл бит! Догалар өйрəтеп, корбан чалып, гаетлəрне бəйрəм итеп, Мəүлет айларында мəҗлеслəр уздырып, сəдака өлəштереп күпме тəрбия бирергə була! Кызганыч, күплəр əле моны аңламый...

Боз кузгалды

Сахалин өлкəсе губернаторы Игорь Фəрхетдинов килгəч бик алга китте бу төбəк, нык нигез салынды, диңгезгə платформалар төзелде, инвесторлар тартылды. Аның белəн дə аралаштым. «Татар фамилиясе бит сездə», – дим. «Əйе, əтием татар. Репрессиягə элəгеп, бабаларым бу якларга җибəрелгəн», – диде. Чын татар канлы кеше иде ул. Хəзер аның нəсел тарихы, үзе, Сахалин татарлары турында китап язабыз.

Аннары Камил Исхаковны Ерак Көнчыгыш округының вəкалəтле вəкиле итеп билгелəделəр – татарлар өстендəге боз бик тиз кузгала башлады. Южно-Сахалинск шəһəренə күчеп килгəн идек ул вакытта. Төрле миллəт оешмаларына игътибар итə башладым. Телəсə кайсы миллəтне табарга була – татарлар юк! Тоттым да, татарларны берлəштерергə ярдəм итегез, дип, Татарстан Президенты Минтимер Шəймиевкə хат яздым. Монда телевидениедəн чыгыш ясап, татарларны эзлəвем турында хəбəр иттем. Хат эзлəре буенча миңа Бөтендөнья татар конгрессыннан чыктылар, Камил Шамилевичның ярдəмчесе элемтəгə керде. Беренче уңышлы эшебез – «Туган тел» уку-мəдəни үзəген ачу. Аны рəсмилəштерү, татар телле атамасын саклап калу өчен күпме юллар таптарга кирəк булганын үзем генə белəм.

2006 елның 21 мартында үзəк ачылышына Казаннан җырчы Фердинант Сəлахов килде. Уку-мəдəни үзəге ачабыз, бер китап та юк. Элек «Азат хатын» журналы артында артистларның фотолары чыга иде. Шуларны табып, кисеп алып стенага ябыштырып чыктык. Минем башымда – үзбəк түбəтəе. Казан артистын шулай каршыладык. Фердинант Сəлахов интервью биргəн иде шул чакта. «Монда тел дə, мəдəният тə сакланмаган», – дип сөйлəгəнен хəтерлим. Башымнан үзбəк түбəтəен салдырып атты да: «Татарлар таркау монда, эшлəве авыр булыр, лəкин син булдырасың моны, мишəр бит син!» – диде ул миңа. Татарлар белəн очрашырга, татар кешесен күрергə төрле районнардан миллəттəшлəр җыелды. «Йөрəгем атылып чыга, ахрысы, кызым», – дип, дулкынланудан елаучы бабайны һич онытмыйм...

Шуннан соң үзебезне күрсəтə башладык. Берничə көннəн Камил Исхаков татарларны җыйды. Мине дə чакырдылар ул очрашуга. «Сабантуегыз кайда?» – дип сорый. Килəсе елга уздырабыз Сабантуйны, ди мəчеткə йөрүче картлар (ул чакта алар барысын да үз кулларында тоталар иде). «Зəкия, быел Сабантуй үткəрəсез!» – дип, Камил Шамилевич бу эшне миңа йөклəде. «Үткəрəбез!» – дидем.

Бөтендөнья татар конгрессына рəхмəт: бик ярдəм иттелəр, сценарий язып бирделəр, артистлар җибəрделəр. Губернаторга хат яздык – барлык районнардан татарларны автобуслар белəн китерергə тиешлəр, тəкəлəр алдык, əлəмнəр чыгарасы атлар килде, татар солдатлары төннəн үк тəртип саклый... Иртəгə Сабантуй, ə мин елый-елый өемə кайтып барам. Булырмы, башкарып чыга алырмынмы? Мəшəкате тавык чүплəп бетермəслек...

Икенче көнне Сабантуй узасы мəйданга бөтен Сахалиннан халык агылды. Биш меңнəн артык кеше җыелды бəйрəмгə! Күпме татар ашлары пешереп алып килгəннəр! Стадион буйлап йөрибез, бер əби аягыма килеп егылды. Янына утырдым да кочакладым. «Сабантуй күрми үлəрмен дигəн идем, кызым», – дип елый... Кешенең шатлыгын, дəртен күрсəгез! Сахалин тарихында беренче Сабантуй иде ул. Хəзер ел саен уздырабыз. Быел менə унөченче балалар Сабан туе узачак төбəктə. Көрəш тə, уеннар да, чабыш та бар анда. Тик атка түгел, понига утырып чаба балалар.

Артыбызда Казан бар!

«Җиргə нык басып йөрегез!» – дип əйтə иде əти. Күрше малаен кыйнадым бервакыт... Карават астына кереп качтым. Теге малайның əнисе кереп җиткəн. «Ни өчен кыйнадың Рəфикъны?» – дип сорый əти. Чык, ятма анда, җавап бир, ди. Аңлатам. «Дөрес эшлəгəнсең! Бер мəртəбə суксалар, ике мəртəбə сук! Минем кызымдыр ич син!» Дөрес эшлəгəн, дип, əти мине яклый. Беркайчан үз эшеңнəн качма, җавап бир, дип өйрəтə. Татарларга кагылышлы нинди эшкə тотынсам да,

үз кирәгемә ирешәм. Шундый икәнемне беләләр! Ун ел йөреп булса да, зират та, намаз йорты да булдырдык. Дөрес санаган эшем өчен бер киртә алдында да туктап тормыйм, беркемнән курыкмыйм да. Аллаһтан кала!

Эшчәнлегебез белән бәйле бөтен атамаларга «Татарстан» исеме бирдек. «Татарстан» балалар ансамбле, «Татарстан» футбол командасы... Халыклар бердәмлеге көнендә төрле милләтләр арасында футбол турниры уза. Гел җиңү яулый безнекеләр! Улым да командада... Чит төбәктә татарлар белән эшләү әләм тотып, бәйрәмнәр оештырып йөрү генә түгел әле ул. Син анда һәр татар кешесе өчен туган якларының бер ядкаре. Син алар өчен дә җаваплы. Тормышның төрле чагы була. Балалар йортындагы татар балаларын, картлар йортындагы татар әби-бабайларын, хезмәт итүче солдатларны опекага алдык. Паркларга йөртәбез, чараларга чакырабыз, ризыклар пешерәбез. Картларның туганнары белән элемтәгә керәбез.

Кукмара районы Каенсар авылыннан Шәрәфетдин бабайның тарихын сөйлим әле. Гел түбәтәйдән йөри иде ул. Башын кырын салып, моңсу гына тәрәзәгә карап утыра... Картлар йортына үзем белән улымны да алып йөри башладым. «Әнә Шәрәфетдин бабаң, үз бабаңа барган кебек бар янына», – дидем. Колагы начар ишетә бабайның. Улым укый иде әле, буш вакытында машиналар юып, акча эшләп, бабайга колак аппараты алды. «Ишетәм! Ишетәм!» – дип куанганын күрсәгез! «Миңа Эльмир колак алып бирде», – дип әйтә иде. Бабай – сугыш ветераны, дүрт бала атасы. Әниләре үлгәч, фатирны сатып, картлар йортына озатканнар аны. 2010 елда бабайларны махсус программа буенча 9 Майга Казанга алып кайттым. 16 ветеран! Барысын да туганнары килеп каршы алды, кунакка алып киттеләр. Ә Шәрәфетдин бабайны алучы юк. Күз яшьләренә буылып елый бит карт. Нишләтәсең, фатир табып, бабай белән икәү урнаштык шунда. Алай да, журналист Энҗе Шәйхетдинова интервью алып, бабайны «Яңа гасыр» каналыннан күрсәттеләр. Сахалинга кайтып төшкән генә идек: «Безнең бабай бит бу! Бирегез аны безгә!» – дип, мине эзләп тә таптылар. Шәрәфетдин бабайның абыйсының балалары булып чыкты. Кайтам, ди бабай. Гариза язып, озатырга кеше табып, бабайны туган ягына кайтарып җибәрдем. Өч көннән бабай шалтырата, мин китмим, монда калам, документларны, пенсиямне күчер, ди.

Бик зурладылар Кукмарада бабайны. Абыйсының кызы Рәзилә, нәкъ эти ул, ди. Бабай Кукмарада мәчеткә йөргән. Ел саен корбан чалдырган. Миңа дип ниятләп, һәр елны бер сыер боты җибәрттерергә куша... Рәзилә белән сөйләшеп, ул итне шунда мохтаҗларга йә мәчеткә бирдерә идем. Моннан кайтучы татарларга Кукмарага кереп хәлен белдертәм. 63 ел яшәгән бит ул монда, сагына иде. Посылка белән диңгез кәбестәсе салам, шуны җыюда эшләгән булган ул. Гомер көзен туган җирендә каршылады, кәфенләп озаттылар. Һәр кешенең үз язмышы... Шуңа бер яктылык кертергә тырышам. Бабай үлгәч кенә кайта алдым Кукмарага. Чәчәкләр, гармуннар белән, президентны каршы алган кебек каршыладылар. Бабайның каберенә бардым. Исән чакта кайта алмадым, син үз туган туфрагыңда ятасың, дидем. Гел еладым... Бабайның рухы гел минем янда иде кебек.

Татарстанда туганнарым күп минем! Безнең малайны караган кеше бит сез... Әти-әниләрнең каберен карап торасыз... Абыйны җирләдегез, дип, гел яныма килеп, күчтәнәчләр биреп, рәхмәт әйтеп торалар...

Бөек шагыйрьләребез Габдулла Тукай, Муса Җәлилнең туган көннәрен билгеләми калмыйбыз, милли ашлар пешерү буенча мастер-класслар оештырабыз, грантлар отабыз. ТАИФ белән тыгыз элемтәдә эшлибез, алар безгә бик күп китаплар җибәрә. Якшәмбе мәктәбе эшли. Эшләремне тапшырып калдырырга яңа буын үсеп килә. «Ак калфак» оешмасын да яшь кызыбыз Гүзәлия Абдрахманова җитәкли.

Хәзер эшчәнлегебезнең төп өлеше махсус хәрби операция белән бәйле. «Сахалин за наших» халык хәрәкәтен дә без, татарлар, башлап җибәрдек. Бөтен милләтләр бердәм булып хәрби операциядәге егетләребезгә ярдәм итәбез. Апрель аенда үзем дә барырга планлаштырам. Әйе, куркыныч икәнен дә аңлыйм, ләкин үз күзем белән күреп кайтырга кирәк... «Сезгә рәхәт, сезнең артта Казан бар», – диләр безгә. Бар шул! Казан гына түгел, бөтен дөнья татарлары белән бердәм без. Бер генә мисал. Сахалин өлкәсеннән Махсус хәрби операциягә 333 доброволец озаттык. Волгоградта посадка ясарга мәҗбүр булган очкыч. Егетләрне накопительгә урнаштырганнар. Эчәргә сулары, ашарга ризыклары, авыручыларга дару юк. Безгә хәбәр килүгә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Марс Тукаев мине Волгоград татарлары оешмасы, Ильяс хәзрәт Бикмөхәммәтов белән элемтәгә кертте. Шул арада егетләребезгә биш йөз самса җибәрделәр, су китерделәр, дарулар алып килделәр. Менә нинди элемтә бездә! Менә, ичмасам, татарлар, диделәр башка милләт егетләре дә! Мондый мөнәсәбәт бер оешманың Уставында да язылмаган, безнең күңелләрнең уставы ул. Башкача булдыра алмыйбыз...



Кызы Эльвира һәм улы Эльмир белән.

Фотолар гаилә архивыннан.

PRESSA

АВЫЛ МУЛЛАСЫ



Лилия
ГӘРӘЕВА

Казан уртасында таныш көй ишетеп, барган җирдән туктап кала Лилия: «Бу бит шул көй! Бабай көе!» Дус кызы, аптырап, кулыннан тарта: «Киттек! Ник торасың?» «Тыңлыйк инде. Бабамның көе бит», – ди Лилия, тын калып. Кайчандыр Дамир бабасы яратып тыңлаган көйнең татарныкы булуын, «Су буйлап» дип аталуын шул көнне генә белә ул.



Мин – татар?!

Краснодар өлкәсенең Ейск шәһәрендә үсә Лилия Минаҗетдинова. Әтисе Радик, әнисе Әкълимә – икесе дә хәрбиләр. Бүген Дүшәмбедә алар, иртәгә – Камчаткада... Советлар иле киң, чикләре иркен. Кайсы кавем, кайсы милләттән син – ул чакта моның белән беркем артыгын кызыксынмый. Алар үзләрен совет халкы, диләр. Аралашкан телләре дә барысыныкы да уртак – русча.

Бары Дамир бабасы гына кызга ниндидер татарлар турында сөйли, аңлаешсыз телдә ят сүзләр әйтә. Аның тыңлаган җырлары да үзгә, озын үзләре, моңсу... Бабасы шул җырларны куйса, Лилиянең гел елыйсы килә. Сүзләрен аңламаса да, җырлаучы кемнедер бик сагынадыр, өзелеп көтәдер кебек тоела аңа. «Без – татарлар, – дип өйрәтә аны бабасы. – Безнең Мәккәбез – Казан». Бабасының сөйләгәннәрен тыңларга ярата кыз. 5 кенә яшьлек булса да, ишеткән берсен күңеленә сеңдереп бара. Тик тиздән кадерле кешесен мәңгегә югалта.

– Бабай булмаса, татар икәнемне белмичә әле күпме яшәр идем, – ди ул. – Күңелемдә зур бер учак кабызып калдырды бабам – татар учагы.

> *Ана теле дип, юкка гына әйтмәгән халык. Баланы күбрәк әнисе тәрбияли. Шуңа күрә теле дә әнисе сөйләшкән телдә ачыла.*

9 нчы сыйныфны тәмамлагач, Ейск шәһәренең педагогика училищесына укырга керә Лилия. Дәресләрдән соң намаз укырга йөгерүен, ураза тотуын курсташлары ниндидер бер экзотика кебек кабул итә. Тәүге намазын 1 нче класста укыганда ук кыла. Дин турында моңарчы берни белми яшәгән әтисе бер мөселман егете белән таныша. Ул аңа ислам дине, мөселманнар турында сөйли. Шул көнне намазга баса Радик абый. Бәләкәй Лилия дә аңа иярә.

– Намаз уку ошый иде миңа. Беркем дә ирексезләмәде. Тугызынчы класстан соң инде дин белән тирәннәнрәк кызыксына башладым, – дип сөйли ул балалык чоры, яшүсмер вакытлары турында.

– Казанга ничек килергә булдың? – дип сорыйм Россия Ислам университетын тәмамлап, лингвист белгечлеген алган яшь ханымнан.

– Әтинең Себердә яшәүче таныш имамы киңәш бирде. Казанда Россия Ислам университеты булуын да ул әйтте. «Лилиягә анда укуы файдалы булачак», – дип, әти-әниемне үгетләде. Без аңа кадәр Алабуга шәһәрендә бераз яшәп алган идек. Казанда да бер-ике тапкыр булгаладык.

Татарстан аңа бөтенләй башка ил булып тоела. Монда бар да үзгә – тел дә, гадәтләр дә, ризык та... «Үзең татар кызы, үзең татарча белмисең?» – дип шелтәләүләрен дә еш ишетергә туры килә. Шул бушлыкны тизрәк тутыру өчен татар теле курсларына языла. Сөйләшергә үк өйрәнә алмаса да, көндәлек иң кирәкле сүзләрне кулланырга, татарча аңларга өйрәнә.

Урау юллар аша – дингә

Тимурның да балачагы Лилиянекенә охшаш. Ул да Татарстаннан читтә – Чабаксар шәһәрендә туа. Әнисе Әминә апа – шәһәр кызы, татарча бер авыз сүз белми.

– 6 яшемдә әтием Фәритнең туган ягына – Әгерҗе районы Тирсә авылына күченеп кайтканчыга кадәр мин дә татарча белми идем, – дип башлады сүзен Тимур. Алгарак китү булса да, Тимур хәзрәт Латыйповның Питрәч районы Шәле авылында имам-хатыйп икәнлеген әйтеп үтим әле. – Ана теле дип, юкка гына әйтмәгән халык. Баланы күбрәк әнисе тәрбияли, ул гел әнисе янында, шуңа күрә теле дә әнисе сөйләшкән телдә ачыла. Татар телен миңа Тирсә малайлары өйрәтте, – ди ул.

Тимур хәзрәт – Россия Ислам университетын тәмамлаган югары белемле имам.

– Ни өчен шушы уку йортын сайладыгыз? – дигән сорауны бирәм.

– Әгерҗе якларында мәктәпне тәмамлаучылар алдында өч юл ачыла гадәттә. Йә син якындагы Ижау шәһәренә укырга китәсең, йә булмаса, Әгерҗегә барып, тимерьюлчылыкка укыйсың. Кыюраклар ерагын сайлый – Казанга килә. Мин менә өченче юлны сайлаучылардан булдым, – ди Тимур хәзрәт. – Дин белән ничек кызыксынып киттемме? Бишенче класста укыганда тарих укытучыбыз Әнисә апа Кәримова дини дәресләр оештырып җибәрде. Ул вакытта авылда түгәрәкләр аз, без, 20–30 бала, шул дәресләргә йөри башладык. Кызыклы итеп уздыра иде апабыз аларны: уеннар да уйныйбыз, чәйләр дә эчәбез. Укытучыбыз борынгы татар имлясын өйрәтә, сүрәләр ятлата.

2003 елда мәктәпне тәмамлап, Россия Ислам университетына имтиханнар бирдем. Ул вакытта миңа Разум бабамның Гөлфирә һәм Мөсфирә апалары бик булышты.

Укырга керешкәнче, башта ике ел әзерлек курсларында шөгыльләнергә кирәк иде. Ике ел эчендә никтер күңелем сүрелде. Консерватив дини уку йортында белем алу кызыксыз кебек тоела башлады. Кайнап торган студент тормышы белән яшәп карыйсым килде.

Киредән үзенең туган шәһәренә – Чабаксарга күченеп китә Тимур. «Улым, – ди аңа бабасы, – тормыш көтәрлек белгечлек ал». Әнисе Әминә ханым кебек повар-кондитер һөнәренә укый егет. Укып бетергәч, ашханәгә эшкә урнаша. Савыт-сабасын да юа, аш-суын да пешерә...

– Һәр өлкәнең үз баскычлары бар икән аның. Иң түбән баскычтан башламый торып, югары баскычка менә алмыйсың, – ди әңгәмәдәшем. Әлеге юнәлештә укуын тагын дәвам итә ул – техникум тәмамлый. Ит ризыклары цехының җитәкчесе була. Бишенче разрядлы ашчы дәрәҗәсен ала. Шул ук вакытта динне дә онытмый.

– Телләгәнемә ирештем дә шикелле. Авыз итмәгән ризыгым калмады, хезмәт хакым да әйбәт, ләкин күңелдә кабат бушлык. Минем эшем түгелдер шикелле, үземне тапмадым кебек... Казанны да бик сагына идем. Җәй чыккан саен монда килеп, Кабан буйларында йөрим, театрга барам. 2009 елда Казанга килеп, Ислам универси-

тетында укуымны кабат дәвам иттем. Җайланган тормышымны калдырып янәдән студент булу, тулай торакларда яшәү бик рәхәт булмаса да, күңелем шулай кушты.

Диплом алгач, тагын бер ел укырга Мисырга китә ул. «Гарәп телем начаррак иде. Шуны ныгытасым килде. Аны яхшылап белми торып, Коръәннең мәгънәсенә төшенә алмыйсың», – дип аңлата бу гамәлен Тимур хәзрәт үзе.

Үзеннән бер курс түбәнрәк укучы Лилия белән дә аларны Мисыр дуслаштыра. Лилия дә алдагы елны гына биредә булып, гарәп телен өйрәнеп кайта. Үзен кызыксындырган сорауларны егет аннан сорый.

Мөһаҗирләр һәм ансарлар

Казанда югары дини белем алып, Мисырда чарланып кайткан яшь егет алдына мәсьәләнең четереклесе килеп баса – кая гына мөрәҗәгать итеп караса да, эш юк. Үзе бик теләп Әгерҗегә кайтыр иде дә, әлегә урыннар буш түгел, көтеп тор, диләр.

– Шулкадәр эшлисем килә иде минем, – дип искә ала ул көннәрне Тимур хәзрәт. – Кая чакырсалар, шунда китәргә риза идем. Шул чагында, Аллаһның рәхмәте белән, үзем укыган уку йортында эшләүче Илнар абый очрады. Туган авылы Шәлегә мулла кирәк икән. Риза булсаң, кайтып, бер җомга уздырып кара, ди. Шәледә моңарчы булырга туры килгәне юк иде. Җомгага кадәр аның белән бергә кайтып, Наил абый Хәмидуллин белән таныштым. Наил абый – хәзер мин имамлык иткән «Заһир» мәчетен төзетеп бетергән кеше. «Безгә имам кирәк. Кайт, эшлә!» – дип, үзенең ризалыгын бирде. 2014 елның көзендә Шәлегә беренче җомга намазымны уздырырга кайттым. Шактый кеше килгән иде. Сынап-сынап караганнарын сизеп торам.

Шәле – үз менталитеты булган гаҗәеп авыл ул. Өч мең тирәсе халык яши монда. Татарстанның Шанхае дип тә йөртәләр аны. Шәлегә хәтта Явыз Иванның чукындыру отрядлары да үтеп керә алмаган. «Заһир» мәчетеннән тыш, XIX гасырның архитектура һәйкәле булып саналучы борынгы мәчете дә бар. Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдин дә шушы авылныкы. Мәчет каршында эшләүче мәдрәсә бүген аның исемен йөртә.

Бер-ике җомга уздыргач, Шәлегә яшәргә һәм эшләргә кайтырга карар кыла Тимур хәзрәт. Хәзергә яшәп торырсың дип, мәчеттән бер бүлмә бирәләр. Ул вакытта аның әле ишеге дә юк, пәрдә белән генә бүленгән. Ризык әзерләр урын да каралмаган. Шулай да тәвәккәлли яшь хәзрәт. Шәле аны алтын көзе һәм ачык йөзле кунакчыл халкы белән каршы ала.

Авыр чакта үзенә ярдәм кулын сузган, җылы ризыктан һәм кайнар мунчадан калдырмаган Фатыйма, Фәүзия апаларга бүген дә рәхмәтле ул. Мәчеттәге бүлмәдә тормыш итеп булмавы ачыклангангач, муллага Йолдыз урамыннан яшәп торырлык йорт тәкъдим итәләр. Мәккәдән Мәдинәгә күченүче мөһаҗирләргә ярдәм кулы сузган җирле халык – ансарларга тиңли авылдашларын хәзрәт. Ә үзе, килү белән, җиң сызганып эшкә керешә.

– Мин килгәндә мәдрәсәдә эш гөрләп тора иде инде. Аны 2009 елда ачкан булганнар. Ачылган көннән үк мәдрәсәне җитәкләп, биредә белем бирүче Мәрьямбикә абыстай Садыйкова белән кулга-кул тотынышып, матур гына эшләп киттек без, – дип, беренче көннәрен искә ала Тимур. – Үземә бернечә юнәлешне билгеләп куйдым. Шәле – Казанга якын, олы юл буенда урнашкан авыл. Килгән-киткән арасында төрле фикерле кешеләр, мәзһәбкә иярмәүчеләр дә булгалаган. Алар гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны инкарь итә, бабаларыбыз дөрес яшәмәгән, диләр. Беренче юнәлешем – мәзһәбкә иярмәүче әнә шул кешеләр белән эшләү булса, икенчесе – балалар белән элемтә иде. Мәдрәсәгә алты яшьтән алып тугызынчы класска кадәрге балалар килә. Бүгенге балаларның бар нәрсәләре дә җитеш, бүләк белән генә шаккаттыра алмыйсың. Аларга матур хис-тойгылар кирәк. Менә шул матур хисләрне мәдрәсәдән алып китсеннәр дип тырышабыз. Укуны тагын да кызыклырак итик дип, төрле чаралар оештырабыз. Тегү түгәрәге дә бар безнең, кулинария да.







Анысын үзем уздырам. Әле соңгы араларда вакыт кына җитеп бетми. Балалар белән печеньелар, вафлилар пешерәбез, коктейльләр ясыйбыз. Барысы да чын булсын дип, матур алъяпкычлар, башлыклар сатып алдык. Шәле – минем сынау полигоным, дип шаяртам кайчак.

Беренче квестны да Шәледә үткәрделәр. Шунда катнашкан балалар әле дә кызык итеп сөйли икән аны. Чаңгы, велосипед ярышлары үткәрүнең дә максаты шул була. Хәер, аларны оештырганда тагын бер максатны күздә тота әле хәзрәт – балаларның өйдән чыкмыйча, компьютер, телефоннарга капланып утыруы борчый аны.

Казанга, Болгарга сәяхәтләр дә кызык бер хатирә булып күңелләрендә саклана балаларның. Алар булмаган мәчет, күңел ачу үзәге, парк калдымы икән башкалада?! Хәтта Казандагы ифтар мәҗлесләренә дә барганнар. Ә каникул вакытында оештырылган лагерьлар тагын! Дини бәйрәмнәр! Бәйрәмнәрне шарлар белән бизәп, һәр бала өенә шар тотып кайтып китә икән ул көнне.

Узган ел беренче тапкыр балалар өчен мөселман Сабан туе узган. Анда катнашучыларга бер генә шарт куелган – кызлар яулыктан, ә егетләр кәләпүштән килергә тиеш.

– Башта ук Шәледә уздырырга кыюлыгым җитмәде. Миңнур Шәмсетдинов дигән дустым белән башта Чыты авылында уздырып карадык. Бөрбаш авылында Җәлил хәзрәтнең шундый Сабантуй оештырганын беләм. Алардан да өйрәнеп кайтасым килә әле, – ди хәзрәт.

Интернет һәм социаль челтәрләр – аның үзалдына билгеләгән өченче юнәлеше.

– Хәзер интернет заманы. Кулында телефоны булган кеше теләсә кайсы вакытта интернетка кереп, үз соравына җавап таба ала. Ә анда җавапларның дөресе, дөрес булмаганы бар. Кешеләр үзләрен кызыксындырган сорауларга җавапны бездән – хәзрәтләрдән ишетсеннәр дигән нияттән башланган эш иде бу, – дип аңлата Тимур хәзрәт «Заһир» мәчетенең Ютубта үз каналын ачып, тапшырулар эшләвен. Үзе төшерә, үзе монтажлый, үзе үк урнаштыра... Санга түгел, сыйфатка өстенлек бирә.



Авылдашларын табигатькә сак карарга өндәүне дүртенче юнәлеш дип атарга буладыр. Макулатура җыю, тотылган батарейкаларны чүплеккә ыргытмыйча, мәчеткә алып килеп тапшыруны да ул тәкъдим итә.

Үзебезне монда таптык

Шәледә бер ел эшләгәч, Лилиягә тәкъдим ясый егет. Хәзер әнә өч балалары үсеп килә. Әхмәтләренә – 6, Зарифага – 4 яшь, ә бишектәге Сәетләренә ай ярым гына. Әле абыйсы тирбәтеп килә талбишекне, әле апасы... Өй түренә бишек элүләре уйламыйча эшләнгән эш түгел. Бу – үз традицияләребезгә кайту. Атнага ике тапкыр мичкә ипи салулары да халкыбыз йолаларына ишарә. Ипи башы калдырып, арыш оныннан үзе пешерә аны Тимур хәзрәт.

– Беркайчан да авыл мулласына кияүгә чыкмыйм һәм авылда яшәмим, дигән сүзем бар иде, – ди Лилия. – Муллалар тормышы элек бик күңелсез булып тоела иде миңа. Җомга уздыралар да, ашка йөриләр. Сәдака акчасына гына яшиләр... Минемчә, мулла кеше җәмгыятьтә дә актив булырга, кызыклы идеяләр белән яшәргә, халыкны үз артыннан ияртеп барырга тиеш.

28 яшьлек Тимурда нәкъ шул сыйфатларны күрә ул.

– Шәлегә кайтканчы, авыл карын да күргәне булмаган аның, – дип шаярта хәләлен Тимур хәзрәт.

– Чынлап та шулай, – дип килешә Лилия. – Моңа кадәр бәрәңгене дә орлыктан чәчеп үстерәләр дип уйлап йөргән кеше мин. Татар ашларының күбесе белән Шәледә таныштым. Аңарчы бары кыстыбыйны гына белә идем.

Яшерми: баштарак авыл тормышы кызыксыз тоела яшь ханымга. Сөйләшергә дусты, күрешергә туганы юк.

– Авылда яшәүнең чын рәхәтен Зарифа тугач кына аңладым, – ди Лилия. Балаларыбыз татарлар арасында үсә дип шатлана ул. – Мин хәзер Кубаньга кайтып яши алмас идем. Анда бар да таныш, якын анысы, ләкин анда татарлар, мөселманнар юк. Балалар үз милләте янында үсәргә тиеш. Әти миңа кечкенәдән, татар егетенә генә чыгасың, дип тәкрарлады. Оныкларының татарлар арасында татар булып үсүе – иң зур теләге иде аның.

– Шәлегә кайтып, без чын татар тормышын күрдек. Аның нинди булырга тиешлеген белдек. Балаларыбыз татар бакчасына йөри, татар мәктәбендә укыячак, татар телен өйрәнәләр. Безнең шикелле, милли телдән, әдәбияттан, мәдәнияттән мәхрүм булып үсмәячәк алар. Шуңа шатланабыз, – диләр Тимур хәзрәт белән Лилия ханым.

Бүген алар үзләрен авылда чит дип түгел, үз итеп тоя. «Балаларыбыз монда туды, Шәленең үзенекеләр», – диләр. Хәзер яшәгән йортларын авыл халкы салып биргән. Үзеннән өлеш чыгармаган кеше калдымы икән ул чакта?!

Авыл уртасын ямьләп үсеп килүче чыршы аллеясы исә Тимур хәзрәтнең чынга ашып килүче хыялы. Чыршы аллеясы үстерү турында хыялланган ул.

– Кем белә, бәлки, кайчандыр моннан китәргә дә туры килер. Кеше китә, исеме онытыла, ә кылган эшләре гомерлеккә хәтердә кала, – ди хәзрәт.

– Кайда гына яшәсәк тә, ул авыл йорты булачак, – дип өсти Лилия. – Без инде авылсыз яши алмыйбыз.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Фото һәм видео: Анна Арахамия.

2009–2017 еллар



2009 елда «Сөембикә»гә баш мөхәррир итеп Ләйсән Рәфикъ кызы Юнысова билгеләнде. Ул – журналист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ләйсән Рәфикъ кызы «Сөембикә»нең җәмгыятьтәге ролен күтәрү, басманың кыйбласын саклап калу, аны замана хатын-кызларының мәнфәгатьләренә яраклы итеп үзгәртү өстендә эшли. Ул җитәкчелек иткән елларда журнал тагын бер тапкыр «Бәллүр каләм» иясе була. Республика матбагалары арасында үткәрелгән биш бәйгедә җиңүче дип табыла, ике тапкыр «Ел иганәчесе» буларак бүләкләнә.
«Сөембикә» журналы Бөтендөнья татар конгрессы, «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый берләшмәсе белән берлектә «Авыл кызы» Бөтенроссия конкурсын үткәрә. Аның сайлап алу турлары Самара, Оренбург, Түбән Новгород һәм башка өлкәләрдә, Чуашстан Республикасында уза. Журналның Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм ЗАГС идарәсе белән берлектә башлаган «Бергә – гомергә» уртак проектын да укучылар хуплап каршы ала.
«Сөембикә» үз битләрендә башлы-күзле булу белән бәйле милли йолаларыбыз турында сөйли, аннан гаиләдә бала туу белән бәйле гореф-гадәтләргә күчә. Редакция Казанның үзәк ЗАГСында һәм Кукмара районында милли гореф-гадәтләребезгә нигезләнгән шундый ике туй да оештыра. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Казан дәүләт технология университеты белән бергә уздырган милли кием дизайнерларының Халыкара конкурсы да – «Сөембикә»нең бу чордагы иң зур проектларының берсе. «International Fashion»да милли кием темасына иҗат итүче барлык дизайнерларга да катнашу мөмкинлеге туды. Киемнәрдәге милли бизәкләр, чигешләр – барысы да тамырларыбызга кире кайту иде.
«Сөембикә»нең Бөтендөнья татар конгрессы һәм аның каршында эшләүче «Татар гаиләсе» фонды белән бергә үткәргән «Әти һәм мин» конкурсы исә журнал битләрендә барды. Башкаларга үрнәк булырдай әтиләр турында сөйләнде анда. Бу конкурс та «Сөембикә»нең татар гаиләсен, гаилә институтын саклауга керткән саллы өлеше иде.
Бу чорда «Сөембикә»дә журналистлар Роза Камалетдинова, Мәдинә Авзалова, Асия Юнысова, Гөлнур Сафиуллина, Эльмира Закирова, Сөмбел Гаффарова, Лилия Гәрәева, Ландыш Әбүдәровалар эшли.



Редакция коллективы «Сөембикә» журналының йөз еллыгын үткәрү алдыннан.

Ләйсән Юнысова шигырьләрен уку өчен:



1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2009 ДЕКАБРЬ
№ 12

СӨЕМБИКӘ®

ISSN 0869-1398

ТӨМӘНДӘ ТҮГӘРӘК УЕН
II Бөтенроссия татар фольклоры фестивале

ЗИЛӘ СӨНГАТУЛЛИНА:
бәхет өчен талант кына аз

САРЫ ЮЛБАРЫС ЕЛЫ
яңа елда безне ни көтә

Гөлнара ГАЛКИНА-СӘМИТОВА:

КИТӘРГӘ ҖЫЕНМЫЙМ!



Баш мөхәррир сүзе



Февральне ирләр ае дисәң дә буладыр. Ватанны саклаучылар көнен шушы айда бәйрәм иткәнгә генә түгел бу – алар арасында хатын-кызлар да бар. Әнә, Кытайда яшәүче бер милләттәшебез генерал хәтле генерал дәрәҗәсенә үк ирешкән ләбаса. Рәгънә ханым Акмуллина ул – татар хатыны! Шундыйлар без – гаилә дисәң, гаилә учагын саклыйбыз, Ватан дисәң, ил тынычлыгы сагында торабыз. Афәт килә калса... Аяусыз сугыш елларының байтак каһарманы хатын-кыз кавеменнән.

Тыныч вакытта исә без җир җимертеп эшлибез, дөнья көтәбез, бала үстерәбез, якыннарыбызны карыйбыз... Ничек өлгерәбез дә, ничек чыдыйбыз тагын?! Безгә йөкләнгән һәр эшне (ә җаваплы вазифаларны дәүләт тә, җәмгыять тә, җитәкчеләребез дә безгә ышанып, күпләп йөкли) бөртекләп, җиренә җиткереп эшләгән кебек, бар борчу-хәсрәтләребезне дә нечкәләп, күңел тутырып кичерәбез бит без. Ә алар... – «көчле кавем» саналган тормыш иптәшләребез – яртысын күрми, белми, сизми дә кала кебек. Әйе, төрлечә яратылган без, төрлечә фикер йөртәбез, хисләнәбез, дөньяга төрлечә карыйбыз. Бер-беребезне ахыргача беркайчан аңлап та бетермәбез кебек. Ир затлары – Марстан, хатын-кызлар Венерадан, диләрме әле? Бер телдә сөйләшә башлаганчы ничә пот тоз безнең күз яше белән чыгарга да, ничәмә-ничә өмет тәлинкә кебек чәлпәрәмә килергә тиештер? Кайчандыр: «Гаилә тормышында беренче ун ел гына авыр», – дип шаккатырган иде мине бер бәхетле ир хатыны. «Шулкадәр түзеп торганнан соң аңлашып буламы?» – дигән соравыма җавап итеп: «Ә аннары инде барыбер була башлый», – дип көлгән иде ул.

Бүгенге заманда бергә дөнья көтүнең – һәрхәлдә, эш бүленеше юкка чыгып барган шәһәр җирендә – элекке мәгънәсе дә юк кебек. Ир кеше хәзер ауга чыкса да, кызык эзләп кенә чыга. Күп очракта хатын-кыз да ир хатыны булып, аны көйләп өйдә утыруның кызыгын да, кирәген дә тапмый. Йөзләгән мәшәкатенә өстәп, үзенә тагын бер йөкне ни дип алсын ди ул? «Тоткасыз чемоданың» ялкау, хыянәтче, көнче, йә эчкече булып чыкса? Шул инде, ташларга җәлләп, гомер буе күтәрәсең... Шулай уйлаучы уңган-булган туташ-ханымнар көннән-көн арта. Европа илләрендә исә ял көннәрендә генә очрашып, кунакка гына йөрешеп яшәүче парлар да күбәя, диләр. Шулай, курчак өе кебек чиста-пөхтә фатирына авыр ботинка кертергә, ышанычсыз ир канаты астына сыеныргга бер дә ашыкмый замана ханымнары. Егетләребезнең канаты сыегайдымы, әллә үзебез – артык мөстәкыйль шәхесләр – ул кысанлыкка сыеша алмый башладыкмы? Баланы да «үзем өчен» дип табучы күп – бөтен авырлыгы диярлек барыбер ана җилкәсенә төшкәч соң...

Ялгыз ана – үзе бер батыр булыр. Булдырыр ул: кыенлыкларны да сер бирми җиңеп чыгар, нарасыен да бәхетле итеп үстерер. Ләкин бер көнне, күгәрченнәр кебек гөрләшеп, балаларын ике яктан җитәкләп барган парны күреп, кинәт кызыгып, көнләшеп куяр. Бергә картаеп, бер-берсенә һаман гашыйкларча карап, «атасы», «анасы» дип яратып-хөрмәтләп дәшкән апа-агайны күреп, адашкан бәхетен юксыныр. Очрар әле ул, соң булса да очрар. Тормыш авырлыкларыннан талчыккан йөзеңә сокланып карар да баланы икенче кулыннан җитәкләп алыр. Шунда плюс белән минус, физика белән лирика, инь белән янь кебек капма-каршы булган яртылар кушылыр да... бердәм гаилә булып түгәрәкләнер. Хатын-кызга ышанычлы Ир, балаларга Ата үрнәге табылган гаилә – җылы ышык булып берегер.

Ирләр кебек үзе кырыс, үзе салкын карда да кояшлы балкышлар уйната алган бу айда инде безнең тормышка да кереп урнашкан тагын бер бәйрәм – Гашыйклар көне дә бар бит әле... Миңа насыйп ярны үзем шул көнне очраткан идем. Теге «беренче ун ел» инде узды – аның бер көне дә үкенечле булмады. Төрле телләрдә сөйләшәбездер, ул – акыл, мин хис белән дөньяга карыйбыздыр. Аңлашып яшибез икән, «тәрҗемәчебез» бар, димәк.

Ләйсән ЮНЫСОВА

«СӨЕМБИКӘ»не КОТЛЫЙЛАР



Кадрия ИДРИСОВА, Бөтендөнья татар хатын-кызлар форумы җитәкчесе, төбәкара «Ак калфак» татар хатын-кызлар оешмасы рәисе

Хөрмәтле Лариса ханым!
Кадерле «Сөембикә» журналы коллективы!

Төрки татар дөньясында беренче татар хатын-кызлар журналы буларак инкыйлабка кадәр нәшер ителгән «Сөембикә» журналына да 110 ел... Әлеге басманың татар ир-аты, меценат Ягъкуб Хәлили тарафыннан чыгарыла башлавы үзе үк тирән мәгънәгә ия. «Сөембикә» – милли журнал, ул безнең кадерле кунагыбыз. Хәтта ишекне шакымый да килеп керүче гаиләбез әгъзасы ул. Әйе, әйе, без аны бик тә көтеп алабыз, чөнки журналыбызның төп концепциясе – ирне – ир, баланы балачаклы итүче дә хатын-кыз, аның буыннан-буынга тапшырылып килгән тәрбиясе. Бу тәрбия эше – журналны журнал итеп тотучы хәзинә. Халкыбыз яратып куллана торган «май чүлмәге тышыннан билгеле» дигән әйтем дә журналыбызга туры килеп тора, чөнки аның затлылыгы, сыйфаты тышлыгыннан ук күренә.

«Сөембикә» канаты астында безнең «Ак калфак» Бөтендөнья хатын-кызлар берләшмәсе оеша, күренекле хатын-кызларның милләт файдасына кылган игелекле эшләрен бәяләү нисбәтеннән «Сөембикә беләзеге» булдырыла, «Гыйффәт туташ», «Киленбикә», «Бишек җыры», «Казан сөлгесе» кебек бөтен дөньяга яңгыраган бәйгеләр оештырыла. Шунысы сөенечле, Роза ханым Туфитуллова кебек өлкән буыннарыбыз салып калдырган бу традицияләр бүген дә дәвам итә. «Килен-кайнана», «Татар гаиләсе – үрнәк алыгыз» дигән бәйгеләр нәкъ шул традицияләрнең дәвамы. Гаилә, ана җылысын биреп торучы басмада ир-ат фикерләренә, татар гаиләсендә өч буын хәрәкәтенә киң урын бирелү дә басмабызны баета.

Журналыбызның үсүенә даими көч бирүче коллективны гасырдан артык хезмәт уңышлары белән бөтен татар хатын-кызлары исеменнән ихластан котлыйбыз, үзләренең гаиләләренә дә бөтенлек, иминлек телибез. Киләчәктә дә ышанычлы мәгълүмат чыганагы булып, укучылар арасында абруегызны саклап калуда тугры дуслар булыйк!



Filzafya «Бик матур журнал! Эчтәлеге дә, тышлыгы да! Яратып укыйм! Нинди матур кешеләр турында язасыз... Күңелем, җаным бәйрәме журналыгыз! Рәхмәт сезгә!»

bishmuncha_xudpyk «Сөембикә» тышлыгындагы хатын-кызлар идеал иде. Хәзер дә киләчәккә өмет һәм ышаныч тудыручылар. Тиккә генә Туфан Миңнуллин да Диләфрүзен сезнең журнал тышлыгына урнаштырмагандыр. Эзләнүле иҗатыгыз туктамасын, язмалар бик кызыклы, гыйбрәтле, файдалы».

Liabiba_zaynagutdinova «Элек урам буйлап почтальон туташлар газета-журналлар таратып йөргән чакларда әнием журналны алдыра иде. Укып чыгып, пөхтә итеп җыеп куя, ә без елларга кайткач рәхәтләнеп укыйбыз!»

liailiagalim «Тормышның ачысын-төчесен бергә татып яшәдек... Шулай дәвам итик! Яхшы хәбәрләр күбрәк булсын иде... Ни булса да, без сезне яратабыз, һәр саныгызны көтеп алабыз!»

БЕЗНЕҢ ХАКТА – СОЦЧЕЛТӘРЛӘРДӘ

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, язучы, драматург Халисә Сәгыйть кызы Мөдәррисова 1953 елның 25 апрелендә Ишембай шәһәрендә дөньяга килә. Балачагы Иглин районы Үктәй авылында үтә. Сигезьеллык белемне шушы авылда ала, урта мәктәпне Нуриман районы Байгелде мәктәбендә тәмамлый. Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлаганнан соң Илеш, Нуриман районнарында укытучы, мәктәп директоры, район советы секретаре, соңыннан озак еллар Нуриман районы хакимиятендә җаваплы вазыйфалар башкара, районның мәдәният бүлеге җитәкчесе булып эшли. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Нуриман районының шәрәфле гражданины. Һади Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Сигез китап авторы. Башкортстанның Нуриман районында яши.



Халисә МӨДӘРРИСОВА

ХЫЯЛЛАРЫМ – МӨЛДЕРӘМӘ

Кышкы иртә

Керфекләрен ачты бәсле иртә,
Агач ботаклары –
Әйтерсең лә
Йөнтәс койрык, йомшак бәбкәләр –
Әйлән-бәйлән уйнап таң нурында
Җиргә коя көмеш тәңкәләр.
Матур да ул һәм хәтәр дә салкын,
Чыңлый тынлык, ак кар шыгырдый.
Уян инде, дөнья, уян тизрәк,
Ныклыгыңны сынап кыш йөри.
Якты иртә җиргә бер Илаһтан
Иминлек һәм муллык үтенә.
Лач-лоч итеп сарай почмагында
Яңа туган бозау сөт имә.

Биктимер чишмәсе

Чишмәм, Биктимер чишмәсе –
Бәллүр күз яше сыман,
Таңнарында иңнәрендә
Күрәннәр өсте томан:
Бер чакыра, бер югала –
Ул белә сөю телен,
Шул томаннар арасында
Көянтәле яшьлегем.
Дөнья чиксез, хисләр биксез,
Төрле төстә буяулар,
Мөлдерәмә чиләкләрдә –
Ышанычлар, хыяллар:
Гомер буе булыр, дидек –
Гел безнеңчә дөньялар.
Өлешкә төште көмеш тә,
Тишекле бер тиен дә,
Кайчак үземчә җырладым,
Йә булмаса усал дөнья
Биетте үз көенә.
Тик шулай да, сыгылсам да,
Сынмадым давылларда,
Чөнки синнән эчкән суым –
Җелектә, тамырларда.
Биктимер чишмәсе суы
Язмышым йөге икән –
Татлы да, ачы да, ләкин
Кадерлерәк юк бүтән.
Ходай биргән шул язмышны
Бишегемнән гүргә хәтле
Иңнәремдә йөретәм,
Иелә,
Бөгелә
Көянтәм!

Карлар ява

Ашыга-ашыга тәүге карлар ява,
Соңлап килгән кышның карлары.
Каплый карлар, ләкин җылыталмас
Онытылып туңган алманы.
Карлар ява, ятимсерәп тора
Син алмасын өзгән алмагач.
Ул югалып калган, тик килешер
Тамырларын карлар каплагач.
Карлар ява, хәтеремдә һаман
Шау чәчкәдә бакчам – ак кына!
Тышта кышлар, тик онытма мине,
Онытма, дип күңел чакыра,
Яшь җанымның кайнар учларыңа
Яшем түккән яшьлек хакына.

Көзге сөю

Кыеклап яңгыр сибәли
Соңгы нур көлтәсенә,
Күшеккән кош кереп качты
Наратлар бөдрәсенә.
Усакларның кочагында
Чайкала көзге ялкын:
Тыелган сөю шикелле
Берчә ут, берчә салкын.
Көзнең соңгы җылы җиле
Тәрәз капкачын ачты,
Минем күңелем дә шулай
Бер болытлы, бер якты.
Өрфиядәй пәрәвездә
Тирбәлә каурый-канат.
Язда кем дә сөя ала,
Син мине көздә ярат.
Көземдә мине ярат.
Әдәбият – Бөек остаз,
Анда Азатлык хисе,
Күкрәк сөте һәм Гаделлек,
Сөю һәм Ватан көче.

Камиләгә

Кызым, кызым, кызчыгым,
Син шаян йолдызчыгым.
Күзкәйләрең – күл генә,
Йөзкәйләрең – гөл генә.
Бармакларың камыштай,
Йөрешләрең аккоштай.
«Нәнәй», «картатай», дисәң,
Мин дә бер карыш үсәм.
Әткәң-әнкәң пар канат,

Шул канатларны ярат.
Затлы, таянычлы бул,
Ныклы, ышанычлы бул.
Гомерле, иманлы бул,
Хәләлне җыйганлы бул.
Картайгач, ямьсезләнгәч,
Көйсезләнгәч, чирләгәч,
Күп кешеләр бизгәндә,
Инде гүргә иңгәндә,
Маңгаемда кул булса,
Җылы синеке булса,
Күл кебек күзләреңнән
Бер бөртек яшь саркылса,
Шул яшь җанны җылытыр
Һәм җәннәткә юл илтер.

Үткән гомер

Аккан судай үтә безнең яшьлек,
Туктатып та аны булса иде,
Йә булмаса кайгы, сагышларны
Агымсулар алып юса иде.
Искән җилдәй үтә безнең гомер,
Кабатлап та аны булса иде.
Йә булмаса килер картлыкларны
Искән җилләр кагып куса иде.
Кабатланмый җирдә бернәрсә дә,
Сорау, җавап артык, бу – төшенчә.
Сөю генә бары кабатлана,
Кабатлана һәрчак, тик – үзенчә!

Иҗат йорты тукраны

Иҗат йорты тукраны
Таңнан эштә – тук та тук.
Әйтерсең лә илһам килгән –
Булмый гына тукталып.
Гүя язу машинкасы
Артында япь-яшь шагыйрь
Зәгыйфь шигырен «әвәли»,
Йә булмаса олпат әдип
Бөек роман тәмамлый.
Икесе дә хыялында
Даһилыкка дәгъвалый.
Әллә мәхәббәт җырларын
Тактка сала җырчы,
Яки рәссам палитрада
Буяулар бутый төсле.
Нинди сихри тукылдау бу,
Бетмәс хезмәт тавышы,
Кемнең монда уй-хисләре,
Өметләре, сагышы.
Монда илһам посып тора
Һәр нарат арасыннан,
Монда камыш сөю көен
Нотага сала сыман.
Монда үткәннең рәшәсе,
Сөелми калган яр да...
Яшь шәүләсе чагылып китә
Кояшлы аллеяда.
Һавасына эленеп калган
Саф хисләрнең хуш исе.
Тукылдый шуңа тукран,
Бер минут тик торсачы!
Тук та тук йөрәгем тибә
Һәм язу машинкасы...
Тукран тәүбәсе монда –
Монда – шигырь дөньясы.

Артист

И сәхнәм, син минем язмышым,
Тәхетеңә булмышны багышлау.
Тәнемне, җанымны җылыттың,
Зал белән кушучы син – чаршау!
Мәңгелек тылсым син, и сәхнәм,
Җавабы табылмас бер сорау.
Чыңлый да, яңадан чакыра
Сөйгән яр шикелле кыңгырау.
Җиде кат күкләргә күтәрдең,
Аямый вулканга этәрдең,
Барлыгым, гомерем һәм мәгънәм,
Елаткан, көлдергән, уйлаткан,
Көл иткән, гөл иткән син – сәхнәм.
И халкым, кул чаптың, көч бирдең
Канатым ялкында көйгәндә,
Җанымны учыма йомарлап
Елмайдым елыйсы килгәндә.
Бер көнне баш исәм соңгы кат,
(Иҗатта гомерләр, ай, нәкыс)
Алкышлар, алкышлар, алкышлар...
Әйтегез: «Ял итә, ул чыгар,
ул – артист!
Чаршауны ябыгыз».
Хәзергә –
Тәнәфес...
Тәнәфес...
Тәнәфес...

Искәндәргә

Оныгым, оныкчыгым,
Наяным, колынчыгым,
Сары авыз кошчыгым,
Минем шаян чыпчыгым.
Күзең – кара бөрлегән,
Көтеп алган бергенәм.
Ялварып бер Ходайдан
Тартып алдык тын белән.
Картатасы караша,
Әйтерсең карт алаша:
Җилкәсендә йөретә,
Аягында селкетә.
Әткәң-әнкәң мәш килә,
Ә нәнәең – яшь кенә,
Яшәртүче нурдыр син,
Телләремдә җырдыр син.
Күгәрчендәй гөрлисең,
Барыбызга бер бит син.
Кулда ефәк кулъяулык,
Булсаң да син дүрт айлык,
Дөнья шавын тыңлыйсың,
Бер дә ятып тормыйсың.
Мөбарәк булды табын,
Йортка кот кайтты тагын.
Көл сарыган учакта
Яңадан дөрли ялкын.
Гомерле, бәхетле бул,
Иманлы, тәхетле бул,
Таянычлы, көчле бул,
Иң мөһиме – Кеше бул!
Телле дәүләт – гөлле дәүләт,
Көчле дәүләт, көчле дәүләт,
Җаны арык – Алып булмас,
Алып билен алып булмас.
Телсез халык – Халык булмас!

Туган як нинди була?

Әткәйле-әнкәйле дөнья
Хәстәрле, ашлы була,
Иң беренче тез канаткан
Кырчынлы, ташлы була.
Туган як нинди була?
Аксакаллы, Акъәбиле
Иманлы, нурлы була,
Ак алъяпкычлы мәхәббәт,
Канатлы, кошлы була,
Авыл курайлы, күперле,
Гармунлы очлы була.
Туган як нинди була?
Язмышлар да төрле була –
Кырык та кыллы була,
Челпәрәмә килгән бәхет,
Бормалы юллы була.
Туган як нинди була?
Уңган киленле яңа йорт
Токмачлы, онлы була,
Табын мул куллы була,
Җанында иярле ат яткан
Гайрәтле улы була.
Туган як нинди була?
Җитез һәм эшле була,
Хәләленә тугры яр һәм
Гаилә ишле була.
Туган як нинди була?
Талантлы, җырлы була,
Дошман килсә, илгә терәк,
Батыр һәм көчле була.
Туган як нинди була?
Ата-ана каберендә
Күзләре яшьле була.
Үзәк өзеп үзенә тарткан
Туган як шушы була,
Тамырлар көчле була!



Марат Әмирханов... Безнең Марат абый... Зур язучы, талантлы журналист-публицист һәм, әлбәттә, «Сөембикә» журналының алыштыргысыз кадерле кешесе Марат Әмирханов турында сүзебез. Бергә эшләгән елларда да, инде хәзер дә ул безнең редакция өчен һаман әти кебек бик якын. Актанышның Сөн буендагы Кәзкәендә туганга – «Сөн егете», «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесендә яулаган исеме белән – «Алтын йөрәкле ир-ат», редакциядәге каләм иясенең һәркайсына бик итагатьле, таләпчән, җитди урынбасар җитәкче була белгәнгә – «Остаз»... Әнә шулай дип тә йөртәбез үзен. Бу көннәрдә үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче легендар шәхес Марат Әмирхановны олуг бәйрәме белән котлыйбыз! Соклануыбызны әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов сүзләре белән җиткерәбез: «Яше белән генә түгел, кабатланмас бай иҗаты белән дә әдәбиятыбызда ханлык, әмирлек дәрәҗәсенә ирешкән олпат зат. Ул сүз сәнгатендә тирән эз калдырган адашлары Фатих Әмирхан, Әмирхан Еники традицияләрен уңышлы дәвам итә».



Марат ӘМИРХАНОВ

И ЧАБАТА, ЧАБАТА...

(Хикәя)

Сыер мөгезен сындырырдай бер чатнама суык көндә кемдер Мәүлиҗаннарның ишеген киереп ачты. Әүвәл өй эче аксыл томанлы бу белән тулышты, бераздан гына кемсәнең шыксыз вә куркыныч кара сыны шәйләнде.

Мәүлиҗан – тәэминатчы, сельпода эшли, көне юлда уза. Хатыны Гакифә белән кызы Әннүрә генә өйдә иде. Әннүрә аһ итеп әнисенең артына посты.

– Һитлер түгел! Мин – итальяно! Һитлер капут! – дип оран салды керүче. Аннан туп-туры ягулы тимер мич янына килеп, аякларын җылыга сузды. Үзе дер-дер калтырана, салкын эченә үткән, күрәсең.

Өстендә төсен җуйган тишек-тошык юка шинель, башына ниндидер шакмаклы чүпрәк ураган. Юбка кисәгеме, яулыкмы – һич аңламассың. Карачкыдан да калыш.

Хуҗабикәләр икесе тиң телсез калды. Чарасызлыктан фәкать бәбәкләре генә күз очтан бәргәләнә.

Гакифә тел күәсен югалтса да, аңы урынында иде әле. Уйлана торгач, бу башка да сыймастай гайре табигый табышмакның очына чыкты бит, бәгырь. Су юлында хатыннарның, Башкорт ягына нимес әсирләрен нефть эшенә куып китергәннәр икән, дигән сүзләре колагына кереп калган иде. Хак, бу шул фашист сыңары инде алайса, качак.

Җә Ходай, сугыш беткәч тә дошман кулыннан гомереӊ киселер, диеп кем уйлаган? Моннан котылулар юк, әнә ничек акаеп утыра, хәшәрәт. Буды, ташлады, шуның белән вәссәлам.

И Мәүлиҗаным, сельподан биргән мылтыгыңны күтәреп кайтсана, бәгърем, коткар бедне бу бәлаләрдән. Ант итәм, салгалауларыңа да, кул салуларыңа да бер сүд дә әйтмәс ием, солдаткалар янында бөтерелә дигән гайбәтне дә, чын икәнен белсәм дә, күңелемә кертмәс ием, бәгърем...

– Синьора, ипи...

Хуҗабикәнең өзгәләнүе шушы урында өзелде, качак, ач күзләрен тожрайтып, аңа текәлгән иде.

Җылынган, күрәсең, башындагы чүпрәген салып ташлаган. Кара-кучкыл ябык йөзендә кәгазьдәй үтә күренмәле кылыч борыны гына тырпаеп тора. Янә дә юка иренле иләк авызы. Фашистларның газета-журналлардагы сурәтләренә һич тә туры килми. Хәер, алданырга ярамай, дошман ул юха еланга тиң, төрле рәвешкә керә ала...

– Синьора, ипи...

Әлеге ялвару катыш мәел сорану Гакифәнең күңелендәге бозны бераз гына кыймшандырып җибәрде. Бу качак тиктомалдан кешегә кул сала торган залим адәмгә охшамаган охшавын дип, икеләнебрәк калды. Тәвәккәлгә бүре тимәс, дип, күңеленнән белгән кадәр Аятел-көрси догасын укына-укына урыныннан кузгалды. Олы авызлы таш касәгә сөт агызды, аннан бәрәңгегә тары көрпәсе кушып пешерелгән яшькелт ипине кулына алды... «Итальяно», бөтен гәүдәсе белән орчыктай тырпаеп, аның һәр хәрәкәтен очлы карашы аша үткәреп утырды.

– Менә, булганы шушы...

Әсир үтә бер комсызлык белән кушучлап ризыкка ябышты. Соса гына. Шундук ялмап та бетерде.

– Һитлер капут, мин – итальяно...

Гакифә аңа тагын да мулрак телем тоттырды. Үзе дә тынычлана төште, әсирне иркенләбрәк күзәтергә дә ярыйдыр, шәт. Күзләре зәңгәр икән, буй-сыны да ким-хур түгел. Карашы салам тутырылган зур ертык эрҗинкәсендә тукталды.

Җә, кадыйр, бу суыкта ничек шулай йөрмәк кирәк, оекбашы да юк, ичмасам, шәрә аяк...

Хатын-кызның мәрхәмәт вә кызгану тойгысы белән мөлдерәмә парә-парә кальбе мондый мескинә кадерсезлеккә түзеп тора димени! Гакифә йөгертеп кенә чоланнан иренең иске ыштырын, сатарга дип әзерләп куйган бер кием өр-яңа чабатасын алып керде дә, әсирне яңабаштан аякландырды. Тегесенең кулы бармагач, киндерәләренә кадәр үзе бәйләде.

Кимәката, ки чабата, / Чабата җайлы ята...

Качакның күзләренә яшь тулды, үзе ниндидер рәхмәтле сүзләр дә әйтергә тели кебек, тик авызыннан һаман шул мәгънәсез җөмлә бәселеп чыкты:

– Һитлер капут, мин – итальяно...

Бу манзараны әлегәчә читтән генә күзәтеп торган Әннүрәнең дә хәйрияви гамәлдән читтә каласы килмәде, күрәсең: «Күмердә пешкән бәрәңге бик тәмле була, кабыгын да әрчисе юк», – дип сөйләнә-сөйләнә чуен чүлмәктәге йодрыктай йомры бәрәңгеләрне берәмтекләп әсирнең кесәләренә тутырырга тотынды.

– Һитлер капут, сеньорита...

Әсир, кыюлыгы җитеп, ниһаять, кызга күтәрелеп карарга җөрьәт итте.

Мөселман мөслимәләре француз нимфеткалары кебек иртә өлгерә. Әннүрә дә язгы нәфис тал бөреседәй тулышып килә торган ак йөзле, кара чәчле, гөләндәм буйлы бер сылукай иде. Күкрәкләре сусыл пар алма рәвешенә кереп, бал тырларына, янбашларына җелек майлары кунып килә иде.

Әннүрә әнисенә охшаган. Гакифә дә ымсындыргыч буй-сынлы, туптай тыгыз күкрәкле, зөбәрҗәт йөзле чибәр зат. Тик авылда төпкә җигелеп тарта алмастай мондый нәзберек хатыннарны хуп күрмиләр. Ире дә мыскыл итеп, «Ак беләк» дип бәйләнә.

Мәүлиҗан үзе нык бәдәнле, көчле куллы, төптән юан кеше. Һәр эшкә кулы ята. Әйтик, тирә-якта аннан да остарак чабата үрүче юк, коеп кына куя. Базарда чират торып алалар. Кемгә ниндие: кыз-кыркынга – вак үремле, аксыл төслеләре, ир-атка – калын табанлысы, мариларга – киндерәсезе, очлы башлысы...

– Рус телен дә беләсез икән, өйрәтәләрме әллә? – дип кызыксынды Әннүрә.

Сорау әсирне уятып җибәрде, хәтта какча йөзендә елмаюга охшаш дулкынлану да шәйләнгәндәй итте. Һәм беренче мәртәбә «Һитлер капут»сыз гына җавабын җиткерде.

– Мин Рим югары дипломатия уку йорты студенты идем, рус, немец телләрен шунда өйрәттеләр. Гомумән, телләр миңа җиңел бирелә. Үзлегемнән аралашу дәрәҗәсендә француз, испан телләрен дә үзләштердем, – диде. – Сугышка тәрҗемәче-тылмач сыйфатында 43 нче елның азагында алдылар. Ике-өч айдан камалышта калдык. Менә хәзер Русиядә...

– Инәң-әтәң исән-саумы, хатының, бала-чагаң бармы? – дип төпчende Гакифә.

– Миңа әле егерме биш кенә яшь, итальяннар соң, мая туплагач кына башлы-күзле була, – дип көлемсерәде әсир. – Ә атам-анам укымышлы, хәлле кешеләр. Исәннәрме – анысы билгесез, безгә хәбәрләшү тыела бит.

– Сагынасыңмы?

– Сагындыра, туган-үскән диңгез буйлары көн дә төшемә керә...

– Безнең Сөн буйлары да диңгезгә биргесез, – диде Әннүрә, әсирнең сүзләрен ошатмыйчарак. – Кыш кына үтсен...

– Мондагы кышның иге-чиге юк икән шул.

Әсир кулларын янә мич кызуында җылытып алды да:

– Минем дә бер соравым бар иде, мөмкинме? – диде.

– Мөмкин, мөмкин булмыйча суң, – диде Гакифә. – Сүз көрәштерүне җенем сөйми...

Әсир әүвәл аякларын суза төшеп, чабаталарын пескәен назлаган бала кебек озак сыйпаштыргалап торды, аннан:

– Бу искиткеч уңайлы аяк киеме ничек дип атала?

– Чабата, – диде Әннүрә борынын чөебрәк. – Ча-ба-та...

– Ча-ба-та, – дип кабатлады әсир. – Исеме җисеменә туры килә икән, ча-ба-та!

Гакифә әңгәмәгә такмак белән кушылды.

Ак чабата, ак оек, / Чабата башы кыек, / Сыдылып киткән кара мыек, / Ничек үбәрсең кыеп?

– Браво, синьора!

Әңгәмә шушы урында өзелде, котырынган эттәй ажгырып, өйгә мылтыклы хәрби килеп керде. Өстендә ак тун, башында колакчынлы бүрек, аякларында соры киез итек.

Килеп тә керде, килә-килешкә әсиргә тибеп тә җибәрде.

– Сволочь!

Шунда ук, атылып диярлек, ике арага Гакифә килеп кысылды, чөнки тимер мич аварга җитешеп кыйшайган иде.

– Ут чыгарасың бит, пырдымсыд.

– Бу хәсисләр белән ни генә булмас, – диде хәрби, мичне урынына утырткан арада. – Гафу итегез...

– Кешегә кешечә карарга кирәк, әсир дигәч тә...

– Фашист – кеше түгел ул, апасы, яклап маташма.

– Ул бит итальяно! – диде Әннүрә.

– Һы, иштең ишәк чумарын, бик беләсең килсә, фашизм чумасының бишеге – Италия. Беренче фашистлар партиясен диктатор Муссолини оештыра. Һитлер бераздан гына аның үрнәгенә иярә.

Хәрби, типкәли-типкәли, әсирне алып чыгып китте.

Шулай да итальяно, күз очтан гына булса да, рәхмәтле карашын юлларга җитеште үзе. Ә иреннәре:

– Сеньорита, – дип пышылдады.

* * *

Мәүлиҗан ут алгач кына кайтты. Кызмача иде. Андый чакта аеруча юмарт ул. Әле дә чишенер-чишенмәс үк гимнастеркасына тагылган орден-медальләрен чулпыдай челтер-челтер уйната-уйната (ул сугыш бүләкләрен башкалар кебек сандыкта тотмый, күкрәгендә йөртә):



– Мин барында сыйланып калыгыд, – дип, өстәлгә күчтәнәчләрен сипте. – Осколка, сабакы, тагын кудгалды, насила тынычландырдым, җәрәхәте тагын...

Бу гадәти зар – күнегелгән зар. Шуңа күрә өйдәгеләр аны колак очыннан гына очыртып җибәрде.

Аларның яңалыгы менә яңалык, ичмасам, теләсә кемне аяктан егардай яңалык! Тик әлегә авызда тәм-том шул кулдан тора, мактанырга ирек бирми. Ә тел кычыта.

Әннүрә чәшкесен читкәрәк төртеп куйды да:

– Әткәй, бедгә бүген Һитлер керде, – диде.

– Таптың сүд, башыңа тай типтеме әллә, – дип, эре тешләрен күрсәтеп көлде атасы. – Шаяртамын дигәч тә теге...

– Фашистларның барысы да Һитлер инде, – диде Әннүрә. – Башкорт ягына нефть эшенә немец әсирләрен китергәннәр бит, шуларның берсе качып бедгә керде. Миңа ышанмасаң, әнә әнкәйдән сора. Ул аны сөтле ипи белән сыйлады, аягына ыштыр урап, яңа чабата кигедде.

Мәүлиҗан хәмерле стаканын авызына тигезгән җиреннән бүленеп калды. Калын иреннәре, кабыгына сыеша алмыйча өреп кабартылган каз куыгы рәвешенә кереп, бүселеп чыкты, бүкәндәй тулы гәүдәсе хатыны ягына авышты.

– Минем чабатаны фашист көчегенә бирдеме?

Ул үзен-үзе белешмичә, алпан-тилпән килеп, ишек катындагы чөйгә эленгән мылтыгына үрелде.

– Пристрелю!

Гакифә тиз генә өстенә сырмасын элде дә урамга чыгып йөгерде. Сыналган алым, ул иренең зәһәрле ярсуын шулай гына баса ала иде.

– Әткәй, дуамалланма, әткәй, – дип, кызы атасын тынычландырмак итте. Күзләрен кан баскан исерек ата, сүз тыңлаудан үткән иде инде, әнә мылтыгын кора да башлады...

– Пристрелю, гады!

Әннүрә дә япа-ялангач килеш өйдән атылып чыкты да, күршедәге Әкрәметдин бабайларга кереп ауды.

Озакламый алар артыннан Мәүлиҗан үзе дә килеп җитте. Ишекне ватардай булып дөбертәтә башлады.

– Чашты әткәй бүген, – диде кыз, – күзе-башы тонган...

– Качак әсир мәрәкәсе, – диде Гакифә, – телеңне тыя белмәдең бит, ачык ауыд.

– Ач, Әкрәметдин агай, ач, мин ул кү...не барыбер дөньяда яшәтмим, – дип, аты-юлы белән сүгенде Мәүлиҗан. – Чабатамны фашистка биргән, ашаткан-эчерткән... мужыт аягымны шул фашист аткан пуле чәрдәкләгән булгандыр әле, ә ул сатлык җан, гадина, пристрелю...

– Әүвәл мылтыгыңны ташла, күрше, аннан аңлашырбыз, – диде карт ишек аша, – акылыңа кил.

– За Родину, за Сталина!

Мәүлиҗан шарт та шорт ата башлады.

Ату тавышын ишетеп җыелган ирләр аны Авыл советына илттеләр. Төнне ул сак астында үткәрде.

Иртәгесен эшеннән кудылар.

Фронтовик Мәүлиҗан Гатауллин сугышта алган яралары, осколок-ярчыклары, баш миенә зыян салган контузиясе, хәмер чире һәм дә чабаталары белән япа-ялгыз калды.

Сугыш беткән, җиңү яуланган, инде аның кебекләрнең түрәләр өчен кирәге калмаган иде.

Шул тибелгән халәттә тиздән аны хәмер вә ялары бу дөньядан алып та китте.

* * *

Әннүрәне ашыгыч рәвештә ВЛКСМ комитетына чакырып алдылар. Институтның комсомол секретаре Рәшит Мусаев белән моңа кадәр күзгә-күз аралашканы юк иде әле. Шуңа күрә ишеген дә курка-курка гына шакыды.

– Менә, Гатауллина, синең досье белән танышып утырам әле, – диде нииндидер шикле көрсенү белән. – Өстәвенә, без якташлар да икән әле, Ык ярларыннан Сөн буена кул гына сузмалы.

– Минем тулай торактагы бүлмәдәшем Галия дә...

Секретарь аны тыңлап бетермәде, үзенекен дәвам итте.

– Керү имтиханнарын да гел «бишкә» генә биргәнсең...

– Математика минем иң яраткан фәнем...

Мусаев студентканың сүзен бу юлы да игътибарга алмады. Күренеп тора, аны бөтенләй башка нәрсә кызыксындыра иде.

Һәм менә ул алдындагы папканы ябып куйды да:

– Чит ил разведкасына сине кайчан вербовать иттеләр? – дип, кызга текәлеп бакты.

– Нинди разведка? – диде Әннүрә калтыраулы тавыш белән. – Мин сезне аңламыйм...

– Ә Энрико Бертолуччи?!

Җә Ходай, янә шул итальяшка. Теге вакытта шуның аркасында гаиләдә җәнҗал купты, әтисе аларны ташлап чыгып китте. Дүрт ел ярымнан соң бу бәйләнчек бәндә теге вакыттагы кебек тагын уптым илаһи аларның тормышына килеп керде. Хаты белән, ерактан торып. Югыйсә бу мөмкин хәл түгел иде. Ник дисәң, Көнбатышның мәшһүр сәясәтчесе Уинстон Черчилльнең 1946 елда Фултон шәһәрендә сөйләгән нотыгыннан соң башланган салкын сугыш нәтиҗәсендә ике арага төшкән кара пәрдә аралашуларны бермә-бер киметүгә китергән иде.

Буржуаз илләрдән килгән хатлар иң элек КГБ дигән хәтәрдән-хәтәр оешма кулына килеп эләгә, аларның алдагы язмышы да шунда хәл ителә.

Энриконың хатын да бүлмәдән бүлмәгә йөртеп, һәр хәрефен, һәр өтерен энәсеннән-җебенә кадәр тикшерделәр. Тексты исә гап-гади: якты чырай күрсәткәннәре, ризык бүлешүләре өчен рәхмәт хисләрен белдергән. Чабатага аерым мәдхия. Шифрлаучы белгечләрдә нәкъ менә чабата шик уятты да инде. Хат авторы аны «затлы камчы каешларыдай рәт-рәт тезелешкән нәфис юкә тасмалардан үрелгән сәнгать әсәре», дип атый. Шушы җөмләдә бер-бер антисоветчыл бөҗәк посып ятмыймы?

Эзләделәр, нык эзләделәр. Ахыры хатны иясенә тапшырырга мәҗбүр булдылар. Хат Гакифәгә юлланган иде. Җавапны Әннүрә язды.

Ул әсир белән бәйле вакыйгаларның барысын да төкмичәчми секретарьга җиткерде.

Мусаев аны тешен кысып кына тыңлады, чөнки студентканың язмышын үзенә тапшырылмаган икенче хат хәл иткән иде инде. Монысының эчтәлеге бөтенләй башка иде. Бу юлы буржуа кызның институтта нинди белгечлек сайлавы, үз иткән шөгыльләре, яратып укыган китаплары

белән кызыксынган. Болар, әйтергә кирәк, чын-чынлап сагайта торган мәгълүматлар.

Шуңа күрә компетентлы органнар, баладан башаяк дип, аумакай студентканың язмышын коммунизм төзүче бөек совет халкына хас әхлакый норма-принциплар нигезендә хәл итүне мәгъкуль күрделәр. Бу – Гатауллинаны комсомолдан чыгару һәм институттан куу, дигән сүз иде.

– Гатауллина, комитет синең персональ эшеңне комсомол җыелышында тикшерергә карар итте, – диде Мусаев. – Әзерлән.

Әннүрә, кашларын җыера төшеп, секретарьга күз күтәреп кенә карап алды да:

– Бу мине куркытмый, – диде. – Ватан алдында да, юлбашчыбыз бөек Сталин алдында да бер гаебем дә юк.

* * *

Март – мартның көне шарт. Иртәнге якта гына җиһанны яз исенә төреп, кояш балкый иде. Өйлә вакытында инде аны ниндидер ашкынулы ярсу болытлар камап алды, дулый-дулый ишелеп кар яварга тотынды. Озак та үтмәде, мамыктай йомшак бу кар күбәләкләре нәни сөңге бозларына да әверелеп куйды. Үтеп-сүтеп йөрүчеләр йөзләрен капларга мәҗбүр иде.

Нәни сөңгеләр Әннүрәнең битенә дә килеп кадалалар, тик ул аларны тоймый, ара-тирә черки кугандай бияләен генә җилпештереп алгалый, чөнки үзенең дә хәл-халәте шушы керәле дә чыгалы март көне кебек тотрыксыз вә хәвефле иде. Шиге юк, курсташлары аны аңлар, җыелыш гадел карар кабул итәр. Ә менә Мусаев, чын хаклыкны белми торып, ни өчен шулай каты бәрелде соң әле?..

Әннүрәнең уйлары киселде, аны кемдер читкә тартып алды.

– Тапталасың бит, саңгырау тәре, кычкыртам-кычкыртам, колагыңа да элмисең, – диде әлеге кемсә-машина йөртүче, ачуыннан кулларын буташтыра-буташтыра.

– Гафу, – диде Әннүрә, ләкин бу вакыйга да аны уйларыннан арындыра алмады.

Уйлана торгач, гаеп минем үземдә, дигән нәтиҗәгә килде. Әсир белән очрашкан вакыйганы ул автобиографиясендә күрсәтергә тиеш иде ич. Итальяшкасын да әйтер иде, ни пычагыма хат язып маташырга инде, булган – беткән, үлән үскән.

Гөнаһ шомлыгына, әсир аны эзәрлекләвен дәвам итте, әнә төшенә үк килеп керде.

Кыш. Шундый ук чатнама суык. Әннүрә кар көри иде. Янына, бур кешедәй карана-карана, теге хөрәсән итальяшка килеп туктады. Тагын качкан, күрәсең.

– Һитлер капутмы? – дип каһкаһәле көлү белән көлде Әннүрә. – Чабатаң кая, сатып эчтеңме әллә?

Качак саламнары бүселеп чыккан ертык эрҗинкәсенә карап торды да:

– Татарның егет солтаннары чабатаны түргә элә ди бит, мин дә алардан кимме әллә? Хе-хе-хе...

Зерә күзеңне агартасың, син хәчтерүшкәме соң егет солтаны булу, дип әйтергә авызын ачкан иде дә, Әннүрә өлгермәде, кинәт кенә купкан гарасат бу гыйбад аламасын үз эченә йотты. Нидер шартлады, нидер ярылды...

Әннүрә куркынып уянып китте. Тышта буран котырына иде, җил тәрәзә форточкасын кубарып ташлаган икән. Табигать үзенә урын таба алмагандай бәргәләнепме-бәргәләнә.

Ул сәгатенә күз төшерде. Алты тулып килә икән инде. Репродукторга да җан керде. Бүлмә эче гимн авазы белән тулышты.

Ни сәбәптәндер ул бүген шомлы яңгырашта иде. Төшләнү баласе, дип кашларын җыерды Әннүрә, һай, бу итальяшканы...

Үзе шул ук мизгелдә тораташ булып катты.

– Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, Совет хөкүмәте, күпмилләтле совет халкы тирән кайгы кичерә, каты авырудан соң даһи юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталин вафат...

Диктор сөйләгән арада Әннүрә бүлмәдәше Галиянең өстеннән юрганын тартып төшерде.

– Тор, Сталин үлгән!

– Үлсә соң, анда минем ни эшем бар...

Кыз ятагына бөгәрләнеп ятмакчы иде дә, әлеге хәвефле хәбәр аңына барып ирешә булса кирәк, ул да, ыргылып, репродуктор янына килеп басты.

Бераздан Әннүрә, киенеп, җыена башлады.

– Кая ашыгасың, иртә ич әле, – диде Галия.

– Мин Мәскәүгә иптәш Сталинның җеназасына барам!

– Бүген комсомол җыелышы ич, анда синең...

– Беләм, – дип бүлде Әннүрә, – мин бу авыр һәм кайгылы вакытта юлбашчыбызны соңгы юлга озату мәрасимендә катнашуны мөһимрәк дип саныйм, җыелыштагыларга шуны җиткерерсең.

Дөресен әйткәндә, ошбу карар аның күңелендә кинәт купкан өермә кебек капылт кына тәгаенләнде, акылы соңрак уянды, әмма соң иде инде, ул – сүз кешесе, әйткәненә турылыклы горур зат.

Әннүрә өченче тәүлек дигәндә генә башкалага барып җитте. Юлбашчы Ленин мавзолеена куелган иде инде. Ә ул нигәдер ябык. Шуңа да карамастан, Кызыл мәйдан шыплап тутырылган иде, энә төшәрлек тә урын юк. Халык ташкыны, ярсу дулкын булып, әле бер тарафка, әле икенче тарафка агыла. Тып-тын. Кайгы ташларны да балавызга әверелдергән иде, күрәсең, хәтта аяк тавышлары да ишетелми. Кешеләр ым кагып кына аңлаша.

Әннүрә Мусаевны да күреп алды, тик алар икесе ике дулкында иде. Секретарь карашы белән генә сәламен җиткерде.

Иосиф Виссарионовичның үлеме аумакай студентканың да персональ эшен юып төшерде. Бу хакта башка сүз кузгатучы булмады.

* * *

Бертолуччи хатларының КГБда җиде кат йозакка бикләнеп ятуын белми иде, билгеле. Көтеп-көтеп тә җаваплар килмәгәч, башка юлны сайлады. Дипломатлыкка укуы ярдәм итте. Урыс телен яхшы белгәнлеген исәпкә алып, аның үтенечен бик теләп канәгатьләндерделәр, Италиянең Русиядәге илчелегенә эшкә җибәрделәр. Вазыйфасы җирле дәүләт органнары, югары уку йортлары белән элемтә урнаш-



тырудан гыйбарәт иде. Күп тә үтми, Казан шәһәренә юллама алды. Тәүге очрашуны педагогика институтында үткәрде.

Әлеге чарада берничә студент белән йөзгә-йөз әңгәмә кору да каралган иде. Гатауллинаны үзе сайлап алды.

Әннүрәне урамда очратса да таныган булыр иде, мөгаен, чөнки кыз үзгәрмәгән диярлек, тагын да мөкәммәлрәк кыяфәткә генә кергән: тулган айдай балкып торган мөлаем вә сөйкемле ак йөз, озын толымнары калку күкрәгенә сузылган кара чәч, ымсындыргыч гөләндәм буй-сын. Үзе гади, әмма зәвык белән чын ясау булып киенгән.

Ул аны шулай еллар буе алиһә образында күз алдына китереп яшәде. Хәлбуки, Әннүрә кимчелекләрдән дә хали түгел иде. Җентекләбрәк карасаң, борыныннан да, иягеннән дә килешеп җитмәгән якларын табарга мөмкин. Хәер, мәхәббәт өчен боларның бер әһәмияте дә юк.

– Илче әфәнде, белеп торыгыз, мин провокацияләргә тартым сорауларга җавап бирмәячәкмен, – дип, әңгәмәнең юнәлешен дә билгеләп куйды талибә.

Энрико мыек астыннан гына елмайгандай итте дә:

– Күрәсең, сезгә исем-атымны җиткермәгәннәр, мин Энрико Бертолуччи булам, – дип, йотылып, кызга текәлде. – Мең тугыз йөз кырык сигезенче елның салкын кышын исегезгә төшерегез әле. Мин, шәхсән, ул көннең һәр мизгелен күңел түрендә йөртәм...

– Бертолуччи? Итальяно?!

Әннүрәнең сумкасы кулыннан ычкынып, идәнгә мәтәлде. Ачылып та китте булса кирәк, эчендәге әйберләре шыбыр-шыбыр тирә-якка сибелде.

– Әйе, туташ, кайчандыр сез җылыгызга сыендырган бичара әсир...

Әннүрә илчене күз уңыннан үткәрде. Аның карачкыдай иске-москыга төренгән, элеп киптергәндәй ябык әсир белән берничә уртаклыгы юк иде инде. Каршында төз вә озын буйлы, килешле кылыч борынлы, сызылып киткән ыспай мыеклы, энәдән-җептән киенгән фырт егет басып тора иде. Алай да бу мәһабәт пөхтәлекне, купшы ыспайлыкны күңеле кабул итмәде, ачуын гына кабартты. Кыланышын гына күр, кабарынган ата күркә, дип йөзен чытты.

– Әйтегез әле, зинһар, ни өчен сез мине сукыр чебендәй эзәрлеклисез? – диде күзләрен пәрәвезләндереп. – Хатларыгызның миңа нинди кыенлыклар китерәчәген аңларлык та акылыгыз юк идемени соң?

Әннүрә үз кулына кермәгән теге низаглы хат тудырган вазгыятьтән хәбәрдар иде инде. Мусаев серне чишкән иде.

Энрико яраткан француз язучысы Андре Моруаның: «Сез, хатын-кызлар, ир-атта үзегезне эзәрлекләү теләге уятырга тиешсез», – дигән сүзләре белән җавап бирмәкче иде дә, туташның сөрмәле күз керфекләрен күргәч, ул уеннан кире кайтты.

– Нигә, СССРда хат алышу, хат язышу сәяси хатага саналамы әллә? – диде чүгәләп утырган җиреннән башын калкытып. – БМО, киресенчә, һәртөрле аралашуны хуп күрә, хатын-кызларны ихтирам итү аеруча мактала...

Әннүрә исә көлеп җибәрүдән ботын чеметеп кенә тыелып калды. Ник дисәң, фырттан-фырт илче егетебез аның идәнгә чәчелгән косметика ыбыр-чыбырларын, кәгазь-каләмнәрен берәмтекләп җыя-җыя сумкасына тутыра иде.

– Сумкагызның йозагы кыйшайган, булдыра алганча мин аны рәтләгәндәй иттем, тик барыбер ремонтка бирергә туры килер, – дип, ул сумканы иясенә тоттырды.

Ир-егетләрнең джентльменнарча ихтирам күрсәтүе, эчкерсез мөнәсәбәте хатын-кызларны бөтергечтәй әйләндерә дә куя бит ул. Әннүрәнең дә йөзенә нур кунды.

– Рәхмәт, – диде йомшарып, – рәхмәт...

Ә карашы егетнең кулларын эзләде. Ул соңгы вакытта көчле куллы, үзеннән өлкәнрәк ир-атларга игьтибар итә башлаган иде. Бу яктан да егет ким-хур түгел икән. Шуңа күңеле булыпмы:

– Әнкәй дә сезне онытмый, – диде. – Хатыгызны укыгач, исән-имин илегезгә кайтып җитүегезгә бик сөенде.

– Синьора Гакифә чын мәрхәмәт иясе, дошманына кадер-хөрмәт күрсәтә белгән инсан фәрештәгә тиң, – диде Энрико. – Мин әтиегез Мәүлиҗан солдатны да бик яхшы аңлыйм. Сугыш гади кешеләргә күп фаҗигаләр алып килде. Урыны оҗмахта булсын. Гакифә ханымны бик күрәсем килә. Үземнең әлегә андый мөмкинлегем юк, шуңа күрә мин сезнең икегезне илчелеккә кунакка чакырам. Бөтен чыгымнарны үз өстемә алам. Зинһар, тәкъдимемне кире какмагыз. Русиягә килүемнең төп максаты да сезне күрү, сезнең белән очрашу иде.

Әннүрәнең кашлары сикерешеп алды. Булачак булмый калмас, дип әйтергә ярата аның әнисе. Дөресе дә шулай. Бу италияле белән очрашу да шуның бер дәлиле ләбаса! Тәвәккәлләргәдер, мөгаен. Чит ил дипломатында кунакта булу үзе бер могҗиза ич!

– Май аенда укуымны тәгәллим, диплом алам, шуннан соң гына инде...

– Без сезнең белән телефон аша хәбәрләшеп торырбыз, хат ышанычсыз, каршы килмәссезме? – диде Энрико саубуллашканда. – Белегез, бүген мин иң бәхетле кеше!

* * *

Мәскәү аларны бик якынайтты. Ике арада ниндидер сәмави вә татлы тойгы оеткысы күпереп чыкты. Мөгамәлә дә интим төсмер ягына авышты, үзеннән-үзе «сез»дән «син»гә дә күчеп куйдылар.

Моны Гакифә дә күреп торды.

– Бу, синур дигән кара мыек, сиңа күд ата бит, сидәсеңме, бәгырь? – дип, кызына күзәтү нәтиҗәләрен җиткерде. – Муллый малаеның өмете киселә күрмәсен тагын...

– Мокыт ул синең Муллый малаең...

– Үпкәләшүләр була инде ул, – дип юатты кызын әнкәсе, – борчылма.

– Үпкәләшү өчен башта сөешергә кирәк бит әле, әнкәй...

Муллый малае Хәмзә белән алар бергә укыдылар. Бу – тырыш һәм булдыклы егет мәктәпне көмеш медальгә тәмамлап, Уфа нефть институтына имтиханнар бирде. Укудагы уңышлары, студентларның иҗат оешмасында алып барган хезмәтләре, аспирантурага әзерләнүе турында түкми-чәчми язып торды.

Кызлар, гадәттә, соңгы курска җиткәч, гаилә кору хакында уйлана башлыйлар. Әннүрә дә егетенең кылын тартып карыйсы итте. Тегесе исә моны шаярту дип кабул


Рәсем: Наталья Васильева

иткән иде, күрәсең, үзе дә Тукай сүзләре белән шаярту кимәлендә җавап кайтарды.

Хатын алмак читен бит һәм мәшәкать,
Бер алгач, булмый бит шайтанны ташлап...

Әннүрә егетнең бу әдәпсез дуамаллыгын авыр кичерде. Тик тора-бара курсташ ишләрен күзәтә-күзәтә, ир-егетләр кыз халкыннан соңрак өлгерә икән, дигән нәтиҗәгә килде һәм аларны күңел түреннән сызып ташлады. Көчле куллы өлкән егет солтаннары мәҗмугасы шул нигездә тәгаенләнде.

Гакифә дә ялгышын төзәтергә ашыкты:

– Яшь мәхәббәт келәт ватса, карт мәхәббәт пулат ватар, ди, үзеңә кара инде, кызым, – диде.

– И әнкәй, сиңа ышанырга да, ышанмаска да белмәссең. Кичә әнә Третьяковкада икебезне дә хурга калдырдың бит, – дип, Әннүрә җиңел генә әңгәмәнең юнәлешен үзгәртеп куйды.

Энрико сынлы сәнгать күргәзмәсенә алып барган иде. Шунда алар иң күп кеше җыелган «Йокыдагы Венера» картинасы янына килеп бастылар. Бөтен гаурәтен ачып салган хатын-кызны күргәч, Гакифә, бот чабып, чак-чак артына аумады. Аннан тамаша кылучыларның ризасызлыгына колак та салмыйча, кабалана-кабалана картинаны шәлъяулыгы белән каплап та куйды.

Зур шау-шу купты, штраф түләп кенә котылдылар.

– Мин седне гөнаһтан араладым, – дип акланды Гакифә. – Рәхмәтле булыгыд.

* * *

Кичен егет кызның үзен генә татар ресторанына чакырды. Ике кешелек аулаграк урынны да сайлап куйган иде.

Ярым караңгы зал. Колакны иркәләп, ләйсән яңгыр аһәңедәй салмак кына моңлы музыка агыла. Вальста бөтерелүче парларның да шәүләләре күренгәләп-күренгәләп китткәли. Үзенә бер әһле шагыйранә манзара.

Әннүрә салфеткага үрелгән арада, искәрмәстән Энриконың кулына орынып китте. Кул гүя утлы күмер, өттерер дәрәҗәдә кайнар иде. Шул ук мизгелдә бөтен тәне буйлап әлегәчә бер тапкыр да кичереп карамаган ниндидер ашкынулы дулкын таралды, карашы егетнең күркәм буй-сынын сыйпап узды, ә башына, мин гашыйк булдым бит, дигән канатлы уй китереп бәрде...

Мәгъшук егет тә бер сирпеп карау белән кызның эчке хәлөтен тоемлап алды. Сөю-сәгадәткә сусаган ике яшь йөрәк бер сулышта тибәргә тотынды.

Әннүрә йолдызларга баккан кебек башын чөя төшебрәк егеткә текәлгән. Энрико да ишелеп төшкән бу бәхеттән зәңгәр күктә йөзә иде.

Йәш белән йәшнең күңеле бер, / Ефәк белән ефәкнең төене бер.

Әннүрә ярым йомык керфекләре арасыннан елмаеп, егетенә майдай ягылды. Иреннәр бер-берсен эзләп тапты, җаннар ләззәт дәрьясына кереп эреде...

Күпме сөешкәннәрдер, анысы билгесез, алар күктән моң канатларында иңделәр.

– Беренче ишетүем, искиткеч тәэсирле көй, – дип, башта егет аңына килде.

– Бу безнең мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең «Күзләр» пьесасы өчен иҗат иткән җыры, – диде Әннүрә. – Сүзләре дә бик ятышлы, бик мәгънәле.



Хуш, авылым, сау бул, / Сәламнәр көт / Таң җилләре искәндә; / Мин җырлармын сине сагынып, / Өзелеп искә төшкәндә.

Кыз, керфекләрен сирпеп, егеткә карап торды да:

– Мине шулай өзелеп исеңә алырсыңмы? – дип сорады.

– Юк, – диде Энрико. – Юк!

– Ничек инде? – Әннүрәнең тавышында зеңләп үпкә авазы яңгырап китте. – Һи, алайса...

– Чөнки без тиздән гомерлеккә кавышачакбыз.

Энрико уң кулын югары күтәреп, бармакларын шартлатып алуга, ап-ак роза чәчәкләре китерделәр, яннарына килеп баскан музыкант скрипкасын сыздырып җибәрде.

– Бердәнберем, Әннүрәм, мин сиңа теге чабаталы очрашу вакытында ук гашыйк булган идем, – дип, егет сөеклесе алдына килеп тезләнде. – Мин...

– Тукта-тукта, ул чыбыркы сабыдай кыска гына вакыт эчендә нинди гашыйк булу ди, – диде кыз, шук кына күзләрен уйнаткалап. – Ышанмыйм...

– Ышаныч кына яулап алына, туташ, ә мәхәббәт үзе таба, – дип бүлде аны Энрико. – Мәшһүр сексопатолог Фрейд чын ир-егеткә гашыйк булу өчен җиде секунд вакыт җитә, дип тәкрарлый. Менә мин шуларның берсе инде. (Ә мин бер секунд эчендә гашыйк булдым, дип уйлап куйды Әннүрә.) Мәхәббәтем миңа әсирлекнең кыенлыкларын җиңәргә булышты, киләчәккә өмет уятты, яшәү көче өстәде. Сиңа булган рәхмәтемнең чиге юк. Бу купшы чәчәкләрне тәкъдимем билгесе буларак кабул итеп алсаң иде.

Ул Әннүрәгә чәчәкләрен тоттырды да, сүзен дәвам итте:

– Бу әле, сөеклем, алтәкъдим генә, кунак йортына кайткач, әниең Гакифә ханымнан мин рәсми рәвештә саф татар телендә никахка рөхсәт бирүен үтенеп сораячакмын.

– Ни сәбәптән тырышып-тырмашып татар телен өйрәнә икән бу тәти егет, дип, баш ватып йөри идем, хикмәте шәхси мәнфәгатьтә икән ләбаса, – дип бармак янады Әннүрә. – Һай, үткер егет икәнсең, киңәшү-сөйләшү юк...

– Гафу, – диде егет, – гафу, рәхим итеп, бар теләкләреңне, бар таләпләреңне түкми-чәчми җиткер, мин аларны үтәргә әзер.

Әннүрә эздән чыккан уйларын бераз җайга салды да, башын чөя төшеп, соравын юллады:

– Безнең тормышны ничек күз алдына китерәсең соң?

Энрико иң элек фужерына өч-дүрт тамчы шәраб коеп, аны үзенә бер нәзакәтле осталык белән учына утыртты, әмма эчмәде, иснәп кенә ләззәт кичерде. Шуннан соң гына фикерен җиткерде.

– Бу тормышны күз алдына китерү мөмкин түгел. Аны кулга-кул тотынышып, бергәләп корырга кирәк. Ә нигезен ирек, тигез хокуклылык тәшкил итәргә тиеш. Күренекле психоаналитик Карл Юнг, мисал өчен: «Бәхетле никахның алшарты – тугрылыкны бозу иреге», – дип билгеләде.

– Бу соң, синьор, хыянәт иреге ич!

– Шулай, кеше иреге, кеше хокукы яшәешнең иң мөһим, иң катгый асыл таләбе, – диде Энрико, кызның кулын учларына йомып, – тик бу һич тә башбаштаклык түгел. Италия, мисал өчен, демократик ил, әмма да ләкин дөньяда иң тулы канлы, иң ныклы, иң көчле гаилә – итальяннар гаиләсе. Ир белән хатын арасындагы хөрмәт һәм тугрылык кебек сыйфатлар соңгы сулышка кадәр саклана. Һәм бу бик табигый, чөнки италияннарга хас тәкъвалык, ата-бабадан килүче әхлакый кануннар барысыннан да өстен. Белүемчә, мөселманнарда гаиләне таркату өчен бер сүз җитә. Ул сүз – талак. Һәм бу хокук фәкать ир кешегә генә бирелә...

– Менә-менә, – дип элеп алды Әннүрә, – ниһаять, соравымның асылына килеп төртелдек. Мин – мөселман, син – христиан. Ә минем өчен, синьор Бертолуччи, мөселманча никах беренче урында.

Энрика кызның кулын җибәреп, урындык аркасына терәлебрәк утырды да, берара уйланудан соң, әйтте:

– Әннүрә туташ, акылыгызга килегез, бу бит комсомол әгъзасы, югары белемле мөгаллимә сүзе түгел, – диде. – СССРда диннең эзәрлекләнүе бөтен дөньяга мәгълүм ләбаса. Сезнең бит мәчетләрегезне дә җимереп бетергәннәр...

– Никахны бит аны, кешеләргә белгертмичә, яшерен генә дә башкарып була ич, һәм шулай эшлиләр дә, – дип, кыз үзенекен алга сөрде.

– Юк инде, сөеклем, мин гаилә тормышымны качып-посып, ялганнан башларга теләмим.

– Алайса, нишләргә соң?

– Рәсми язылышуны Казанда теркәрбез, ә никахны тантаналы рәвештә Италиядә укытырбыз. Ризалыгыңны гына бир, барысы да синеңчә булыр, – диде егет.

– Мин риза, әнкәем дә хәер-фатыйхасын бирер, – диде Әннүрә егетнең куенына елыша төшеп. – Без риза... Ләкин...

– Нәрсә ләкин, сөеклем?

– Советлар Союзы гражданкасына чит ил кешесе белән гаилә кору мөмкинме икән? Мин белмим...

– Мин беләм, – диде Энрика. – СССРда мондый никахны рәсми тыю турында закон юк, әмма хупланмый. Бу җәһәттән, минем дипломатик статусым ярдәмгә киләчәк.

– Энрико...

Әннүрәнең керфегенә иртәнге чыктай саф-пакь яшь бөртеге кунды.

– Күрәм, син безнең никахыбызга бик җентекләп әзерләнгәнсең...

– Мин сине бик яратам, сөеклем.

– Ышанам, – диде Әннүрә, егетенең кочагына сыенып, – ышанам, җанашым...

Энриконың кулы сөйгәненең сандугач йомыркасыдай тыгыз күкрәк алмаларына сарылды.

– Минем дә бер шартым бар, – дип, кайнар тынын өрде егет сөеклесенең колагына.

– Әйт соң, тыңлыйм...

– Вакыты җитмәгән әле, – диде егет. – Борчылма, никахка аның бернинди катнашы да юк...

Алар янә сөю сәгадәтендә онытылдылар.

* * *

Яшьләр Никах сараена Сөн елгасы әрәмәлегендә буй җиткергән юкә агачы каерысыннан үрелгән нәфистән-нәфис чуклы чабата киеп килделәр.

Энриконың шарты шушы иде.

Чабатасын түргә эләр, / Үзе кияр күн итек. / Егет егетлеген итәр, / Гүя Арыслан киек. / И чабата, чабата, / Чабата чәчәк ата...

КИТАП УКУ — ДӨНЬЯНЫ АҢЛАУ

КИТАП УКУ УЛ...

– Дөньяда «ярымкешеләр» бар. Алай дип әйтү коточкыч начардыр, әмма андыйлар бар. Алар беркайчан бер китап та укымыйлар, бернәрсә турында уйламыйлар, баш миләре бик бәләкәй... «Кешеләрдә сез нинди сыйфатларны бәялисез?» – дип сораганнар Чыңгыз Айтматовтан. «Акыл!» – дигән ул. Акыл китап аша гына формалаша. Китап укымыйча акыллы булып булмый. Яшь чакта китап уку тәрбия чарасы булса, картайган көндә – ул дәва, профилактика. Деменция, Альцгеймер авырулары китап укыган кешеләрдә булмаячак инде ул.

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...

– Без бәхетле гаиләдә үстек. Әти – абруйлы язучы, әнием – татар теле укытучысы. Авылдан килгән әбиебез бер сүз русча белми иде. Рус мәктәбендә укысак та, өйдә һәрвакыт татарча сөйләштек, әтинең китапларын укыдык. Бәлки, төбенә төшеп аңламагангбыздыр да ул вакытта, әмма укый идек. Мине тетрәндергән беренче китап – Редьярд Киплингнең «Маугли»е. Аны яттан белә идем. Ул гаҗәеп атмосфералы! Соңрак кына аңладым: кешелек җәмгыятен тасвирлый икән. Кешеләр арасында да бар бит Мауглилар, Балулар, Каалар, Шер-Ханнар. Бу әсәрне хәзер дә яратам.

МИНЕ /ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ/ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...

– Дөньяга караш үзгәрү китап белән генә бәйле түгелдер ул. Тере кеше һәрвакыт үсештә булырга тиеш. Шулай да ниндидер үзгәрешләр биргән китап дип Эрнест Сетон-Томпсонның хайваннар турында хикәяләрен атый алам. Ул әтинең өстәлендә ята иде. Без аны барыбыз да укыдык. Табигатькә кереп китү шушы китап аша булгандыр, мөгаен.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ-КИТАП...

– Антуан де Сент-Экзюпери безнең гаиләдә кумир иде. Аның әсәрләре хәзер дә тетрәндерә, күп цитаталары күңелемдә. Минем «Микулай» әсәремдә Экзюпери фикерләре ята. Очыш, очучы булуы... Ул бит аерым дөнья! Микулай дигән егет гомере буе авылда яшәгән, беркая да чыкмаган, әмма аның да очасы килә. Һәр кеше йолдызларга карап яши! Үсмер вакытымда ук Лев Толстойның «Война и мир»ын укып чыктым. Ул сугыш һәм ДӨНЬЯ турында. Моны аңларга кирәк. Марксны, Ленинны укый идем. Фёдор Достоевскийның «Братья Карамазовы» минем өчен бик кадерле, чөнки ул гаиләбезнең тормышын чагылдыра. Бу әсәр өч бертуган турында. Алар өчесе дә төрле. Абыем, мин һәм энем дә нәкъ шулай.

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...

– Мин бит кино, театр дөньясында кайныйм. Өстәлемдә – Никита Михалковның «Публичное одиночество» китабы. Бик яратам, хөрмәт итәм ул шәхесне.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Бәлки, җавабыма аптырарсыз да... Бернәрсә дә укымыйм. Нинди китап укый башласам да, үзем өчен яңалык таба алмыйм, яңа дөнья күрмим, яңа атмосфера тоймыйм. Өлкәнәюме бу, күңел сүрелүме... Үз тормышымда бик күп китаплар укыдым. Барысы да күңелемдә. Аларны кабат-кабат кайтып укыйм. Минем өчен гомерем буе әтиемнең китаплары беренче урында. Бу инде аксиома. Бүген элекке кумирларыма кайттым. Достоевский, Толстой... Толстойның бөтен әсәрләрен укып чыгып, башка бернәрсә укымасаң да иманлы, белемле кеше булачаксың. Күп китап уку әллә ни баетмый, тирәнлек белән укырга кирәк! Үзем өчен «Китап» радиосын ачтым. Машинада барганда бернинди музыка да кирәкми. Ул шулкадәр рәхәт радио! Анда иң яхшы артистларыбыз татар классикларының әсәрләрен укый. Бик яратам тыңларга. «Китап» тыңлап «тукланам» шулай.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ ӨЧ ЯРАТКАН ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ...

– Татар әдәбиятында бердәнбер яраткан авторым – әтием Аяз Гыйләҗев. Әсәрләрендәге фикерләре, атмосферасы миңа бик якын һәм бик кадерле! Иң ошаган әсәре – «Яра». Бөтенебез дә яраланган кешеләр. Ярасыз кеше – ул примитив, дөньяны күрмәгән-танымаган. Кичерешләр узган кеше генә миңа кызык.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...

– Бүген миңа, әлбәттә, электрон китаплар якын. Күзләрем начаррак күрә, ә компьютер мониторы зур – хәрефләре эре. Электрон форматта китап уку җайлырак.

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...

– Хәзер яшьләр сәнгатькә килә дә яңалык кертәм, дия башлыйлар. Әмма ул буш була, яңалык тудырганчы классиканы белү мөһим. Классик китаплар укырга. Пикассоның гениаль фикере бар: «Я 14 лет рисовал как Микеланджело». Гәрчә, үзе абстракционист булган. Хәзер язылган әсәрләрне укып кына дөньяны танып, аңлап булмый. Баштан башларга кирәк!

Мансур ГЫЙЛӘҖЕВ, режиссёр, драматург




Фото: Анна Арахамия

2018–2019 еллар



2018 елда «Сөембикә» журналының баш мөхәррире итеп шагыйрә, журналист Гөлнара Ильяс кызы Сабирова билгеләнде.
Татар матбугаты өчен үзенә күрә бер тәҗрибә дә иде бу: Гөлнара Сабирова берьюлы ике басмага баш мөхәррир булып торды – «Сөембикә» журналына һәм «Шәһри Казан» газетасына. 2019 елның апрелендә ул инде «Ватаным Татарстан» газетасына баш мөхәррир итеп куелды.
Журналга яңа рубрикалар алып килде Гөлнара Сабирова. Шуларның берсе – «Ачыктан-ачык». Татар дөньясына билгеле булган күренекле шәхесләр үзләренең тормышында булган катлаулы хәлләр, язмыш сынаулары турында ачыктан-ачык сөйли. Журналисттан – әңгәмәдәше күңеленә үтеп керү, ә сөйләүчедән шактый ихласлык таләп итә бу интервьюлар. Иң беренче язмадан ук журнал укучының яраткан, көтеп алган сәхифәсенә әйләнде әлеге рубрика.
«Объективта – әни» фотобәйгесе шулай ук «Сөембикә» тарихына кереп калачак. Журнал аны «Казан Кремле» музей-тыюлыгы белән бергә үткәрде. Ел буе журнал битләрендә барган бәйгегә көзен – Әниләр көнендә нәтиҗә ясалды һәм бу фотосурәтләр Кремльдә, «Манеж» күргәзмәләр залында тамашачыга тәкъдим ителде.
Бу чорда «Сөембикә»дә журналистлар Мәдинә Авзалова, Эльмира Закирова, Гөлнур Сафиуллина, Лилия Гәрәева, Фәнзилә Мостафина, Чулпан Галиәхмәтовалар эшләде.

Гөлнара Сабирова белән әңгәмәне уку өчен:





Кызлар бәйрәме, чәчәкләр, елмаюлар...

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ПЕНСИЯДӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР
картаерга иртәрәк

ИЯРТЕП КИЛГӘН БАЛА
икенче ир өчен кем ул

ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА СЫЙЛЫЙ
азу

Раушания БӘДРЕТДИНОВА:

КҮҢЕЛЛӘРГӘ АЧКЫЧ ЯРАТУ – ҮЗ КУЛЫБЫЗДА

Баш мөхәррир сүзе



Бөтен нәрсә үзгәрештә. Еллар, чорлар, вазгыять үзгәрә, буыннар алмаша. Ә без һаман шул: 105 еллык «Сөембикә» нинди генә чорда, нинди генә вазгыятьтә дә гаилә кыйммәтләре, әхлак һәм милләт мәнфәгатьләре сагында. Хатын-кызларның якын дусты, киңәшчесе, сердәше ул. Журналны «Азат хатын» чорыннан алдырып килүчеләр дә, «Сөембикә» исеме белән якын итүчеләр дә бу сүзләрдә хилафлык күрмәс. Әйе, без заман белән атлыйбыз, һәр санызбызны тагын да кызыклырак, баерак итәр өчен эзләнәбез, яңа сәхифәләр уйлап табабыз, тик максатыбыз барыбер бер: безнең сезгә үз, якын, кирәкле буласыбыз килә.

Бу көннәрдә Сөембикә рухы белән яшәдек. Әйе, Сөембикәнең үзе белән! Махсус безнең юбилейга диярсең, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Сөембикә» операсының премьерасы узды. Операның тарихи һәм милли кыйммәте турында кайта-кайта сөйләрләр, язарлар әле, бүген сүзебез ул хакта түгел. Сөембикә ханбикә – милләт тарихы, милләт фаҗигасе. Ә операда без аны бөтен хатын-кызлар фаҗигасен үзенә туплаган образ итеп тә күрдек. Нинди генә хәлдә калганда да, хатын-кыз күңелен бары хатын-кыз тирәнтен аңлаган. «Сөембикә» журналы да еллар дәвамында сезнең күңелегезне аңларга һәм сезнең белән бергә вазгыятьне аңлашырга теләгән басма. Ханбикә исемен йөртү исә, горурлык һәм дәрәҗә булу белән бергә, җаваплылык та өсти.

«Сөембикә»гә – 105! «Сөембикә» бүген инде икенче гасыр тарихын яза. Аңа нигез салучыларга да, безнең заманнарда мөхәррирлек иткән һәм бүгенге көнгә алып килгән Асия Хәсәнова, Венера Ихсанова, Роза Туфитуллова, Фирая Бәдретдинова, Ләйсән Юнысовага, журнал редакциясендә эшләгән хөрмәтле ветераннарыбызга, актив хәбәрчеләребезгә, төрле төбәкләрдә яшәүче дусларыбызга, партнерларыбызга һәм, әлбәттә, сезгә, кадерле укучыларыбыз – туташлар һәм ханымнар, олы рәхмәтләребезне җиткерәбез! Безнең янда Сез булмасагыз, ул тарих булмас иде. Бу – безнең уртак бәйрәмебез. Киләчәктә дә бергә булыйк!

Гөлнара САБИРОВА

«ТАТМЕДИА» БАСМАЛАРЫ МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА



БЕЗНЕ НИЧЕК ТАБАРГА?

ТАТМЕДИА

КИТАПЛАР



ЖУРНАЛЛАР



ТӘБРИКЛӘМӘЛӘР



OZON



Я Маркет



WILDBERRIES



KazanExpress



БЕЗНЕҢ ИНТЕРНЕТ-КИБЕТ

SHOP.TATMEDIA.RU



Реклама. 16+. АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 Казань шәһәре, Декабристов ур., 2 нче йорт. ГРН 1071690057834

МӘХӘББӘТЕМ АНА БУЛЫШСЫН!..

Динә НАСЫЙРОВА

Һич икеләнмичә әйтә алам: бүгенге көндә Илгиз ФАЗЫЛҖАНОВ дөньядагы иң талантлы ювелирларның берсе! Халыкара конкурсларда Гран-прилар яулаган, үз брендын булдырган... Эшләре Лондон һәм Нью-Йоркның аукцион йортларында сатылган, «Мәскәү Кремле» музейлары һәм Мәскәү Алмаз фонды коллекцияләрендә, төрле илләрнең шәхси коллекционерларында сакланган... Мәскәүдә һәм Парижда үз галереясы булган... «Bovet» легендар сәгатьләре өчен уникаль циферблатлар ясаучы бердәнбер Россия ювелиры ул. Аның эшләрен таныйлар! Соңгысы – зәркәнче өчен иң зур бәя... Бу исемлекне бик озак дәвам итә алам, әмма Илгиз, беренче чиратта, минем иң якын кешем – ирем...



Илгиз белән 1997 елны таныштык без. Очраклы рәвештә булды ул.

Минем медицина институтын тәмамлаган елым иде. Соңгы курста укыганда Парижда ике ай буе француз теле өйрәнергә мөмкинлек туды. Онытылмас көннәр булды ул... Казанга кайтуга, сәяхәттән алган тәэсирләрем белән уртаклашырга дус кызым янына киттем. Ә аның дусты – модельер: ул безнең икебезне дә бер ювелир танышын туган көне белән котларга дәште. Шулай итеп, без Илгиз белән аның туган көнендә – 28 мартта, Казан Кремлендәге остаханәсендә таныштык. Мин шунда ук аның күзләренә игътибар иттем: карашы арыган кешенеке иде... Ул үзенең кызы үсүе, тик гаилә тормышы барып чыкмавы турында әйтте, ә аннан иң мөһим яңалыгын җиткерде: «Пуатьеда узачак Халыкара антиквар салонда коллекциямне – эмаль ысулы белән ясалган бизәнү әйберләрен күрсәтәм», – диде. Сүз үзеннән-үзе Франциягә күчте. Минем яраткан темага! Яңа гына аннан кайтуым, француз телен белүем турында әйттем.
«Их, нигә без бераз гына алдарак танышмадык икән?! Инглиз телле тәрҗемәче белән килешү төзергә өлгердем шул», – дип уфтанды ул.

Без шулай саубуллаштык. Ярты елдан соң аның остаханәсендә кабат күрешкәнгә кадәр булды ул саубуллашу. Очрашуның анысы да очраклы килеп чыкты. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы Казан Кремлендә урнашкан иде әле ул чакта. Ординатурага укырга керүем турындагы кәгазьләрне аларга тапшырырга кирәк иде миңа. Кинәт кенә яңгыр ява башлады. Ышыкланыр өчен иң якын җир – таныш ювелирның остаханәсе иде...

Илгиз мине онытмаган булып чыкты. «Сине бик еш исемә төшердем», – дип шаккаттырды. Туйга чакырулы иде ул көнне Илгиз, мине дә анда үзе белән бергә барырга күндерде. Өстемдәге киемем рәсми очрашулар өчен булуын да (министрлыкка киләм бит!) киртә дип сана-

мады: аның нибары бер бизәнү әйбере костюмымны үзгәртте дә куйды... Аннары инде без бәхетле гаилә кордык. Юк, алай тиз түгел, Илгиз үзенең илһамчысы булуыма тәмам төшенгәч кенә. Әмма «бер күрүдән гашыйк булу» дигән гыйбарә безгә барыбер туры килә дип саныйм...

Илгиз Яшел Үзән шәһәрендә туып-үскән. Гаиләдә дүрт ир бала алар! Әтисе белән әнисе сөйләве буенча, ирем кечкенәдән үк мөстәкыйль булган. Аны бер түгәрәктән икенчесенә берәү дә җитәкләп йөрмәгән. Хәер, моңа вакытлары да булмаган: әтисе эштән кайтып кермәгән, ә әнисе эшләгән дә, шундый зур гаиләне карарга да өлгергән: ашарга пешергән, кер юган, өйне чисталыкта тоткан. Илгиз – мәктәптә активист, пионер, комсомол оешмалары лидеры була. 8 яшендә шәһәрнең сынлы сәнгать мәктәбен ул үзе эзләп таба, рәсемнәрен үзе алып бара – шулай итеп укырга керә. 6 ел буе шәһәрнең икенче почмагында урнашкан сәнгать мәктәбенә йөреп белем ала. Әмма моңа өйдәгеләр әллә ни игътибар итми бугай: бала-чага ни белән шөгыльләнмәс. Шуңа күрә дә Илгизнең киләчәген сәнгать белән бәйләргә теләвен ишетү әти-әнисе өчен көтелмәгән хәл була. Мөршидә кайнанам бу хакта болай дип сөйләгән иде: «Ул рәссам булырга телим дигәч, мин хәтта утырып еладым. Әгәр дә заводка эшкә урнашса, күңелем тынычрак булыр иде. Хәрби булырга теләсә дә шатланыр идем әле. Тормыш алып бару өчен ничекләр акча эшләр бу бала дип кайгырдым...»

Әмма улларының теләгенә алар каршы төшмәгән. Казан сынлы сәнгать училищесы Илгизгә иҗат белән шөгыльләнү өчен төп нигез биргән. Армиядән соң инде ул үз иҗат юлын эзли башлый... Шул вакыт Таҗикстанга зәркәнче һөнәренә өйрәнергә җибәрү өчен бер төркем туплыйлар: кемдер бара алмый кала, һәм аның урынына Илгиз китә. Тик Таҗикстандагы сәяси вакыйгалар Илгиз һәм аның тагын бер дусты өчен дә авырлыклар, хәтта үлем куркынычы аша Казанга әйләнеп кайту белән тәмамлана. Тик ул инде илнең ерак почмагында яшәүче бер зәркәченең ничек эшләвен бераз булса да күрергә өлгерә... Үзе ясаган беренче бизәнү әйберләрен сатып алучыларга Илгиз бүгенгәчә рәхмәтле, чөнки шуңа күрә генә ул иҗатын дәвам итә алган...

Биш ел буе ул борынгы Болгар тарихын, алардагы ювелирлык сәнгатен өйрәнә. Музейларга барып мәгълүматлар туплый, архивлардагы борынгы бизәнү әйберләрен кабатлап ясап карый. Танылган сәнгать белгече Розалина Шаһиева белән «Мәскәү Кремле музейлары»на барып, анда саклanучы Казан таҗы белән таныша һәм аның миниатюр күчермәсен иҗат итә – ул Казанда саклана. Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Татарстан Милли музеенда, элеккеге «Казан» милли-мәдәни үзәге коллекцияләрендә дә аның эшләрен күрергә мөмкин. 1994 елда Исламабадта узган мөселман дәүләтләре яшь ювелирларының I Халыкара ислам фестивалендә кыйммәтле ташлар белән бизәлгән Коръән тартмасы, хәситә һәм беләзек тәкъдим итеп, беренче дәрәҗәдәге Гран-прига лаек була. Аннан инде үз әсәрләрен иҗат итә башлый.

Аның бизәнү әйберләре Европа аристократлары гаиләләрендә нәселдән-нәселгә күчәчәк **байлык булып санала.**

1998 елда Франциядә узган Халыкара салонга инде без бергәләп әзерләндек. Моңарчы медицина белән бәйле күргәзмәләрдә генә эшләгәнем бар иде, ә бу бөтенләй башка өлкә. Илгиз миңа үз һөнәренең серләре турында сөйли, ә мин аны французчага өйрәтәм... Барысы да бик уңышлы узды, сатып алучылар да булды. Илгизне хәтта Франциягә эшкә чакырдылар. Калыгыз, остаханә әзер, диделәр. Без анда ике ай булдык: Антибтан – Ниццага, аннары Парижга киттек. Безнең алда ачылмас ишекләр юк иде кебек: Cartier Ювелир йорты офисы бусагасын атлап кердек. Таныштык. Бер айдан шалтыратып, алар Илгизне үзләренә, дизайн департаменты экспертлар советына чакыруларын хәбәр иттеләр: Cartier Ювелир йорты Илгиз Фазылҗанов белән эшләргә әзер иде.

Казанга кайтуга улыбыз Кәрим туды. Шатлыклы көннәр башланды, әмма шул ук вакытта 1998 ел кризисы да килеп җитте. Сату кимеде – кешеләр булган алтыннарын да ломбардка тапшыру җаен карады... Илгиз ул чорда күпләп көмеш бизәнгечләр ясады. Базар янындагы кечкенә павильоннан сатып алырга була иде аларны. Соңрак ул тагын алтын бизәнү әйберләре ясый башлады, әмма аларда ярым затлы ташлар гына кулланды.

2000 ел ахырында бер рус-француз журналыннан графиня Доминик де Рокморель-Голицына хакында язма укыдым, аның электрон адресын таптым. Белеме буенча сәнгать белгече, ювелир һәм коллекционер ханым Россиядәге антиквар һәм заманча ювелир бизәнү әйберләре белән кызыксына иде. Димәк, безнең белән! Озакка сузмыйча, аның белән элемтәгә кердек, ул шунда ук тиз арада килергә вәгъдә итте. 2001 ел башында аның белән Казанда очраштык. Илгизне ул заказларга күмде: яңа эшләнмәләр өчен рубин, сапфир һәм зөбәрҗәт ташлар калдырып китте. Ә тагын бер атнадан Илгизнең Казан Кремлендәге остаханәсеннән ул ташларны урлап чыктылар... Тикшерү бернинди нәтиҗә дә бирмәде. Без исә дүрт ел буе бурычыбызны түләдек һәм барысын да яңадан башладык...

Мәскәүдә «Ювелир-2000» Халыкара ювелир күргәзмәсе бара. Яныбызга көтмәгәндә күргәзмәнең техник директоры Илгиз Садретдинов килде. Һәм ул безне шунда ук киләсе ел чарасына чакырды. Шулкадәр урынлы һәм кирәк булды бу чакыру! «Ювелир-2001»дә Илгизнең эшләре дипломга лаек дип табылды, бик күпләр аның белән якыннан да таныштылар: клиентлар артты.

Бихисап бухгалтер кәгазьләре белән бәйле эшләрне алып бару гаиләбездә минем өстә иде. Белемем җитмәвен аңлагач, Казан дәүләт университетының икътисад факультеты каршындагы курсларга укырга кердем. 2002 елда мине Италиягә стажировкага җибәрделәр. Виченцадагы ике ювелир фабрикада стажировка үттем.

Илгиз Фазылҗанов феномены...
Берләштереп булмаганны берләштерү – гади генә аны шулай аңлатып буладыр.

һәм аларның берсе нәкъ шул көннәрдә зур күргәзмәдә катнашты. Минем өчен шундый кирәкле тәҗрибә булды ул. Илгиз дә улыбыз белән яныма кунакка килде. Водородлы эретеп ябыштыру аппараты эшенә шул вакыт төшенде.

Казанга кайткач, үзебезнең шәһәр беренче мәртәбә миңа инде кысан тоелды... Реконструкция булу сәбәпле, Казан Кремлендәге остаханәсез дә калдык. Яңа остаханә таба алмадык. Илгизне Татарстан Рәссамнар берлегенә кабул итмәделәр. Кабул итәргә нигез юк, диделәр... Эшебезне шәһәр үзәгендәге офиста дәвам иттек. Һәм шул вакыт Илгизне Швейцариядә узучы Baselworld Халыкара күргәзмәсендә катнашырга чакырдылар. Әлеге күргәзмә инде 70 ел буе уза һәм аның тарихында Россия беренче тапкыр катнаша икән! Исемлеккә кердек керүен, тик катнашу өчен биш мең доллар кирәк иде. Без күтәрә ала торган сумма түгел иде бу... Бер ишектән икенчесенә йөреп, җитәкчеләрдән булышуларын сорыйм: күргәзмәгә куйган барлык эшләрне Швейцариядән кайткач Казан музейларына бүләк итәчәкбез, дим. Кызганыч, тәкъдимебезгә уңай җавап булмады... Кәеф бөтенләй төште. Үзем ничек тә түзәрмен, әмма Илгизнең кәефен төшерергә ярамый иде миңа: иҗат дәрте сүнмәсен... Тәвәккәлләдем: бер кулыма – улымны, икенчесенә сары чемоданымны тоттым да, Мәскәүгә чыгып киттем. Илгиз дә машинага иң кирәкле эш коралларын төяп, безнең арттан юлга кузгалды...

Башкаладагы беренче ике елны томан эчендәгедәй генә күзаллыйм хәзер. Акча җитми, Илгиз көне-төне эшли, бер күргәзмәдән кайтабыз, икенчесенә чыгып китәбез... Улыбыз Кәрим ул чакта машинада гына яшәде бугай: кая барсак та, аны үзебез белән йөрттек, чөнки бакчага илтергә-алып кайтырга вакытыбыз юк иде. Мондый тормыштан тәмам арыдык. Яшермим, үзебезне, дөресрәге, Илгизнең иҗатын беркемгә кирәксез итеп тойган мәлләр дә кичердек... Икәү бергә булганга, араларыбыз җылы, дус-тату булганга гына бик күп кыенлыкларны җиңеп чыга алдык. Ике елдан соң тормышыбыз җайланды, улыбыз 1 нче сыйныфка укырга керде, иремнең беренче гаиләсендә туган кызы да безнең янга Мәскәүгә килде. Илгиз Мәскәүдә узган зур-зур күргәзмәләрдә катнаша башлады, күп мәртәбәләр төрле конкурсларда җиңеп чыкты. Һәр күргәзмә яңа танышлыклар өстәде, хезмәттәшлек артты, яңа мөмкинлекләр ачты. Тагын шунысы да аңлашылды: Илгизнең юлы – эксклюзив бизәнү әйберләре ясау, аерым клиентлар белән эшләү. Иҗат иткән әсәрләренең бер «тискәре ягы» бар: аларны тиражга куеп – күбәйтеп булмый иде. Һәркайсы – бердәнбер! Бик күп бриллиантлар сибеп эшләнгән бизәнү әйберләре – алар бары тик кыйммәтле бизәнү әйберләре генә. Ә Илгизнекеләр башка... Ул һәр эшендә күптән килгән традицияләрне дә саклый һәм шул ук вакытта үз уйларын, үз фәлсәфәсен дә җиткерә. Заказга тотынганчы, башта аның булачак хуҗасы белән очраша, аннан кыскача булса да үзе хакында сөйләвен үтенә: психологик портретын, образын ачыклый. Әйе, аның һәр эше уникаль! Әсәрләреннән коллекцияләр җыю – аның өчен түгел. «Сәнгать – башкалар өчен булырга тиеш, әгәр әсәреңне үзеңдә саклап калырга телисең икән, бу үз-үзеңә чик кую белән бер», – дип саный ул.

2006 елда икенче улыбыз туды. Күп балалы гаиләгә әйләндек! (Алга китебрәк булса да әйтим: балаларыбызның өчесендә дә рәссам сәләте бар. Әгәр этиләре юлыннан китәргә теләсәләр, остаханә ишекләре алар өчен һәрчак ачык.) Мәшәкатьләр бермә-бер артты, әмма барыбер күңелле еллар иде ул. Фирмабыз яңа, уңайлы остаханәгә ия булды. 2007 елны Илгиз иң яхшы эшләнмәләренең фотосурәтләре, эскизлары кергән беренче китабын нәшер итте. Китапны үзе төзеде, ә мин кереш сүз яздым. Ул елның ахырында шуны да аңладык: Илгизнең эшләренә алтын-бриллиант дип карап, аларны кыйммәтле яхталар, автомобильләр белән берлектә тәкъдим итү – безнең өчен түгел. Аныкылар – сәнгать өлкәсенә генә карый.

Инде без катнашкан күргәзмәләр дә елдан-ел кызыклырак, дәрәҗәлерәк була барды. 2007 елда Илгиз техник яктан гаять катлаулы хезмәтен – «Карабүрекләр»не («Снегири») иҗат итте. Аңардагы тоемлау хисенә кат-кат шаккатасың: эшендә бернәрсә дә артык түгел, шул ук вакытта ким дә түгел... Иремнең 35 яшемә бүләге иде бу... Әлеге асылмалы бизәк «Алрос» үткәргән конкурста җиңү яулады. «Карабүрекләр» 2010 елны Мәскәүдә «Ювелирное обозрение» журналы оештырган бәйгедә дә җиңде! Бу безнең үз-үзебезгә ышанычны тагын да арттырды.

2011 елда «Карабүрекләр» Гонконгта узган Ювелир дизайны халыкара конкурсында катнашты. Россиянең әлеге бәйгедә беренче катнашуы! Утыз илнең йөз егерме бер ювелиры арасыннан финалга нибары сигез оста үтте. Шул исәптән, Илгиз дә! Финалистлар нәрсә сурәтләүләрен һәм аны нинди техник ысуллар кулланып иҗат итүләрен аңлатып бирергә тиешләр иде. Кар өстендә генә ачык күренгән карабүрекләрнең безнең яртылаш кыштан торган илебез өчен нинди кошлар икәнен башкаларга аңлату авыр иде. Тик миңа: «Сез тәрҗемәче була алмыйсыз», – диделәр. Илгизгә беркетелгән тәрҗемәче исә... яртылаш татар кызы булып чыкты. Без аның белән әле дә аралашабыз. Ниһаять бүләкләү тантанасы башланды. Номинантларны, гадәттәгечә, исемлекнең ахырыннан игълан итә башладылар. Сигезенче, җиденче, алтынчы... Менә ике кешене генә атамый калдылар: Илгизне һәм Кытай дизайнерын. «Гран-при һәм «Чемпионнарның чемпионы» исеменә лаек булды...» Илгизнең кытайлар өчен авыр әйтелешле исем-фамилиясен укыганда, йөрәгем күкрәгемнән сикереп чыга дип торам. Бу мизгелне беркайчан да онытмаячакмын! Безнең өчен бик мөһим җиңү иде ул! Шулкадәр кыенлыклар аша узган, барысына да үзлегеннән өйрәнгән, эшен ничәмә тапкыр нульдән башлаган Останың лаеклы җиңүе иде.

(*Дәвамы 112 нче биттә.*)

СИЗГЕР ТИРЕНЕ КАЙГЫРТУ

Реклама. ИП Мустаева О.Н. ОГРНИП 311168919600013





Олеся Мустаева Остаханәсенең Sensitive сериясе – сизгер һәм реактив бит тиресен йомшак һәм нәтиҗәле итеп тәрбияләү. Sensitive сериясенең барлык продуктлары да дерматология тикшерүе узган, аларда эфир майлары һәм синтетик хушбуйлар юк.

Master-om.com сайтында заказ бир һәм ЯЗ промокоды белән 20 процент ташлама ал

«Ташлама» бүлегеннән тыш, барлык төр продукция өчен дә гамәлдә. Акция вакыты: 2023 елның 1 апреленнән 2023 елның 26 маена кадәр (ул көнне дә кертеп).



master-om.com



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Балаларыбыз татарча белми, татар китапларын укымый дип зарланыша әти-әниләр. Барысы да үзеңнән тора бит. Сөйлә бер көнне Тукай, икенче көнне Такташ турында. Шигырьләрен укы. Балаларның зиһене яхшы, тиз оталар.

Мин үзем Башкортстанның Туймазы районында туып-үстем. Татар мәктәбендә белем алдым. Аннары Бәләбәй педагогика училищесына укырга кердем. Үзебезнең күрше авылда өч ел башлангыч мәктәптә укыткач, Казанга китәргә туры килде. Мин килгәндә монда бер генә татар мәктәбе эшли, ә татар балалар бакчалары бөтенләй юк иде. Шаккаттым. Күп еллар балалар бакчасында эшләдем. Бәйрәмнәрдә татар балаларына татарча шигырьләр бирә идем. Өйдә әти-әниләре ятлата да, тәркемдә кабатлыйбыз. Шигырьләрне кабатлаганда башка балалар да ятлап бетерә иде.

Беренче елларда Киров районының Бишбалта бистәсендә яшәдем. 1996–97 елларда миңа Юля исемле рус кызы татар телен өйрәнергә йөрде. Аңа тугыз ел ярдәм иттем. Татар теле грамматикасын су кебек эчә иде.

Яңа Савин районына күченгәч, Илья исемле күрше малае татар теленнән булышуымны үтенде. Татар телен аңлый, белә үзе. Мәктәптән барысын да аңлап кайтса да, китабын күтәреп минем янга кереп җитә иде ул. Әллә мине, әллә татар телен яратты? Мәктәпне тәмамлагач, Казан федераль университетына укырга керде, физик булды. Хәзер чит илләргә йөри, аспирантура тәмамлады, галим булырга җыена. Татар телен өйрәнеп, офыклары киңәйде аның. Күрше кызы белән дә 10–11 нче классларда татар телен өйрәндек.

Татарча дәреслекләр авыр телдә язылган, диләр. Мин алай димәс идем. Китаплар да, методикасы да начар түгел. Әти-әниләрнең үз балаларын татарча укытасылары гына килми. Безнең өчен бу оят кына түгел, хурлык та! Бер милләт тә болай кыланмый. Балаларың белән татарча сөйләшмәгәч, оныкларың белән бик теләсәң дә татарча сөйләшә алмыйсың инде.

Зәбидә МОРТАЗИНА.
Казан шәһәре.

Фото: Анна Арахамия



Үземне белә-белгәннән бирле әнием «Азат хатын» һәм «Башкортостан кызы» журналларын алдырды. Башкорт милләтеннән булсак та, без татарча да рәхәтләнеп укыйбыз, телләребез охшаш бит. Әни үзенең яраткан «Сөембикә»сеннән соңгы көненә кадәр аерылмады.

Әнием Әгъзәмова Бану Шамил кызы 1928 елгы иде. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 13 кенә яшь була. Әтиләре дүрт ел сугышта булып, балалары бәхетеннән 1945 елның көзендә исән-имин кайтып төшә. Җиденче классны тәмамлагач, әни бер ел ФЗӨдә укый. Ул вакытларда җиде класс белем зур белем саналган инде, әнине дә күрше авыл мәктәбенә укытучы итеп билгелиләр. Дүрт ел эшли ул анда, төшкә кадәр укыта, төштән соң колхоз эшенә чыга. Печәнчеләргә, игенчеләргә аш бүлеп торуны гел аңа ышанып тапшыралар. «Син хәрамләшмисең, дөрес итеп бүләсең», – диләр. Сугыш чоры, авыр заманнар бит. Өскә кияргә кием, тамакка ашарга ризык юк. Олы әсәем Хәдичә оста тегүче була. Аңа кием тектерергә күрше авыллардан, хәтта Чиләбе өлкәсеннән дә киләләр. Костюмнар, пальтолар, чалбарлар тегә. Берәүдән эш хакына дип, буй-буй юллы ирләр костюмын сорап ала да, шуны бозып, күлмәк тегеп бирә. «Шундый матур чыкты ул. Шуны киеп, әллә кем булып киттем эшкә!» – дип сөйли иде әни. Сугыштан соң ике ел «избач»та – китапханәдә дә эшли әле ул. Кияүгә чыга, кызы туа, ләкин гаилә тормышы барып чыкмый.

Укырга теләге көчле була әнинең. Мәктәпне тәмамлаганына ун ел вакыт үткәч, 3 яшьлек кызын әти-әнисенә

калдырып торып, кабаттан мәктәп партасына утыра. «Үземнән күпкә яшь балалар белән укып йөрүе кыен булды», – дип сөйли иде. Авыр булса да, кызын бик сагынса да, әни урта мәктәпне әйбәт кенә тәмамлый. Авылга кайтып сельпога урнаша. Соңрак Бөре шәһәрендәге кооператив техникумын тәмамлый. Минем булачак әтием белән танышып, гаилә бәхетен тагын бер кат сынап карарга уйлый. Белемле, тәрбияле, уңган, тырыш әнигә бу юлы да бәхет елмаймый. Басылып, тукмалып, мескен булып яшәүгә ризалашмый ул.

Унъеллык мәктәпне тәмамлаганына ун ел үткәч, әни Белорет шәһәрендәге педагогика техникумына укырга керә. «Балачагымнан укытучы булырга хыялландым. Сугыш вакытында укытып йөргәннәремне сагынам», – ди иде. Укырга керү дип әйтүе генә ансат: ул инде ике бала анасы бит! Җиңел булмый әнигә укуы. «Бер стипендияне өчкә бүләм – ике балама, үземә. Ач йөреп, коры сөяккә калдым. Һушымны җуйганым да булды», – дип сөйләгәне хәтердә. Укуын тәмамлагач, аны юллама белән Белорет шәһәрендә эшкә калдыралар. Мәктәптә математика фәнен укыта. Яшәренә йорт бирәләр. Яшьли вафат булган апасының улы да безгә килеп сыена.

Кешенең шулкадәр укырга теләгән күр син! Бер елдан әни янә студент була – Магнитогорск шәһәренең педагогика институтына читтән торып укырга керә. Үзе сессиягә киткәндә мине һәм мал-туарны таныш хатынына калдырып тора иде. Укырга теләге никадәр генә көчле булса да, институтны ташларга туры килде әнигә. Аның мине үстерәсе, тормышны сөйрисе, ике студент – апам белән агамны укытасы бар иде шул. Укуын ташлавына үкенмәде, балаларым укыды, дип сөенеп яшәде. Үз авылыбызда урта мәктәп ачылгач, шунда күченеп кайттык. Пенсиягә чыкканчы авыл мәктәбендә укытты. 84 яшендә дә әни югары класста укыган кызыма алгебрадан мәсьәләләр чишәргә булышты әле. «Хәзерге программа катлаулы, кая, бераз уйлыйм», – дисә дә, барысын да дөп-дөрес итеп чишкән булып чыга иде.


«Тынычлык» мәчетенә ай куелган көн. 1999 ел, 16 июль.

84 яшендә, 2013 елда китте әни. Үзе яздырып калдырган газета-журналлары әле август аена кадәр аның истәлеге булып өебезгә килеп торды. Укыган бер журналын саклап куяр иде. Кайсыдыр саны килми торса, «Белеш әле, ник журналымны китермиләр?» – дип, миңа район үзәгенә барып белешергә куша. Андагы почтада эшләүчеләр әнине инде күптән белеп бетергән. Белмичә! Бөтен районына бер безнең әни генә алдырды бит «Сөембикә»не. Быел менә үзем дә журналга язылдым. Бик яратып укыйм. Ул миңа әниемнең төсе сыман.

Илдусә МӨСӘЛИМОВА.
Башкортстан, Әбҗәлил районы.

Рәшидә абыстай Исхакованың арабыздан киткәненә быелның апрелендә җиде ел. Аны искә алмаган кешебез бар микән? Гаҗәеп кеше иде ул.

2016 елның 22 апреле. Җомга көн. Рәшидә абыстай белән хушлашырга килгән машиналар Тынычлык бистәсенең урамнарына сыймый. Бөтен Казан кубарылып килгән диярсең. Бу югалту белән күңелнең һич тә килешәсе килми. Ул бер дә үлмәс кебек иде. Көчле рухлы, олы җанлы кеше булды. 92 яше тулырга өч ай калгач, иртәнге намазга азан әйткән мизгелдә күзләре мәңгелеккә йомылган.

Рәшидә абыстайны белмәгән, аның турында ишетмәгән кеше сирәктер. Дин тыелган елларда да исламга тугры булып, Аллаһ юлында хезмәт итте ул. Аның вәгазьләре белән дингә килгән, ул әзерләгән «Намаз уку тәртибе» китабы белән намазга баскан, аның дәресләренә йөреп Коръән укырга өйрәнгән кешеләрне санап бетергесез. Шәкертләрне үз өенә җыеп та укытты, үзләре килә алмаганнарның өйләренә барып та дәрес бирде. Шәкертләренең хәзер күбесе инде үзләре остаз, алар Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә аның эшен дәвам итәләр.

Тынычлык бистәбездәге «Тынычлык» мәчете дә аның хәер-фатыйхасы, ярдәме белән төзелде. Китапларын саткан акчаларны да, сәдака итеп бирелгәннәрен дә – барысын да мәчет төзелешенә бирде. Олы яшьтә булса да, дини бәйрәмнәрдә, җыелышларда чыгышлар ясады. Вәгазьләре шулкадәр үтемле, истә кала, уйландыра иде.

«Мөслимә» хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы белән дә гел хезмәттәшлек итеп торды. «Мөслимә» газетасының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган журналист Әлмира Әдиатуллина белән бергәләп 1997 елда Коръән уку буенча «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесен оештырып җибәрделәр. Соңыннан бу бәйге ел саен уздырылып, анда катнашкан балаларга Рәшидә абыстай исеменнән бүләкләр тапшырылды.

Үз балаларын да чын мөселман итеп тәрбияли алды Рәшидә абыстай. Улы Госман Исхакый 13 ел Татарстанда мөфти вазыйфасын башкарды.

Мин үзем дә мәчеттә алты ел балалар укыттым. Киңәш кирәксә, Рәшидә абыстайга килдем. Бик игътибарлы, ярдәмчел кеше иде ул. Һәрчак чиста, пөхтә йөрде. Башында – ап-ак яулык, иңендә ак шәл булды. Ул безнең күңелләрдә дә шулай ап-ак булып, нурлы, иманлы, юмарт булып саклана. Урыны оҗмахта булсын.

Сәлимә абыстай ХӨСӘЕНОВА.
Казан шәһәре, Тынычлык бистәсе.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар ур, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru



СИН ӨЙРӘТКӘНЧӘ ЯШИБЕЗ, ӘНИ!



Әниләре турындагы истәлекләрнең һәркайсы үзе бер тәрбия сабагы, әхлак-әдәп дәресе. Ул истәлекләр күп, бик күп. Һәркайсы Саимә апаның зирәклеген, сабырлыгын, гадилеген, тырышлыгын, тәрбия бирү осталыгын ача. Ул хатирәләрнең әле икеләтә кыйммәте дә бар: аларда ил тарихы, халык язмышы да чагыла.

Дөньяда миллион-миллион әниләр бар. Ә аларның әнисе берәүнекенә дә охшамаган! Шул миллионнарның берсе дә аның кебек була алмас! Ишле гаиләдәге сигез баланың һәрберсе өчен дә ул бер генә, бердәнбер! Рәшидә, Рәхилә, Рәшит, Ринат, Рәсимә, Ирек, Илнур, Рафис... Балаларының һәркайсы булдыклы, эшчән, намуслы булып үскән.

Кем соң ул Саимә апа? 8 баланың әнисе, 20 онык, 19 оныкчыкның дәү әнисе – нинди ул?

Олы кызы Рәшидә – республикабызның мөхтәрәм җитәкче хатын-кызларының берсе Вәлиуллова Рәшидә Рәфыйк кызы – газиз әниләре турында сәгатьләр буе да сөйли алыр иде. Аны тыңлыйсың да, тормышның ачысын-төчесен, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатен җилкәсендә күтәргән гади авыл хатынының һәр гамәле – балалары өчен үрнәк, һәр киңәше – кагыйдә, яшәү өлгесе булган икән дип сокланып куясың.

«Әни – сугыш чоры баласы. 1938 елның 20 апрелендә Биектау районы Коркачык авылында туган ул. Сугыш башланып, тормышның асты-өскә килгән бер заманда ул 3 яшеннән Саба районы Татар Икшермәсе авылында, әнисенең туганнарында яши башлаган. Шулай килеп чыккан инде: әнинең әтисен – Гарәфетдин бабабызны сугышка алганнар. Әнисе Гандәлиф гаиләдәге дүрт баланың кечерәкләрен – әнине бер туганнарда, энесен икенче туганнарында калдырып торып, ике олы кызын үзе белән алып, Ташкент якларына китеп барган. Үстергән әнисе – Тайфә, әтисе – Ибраһим, ягъни Саимә Ибраһим кызы. Аларның үз балалары булмаган. Әнинең фамилиясе әти буенча – Газизуллина, үзенең әтисе буенча – Шәйхетдинова, үстергән әтисе буенча Ибраева. Менә шундый язмыш. Соңрак, үзе җиткән кыз булгач, тапкан әнисе Гандәлиф әбиебез белән дә күрешкән әни, якынаеп киткәннәр, хәбәрләшеп яшәгәннәр. Ә бу үстергән әти-әнисе бик тәртипле, тырыш, эшчән кешеләр булуы белән билгеле: бабай – совхозда бригадир, Тайфә әби бик әйбәт хуҗабикә. Әнине дә шундый итеп тәрбияләгән. Әти белән әни безне эш сөючән, җаваплылыкны үз өстенә ала, үз көннәрен үзләре күрә, әйткән сүзендә тора белә, илгә, ха-

лыкка хезмәт итә торган кешеләр итеп үстерделәр. Бөтенебез дә тормышта үз юлын тапты. Әти белән әнинең тәрбиясе инде бу! Сигезебезнең бишесе – ир балалар, бишесе дә армия сафларында хезмәт иттеләр. Рәшит – Әфган сугышларын кичте, Кызыл Йолдыз ордены, «За боевые заслуги» медале бар; төпчегебез Рафис – Чечняны үткән егет. Инде Ринатыбыз кызының кияве дә бүгенге көндә хәрби операциядә. Армиягә бармый калу дигән уй башларына да килмәде безнекеләрнең, чөнки өйдә шундый тәрбия иде. Әтинең әтисе сугыш кырларында – Орел өлкәсендә ятып калган. Аның турында Хәтер китабында да язылган. Әнинең әтисе сугышларны үтеп кайтып дөнья куйган...»

«Әни яшь чагында бигрәк тә чибәр булган. Кап-кара озын чәчле, зәңгәр күзле... Бик чиста-пөхтә киенеп йөргән. Әтигә – 18, әнигә 17 яшь булганда өйләнешкәннәр. Ул тарихны белүчеләр хәзер дә бар. Татар Икшермәсендә Сабан туе көнендә Мәүлә Рәфыйгы, дуслары белән ат җигеп, Чыпчык Ибраеның Саимәсен урлап алып кайтты, дип сөйлиләр. Әниләрнең тау башындагы өй тәрәзәләре әтиләр өеннән гел күренеп торган... Ә ул өйдә әтинең әнисе – дәү әниебез Нәгыймә, Газизулла бабай сугышта үлеп калып, аның әнисе Мәхдүмә, Нәгыймә әбинең әнисе Зөлхәбирә әбиләр дә яшәп ята икән. Озын толымлы 17 яшьлек чибәр кыз әнә шул өйгә килен булып төшкән! Берүзенә ничә кайнана! Кызганыч, 23 яшендә авырып, дүрт ай буена больницада яткач, әнинең ул озын чәчләрен кисеп бетергәннәр. Толымнары бик озак чемоданда ятты әле. Аннары аны бер туганы сорап алып, шиньон ясатты...»

Әниләре чиккән ишек-тәрәзә пәрдәләре, мендәр тышлары, ул бәйләгән карават җәймәләре, сырган юрганнар, тәрәзә тутырып утырган яран гөлләр, ап-ак итеп акшарланган мич... (Әни атна саен мичне агарттыра иде, дип искә төшерә Рәшидә ханым). Өстәлдә – әниләре яшьтән үк алдырып, яратып укый торган «Азат хатын» журналы. Саимә апа: «Менә «Азат хатын»да шулай язганнар...» дип, берәр гыйбрәтле язмыш турында сөйләп куя. Еллар узгач, өйгә ул журнал «Сөембикә» булып килә башлый... (Шунысы кызык: әтиләренең сеңлесе, Красноярскида яшәүче 83 яшьлек Сәлимә апа да бүгенге көнгәчә «Сөембикә»не алдыра икән!) Өйгә хуш ис таралган: каз маеннан ясалган сызык тәме борыннарны ярып керә... Мичтә дучмак пешә. Чәй эчкәндә өстәлгә баллы төш, чәлпәк куела. Әниләренең бик яратып пешерә торган «Пәхри бәрәңгесе» бар бит әле тагын! Әрчеп, урталай ярып табага тезелгән бәрәңгегә туң май да салып җибәрсәң – кызарып, кетердәп, шундый тәмле булып пешә! Хәтта күрше Оркыя апа малае Илдус, кызыгып: «Без дә бәрәңге ашарга керик әле», – ди! Олы кыз Рәшидә күрше авыл Иске Икшермә мәктәбенә бишенче класска җәяү йөреп укый. Ул инде пычкы тотып утын да кисә, бәлешне дә үзе пешерә белә. Әне-сеңелләре аңа «апа» дип эндәшә. (Берзаман Рәшидә апалары, мәктәпне «биш»кә генә тәмамлап, Казан университетының юридик факультетына укырга да китеп барачак әле. «Гаделлекне, дөреслекне якларга укы, кызым», дип озаталар бит аны. Хәер, апалары артыннан калганнары да югары белем ала, үз юлларын таба...) Ишегалдында яшел чирәмдә кечерәк балалар каз бәбкәләре саклый. Әнә, кызлар, көянтә-чиләкләр асып, Якуп бабай чишмәсеннән су ташыйлар, Дүли чишмәсендә керләр чайкыйлар. Өсләрендә – әниләре тегеп кидергән күлмәкләр. Малайлар көтү көтә. Аларның белмәгән эше юк. Әтиләреннән күрмәкче, бөтен эшкә алыналар. Кирәк икән, ялт итеп токмачын да кисеп куялар, табын да әзерлиләр... Тагын бер кызык истәлек: матчага тал чыбыгы да кыстырылган була әле. Биш малай бит: әниләре кайчак шул чыбык белән дә тамызып ала. Әтиләре иртә таңнан эштә. Ул бөтен эшне белә, бөтен эшкә алына. Ә малайлар, үсә-үсә, бура бурарга да, машиналар ремонтларга да аңардан өйрәнәләр.

Әни сүзен җиренә җиткереп үтәмәсәң, оят булыр иде...

Сигез баласы өчен дә кадерле әнә шул хатирә-картина, еллар узса да, һаман төсен, яктылыгын җуймый: балачакны сагындырып гел күз алдына килеп баса.

Әниләре йә чөгендер басуында, йә бәрәңге бакчасында, йә кош-корт арасында. Ул ничектер җайлы гына итеп балаларын да эшләтә белә: чөгендер дә эшкәртәләр, су да ташыйлар, утын да кисәләр... Кечкенәдән үк хезмәт яратырга, һәр эшне төгәл итеп, җиренә җиткереп башкарырга өйрәтеп үстергәч соң!..

«Ни гаҗәп, җыенныбызга лидерлык сыйфатлары хас. Анысы да – әнидән. Ул бөтен әйберне тәртипләп куюны, һәр эшне төгәл үтәүне таләп итә иде. Әнидә оештыру сәләте бик көчле. Бәйрәмнәрдә өйдә җыелып концертлар куюны ул уйлап таба иде. Мин – олы бала буларак, алып баручы. Кем шигырь сөйли, кем җырлый, кем бии. Әни безне җыйнап-җыештырып, концертлар әзерләтеп мәш килә иде. Бергәләп нинди генә җырлар җырламыйбыз! Әни өйрәтә инде. Ул татар әдәбиятына, татар сәнгатенә мөкиббән. Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен яратып укый. Гаҗәпләнәсе дә юк: күренекле галим, китап белгече, академик Әбрар Кәримуллин белән бер тамырдан бит, аның чыбык очы туганы! Шактый еллар, пенсиягә чыкканчы клубта җыештыручы булып эшләде әни. Шул чакта концертлар белән килгән Флёра апа Сөләймановасны безгә кунарга алып кайткан иде. Композитор Заһид Хәбибуллинның, Сара апа Садыйкованың безнең өйгә кайтканнарын хәтерлим. Ә әти турында авыл китапханәчесе: «Рәфыйк абый укымаган китап калмады», – дип әйтә иде. Бальзакның 40 томлык әсәрләренә кадәр укыган кеше ул! Гап-гади бал-

та остасы димәссең дә! Рәфыйк абый бураның иң авыр башын үзе күтәрә иде, диләр. Кое казыган, халыкка су табып биргән кеше изге дип санала. Менә безнең әти дә кое казып, буралар бурап төшереп, авыл халкының рәхмәтен алган кеше...»

«Әнигә «карчык» дип эндәшә иде әти. «Атасы, сиңа әйтәм...» – монысы әни сүзләре. «Атагыз, атагыз» дип кенә тора. Гаиләне ничек итеп кору, ничек итеп алып бару тәртибен өйрәтеп үстерде ул. Әти кайтуга ашарга пешерелгән, табынга куелган, бөтен балалар җыелган, аның кайтып керүен көтеп торабыз. Әти кайтмыйча өстәл артына утыру юк. «Ирләр – дөньяның тоткасы! Алар ничек итеп бора – шулай була!» – дип кабатлый иде әни. «Буйсына ала торган кешеләргә генә буйсынырга кирәк. Буйсынырга лаек булмаса – буйсынма!» Монысы да әни сүзләре. Мин кул астында хезмәт иткән кешеләр – буйсынырга лаек кешеләр, шуңа күрә буйсынам. Аңа хәзер 85 яшь. Кемгә буйсынырга, кемгә буйсынмаска икәнен бик яхшы белә. Үз сүзен нык итеп әйтә ул. Әнинең сүзе – закон. Минем өчен дә закон. Әнинең хәтерен калдырмаска, үпкәләтмәскә дип яшим гомерем буе».

«Син тыңлаулы бала идең, бөтен эшне үзең белеп эшли идең, ди ул. Әни сүзен тыңламый калырга намусым җитми иде. Әни сүзен җиренә җиткереп үтәмәсәң, оят булыр иде...»

Иргә хөрмәт дигәнне дә әниләреннән сеңдереп үсә алар. «Иң беренче ир ягын кайгыртырга кирәк. Миңа бүләк алырга акчагыз булмаса да, кайнанагызга алыгыз», – дип өйрәтте безне. Бу сүзләр кагыйдә булып күңелгә кереп калган. Бервакыт безгә ашка әни белән кайнанам бергә килеп керделәр. Иң беренче кайнанам белән күрештем дә аны чишендерергә тотындым. Әни бераз үпкәләгән кебек: «Синдә генә булды инде кайнана!» – дип әйтеп куймасынмы! «Әни, син үзең шулай өйрәттең бит. Иң беренче кайнанагызга хөрмәт күрсәтегез, дидең», – дим. Минем артта кунакка килгән кызым белән киявем, улым белән киленем, кода-кодагыйлар басып тора. Алар да нәрсә әйткәнемне ишетеп торалар. «Синең тәрбия бит, әни, син әйткәнчә эшлим», – дигәч, и шатланды, и күңеле булды инде әнинең!»

Аның киңәшләре алтын бәясенә торырлык, диләр. Һәркайсын тормыш кагыйдәсе итеп күңелләренә салып куйганнар. Илгә, халыкка хезмәт итәргә, гадел булырга, кеше әйберенә тимәскә, башкаларны рәнҗетмәскә, көнләшмәскә, алдашмаска, әйткән сүздә торырга, тигез итеп бүлешергә... Һәм ул кагыйдәләр һәр эштә, һәр адымда иң туры юл, дөрес чишелеш булып калкып чыга.

«2020 елда өч энебез – Ринат та, Ирек тә, Рафис та бер-бер артлы китеп барды. Берсендә инсульт, берсенең йөрәге кинәт туктады, берсе юл һәлакәтендә һәлак булды... Әни төпчеге Рафиста – Икшермәдәге төп йортта яши иде. Хәзер төп яшәгән урыны – Биектауда, җиденче улы Илнур белән киленебез Лениза янында. Олы улы Рәшитләр дә каршыда гына: гел булышып, кайгыртып торалар. Әле беребез, әле икенчебез әнине үзләренә кунакка алып китә. Йә Югары Осланда, йә Икшермәдә ул. Балалар янында булса, янына килсәләр шатлана. Нәрсә бүләк итсәләр дә сөенә. Киленнәр дә, кияүләр дә – барысы да әнигә карата бик игътибарлы. Ирем Харис та кочак-кочак чәчәкләр бүләк итте гел. Инде ул да арабызда юк... Рәхиләнең Вагыйзе дә... Ә Рәсимәнең Олегы әнине ничек хөрмәтләгәнен күрсәгез иде! Шуңа да кияүләренә аерым бер җылы мөнәсәбәттер. Ләкин әни барыбер дә: «Мин бөтенегезне дә бертигез яратам», – ди. Киленнәр Рузалия, Лена, Лениза, Роза, Гөлназ, Ләйсәннәр – һәммәсе үз кызлары кебек якын аңа. Кайда менә хәзер, менә бүген әни кирәк – ул шунда. Ирем вафатына 51 көн булганчы әни көн саен кич минем янга килеп куна кала иде. Кемгә авыр, шуның хәлен җиңеләйтергә тырыша шулай. Үзе көне-төне догада. Шуның белән яши ул...»

Әнисенең туган көне алдыннан Рәшидә ханым әнә шундый уйдык-уйдык мизгелләрне исенә төшереп утырды. Балачакны сагыну да, тирән ярату да, олы хөрмәт тә, чиксез рәхмәтләр дә сыйган ул хатирәләргә.

...Балалар, оныклар тагын Саимә апаны котларга җыелыр. Чәчәкләргә күмәрләр. Балачакта өйдә куйган концертларын искә төшереп, бергәләп җырларлар. «Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа», дип тә, «Менә без дә үсеп җиттек, әни», дип тә... Әниләре эчкерсез елмаеп, күзләреннән якты нур сирпеп, рәхмәт укып утырыр. *Җыелдыгыз минем бәйрәмемә, / Шөкер, без үзебез – бер дәүләт. / Бәйрәмнәрдә яшәтәсез мине, / Балаларым, сезгә зур рәхмәт! / Һәрберегезгә хәердога кылам, / Һәрчак сезне уйлап янам мин. / Кайда булып, нәрсә кылсагыз да, / Һәрчак сезнең белән барам мин,* – дип, узган юбилеенда рәхмәтен шигырь белән белдереп тә шаккаттырган инде балаларын.

Менә шундый әни! Үзе дә апрель кебек: җылы, якты, кояшлы. Чәчәкле күлмәге дә, ак яулыгы да, алкалары да килешле, җанга якын. Балачактагы сыман һаман аңа сыенасы, аннан сөеләсе килә.

Эльмира ЗАКИРОВА



■ «Әнинең 80 яшендә дә сигезебез дә бергәләп «Әниемнең җылы кочагы»н җырладык. Балачактан яраткан, таныш җыр. Сигезебез дә җыела алдык ул чакта.

■ 80 нче биттәге фотода: кечкенә Рәшидә әти-әнисе белән.

АШЫГЫРГА КИРӘКМИ!

Олеся МУСТАЕВА, косметика химик-технологы – косметиканы җитештерүче һәм нигез салучы: «Ике сезон арасында битнең тиресе аеруча сизгер. Бер яктан – җылылык радиаторлары аркасындагы коры һава, икенче яктан – инде активлашып өлгергән кояш тәэсир итә аңа. Шунлыктан тирене дымландырабыз һәм саклыйбыз!»

Язгы кояш нурлары баш киемнәрен салырга, куртканың юкарагын кияргә һәм бит тиресен җәйгечә – җиңелчәрәк тәрбияләү чараларына күчәргә ымсындыра. Ләкин ашыгырга кирәкми! Тәрбия чараларын һәрвакыт, шул исәптән, ике сезон арасында да, тиренең хәзерге халәтенә һәм ихтыяҗына карап сайларга кирәк.

Яз дәвамында дип әйтерлек, өйләрдә җылылык системалары эшли. Бу исә тиренең кипшенүенә, кубалаклануына һәм ялкынсынуына китерә. Бер үк вакытта урамдагы кояш көннән-көн активрак һәм ул бит тиресе өчен кремнарның SPF саклау үзлеге булганнарын сайлау кирәклегенә ишарәли. Шунлыктан тирене яхшылап дымландыру белән бергә ультрашәмәхә нурлардан тиешенчә саклау турында да онытмыйбыз.

Тирене кояштан саклаучы көндезге крем берьюлы ике бурычны үтәсә – бит тиресен дымландырса һәм аның күзәнәкләрен стресстан, зыянлы факторлардан (кояш нуры, шәһәр сөреме, тузан һәм башкалар) сакласа – идеаль вариант.

Үзебездә җитештерелгән косметика базарында андый вариантны Олеся Мустаева остаханәсендә ясалган кремнар арасыннан табарга була. Ул – Sun Ray SPF 35 кремы. Әлеге крем UVB һәм UVA нурларыннан саклый, тирегә җиңел ягыла, агарып калмый, шул ук вакытта тирене дымландыра да.

Ике сезон арасындагы күчеш чорында тирене тәрбияләү өчен аның саклык функцияләрен торгызырга ярдәм иткән чараларны куллану мөһим. Бит тиресе өчен сыйфатлы тоник әнә шундыйлардан. «Она иная» брендының тонигын кулланып карарга киңәш итәбез.

Югарыда язылган кагыйдәләрне үтәп һәм нәтиҗәле косметик чаралар кулланып, бит тирегезнең «тормышын җиңеләйтәсез», аңа ике сезон арасына хас «сюрпризлардан» интегергә ирек бирмисез.

1



Бит өчен Sun Ray SPF 35 кремы:
- UVB һәм UVA нурланыштан саклауның киң спектры
- бит тиресен көн дә тәрбияләү өчен пептидлы крем
- тирегә тиз сеңә һәм агартмый
- фотокартаюдан шәп профилактика

2



«Она иная» тонигы:
- дымландыра
- кызыллыкны сизелерлек киметә
- тирене стресслардан саклый
- тиредәге картаю процессларын тоткарлый (anti-age)
- тиренең төсен тигезли

 mustaeva_beauty  masteromcom www.master-om.com 

Реклама. ИП Мустаева О.Н. ОГРНИП 311168919600013

БӘХЕТ ӨЧЕН КҮП КИРӘКМИ...



Хатлар... Аларның кайсы аэропортта язылган, кайсысы кунакханәнең шыксыз бүлмәсендә, сәхнә артында, фатирга керткән Катя түтәй почмагында, юлда, автобус туктаган арада... Һәр җөмләсеннән киләчәккә булган якты өмет ташый, якын итү, ярату һәм, әлбәттә, сагыну саркый. Диләрә ханым ире – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, виртуоз гармунчы Рөстәм Вәлиев язган бу хатларның һәммәсен яттан белә бугай. Шулайдыр, ул бит аларны кайчандыр тыны белән тартып китергәндәй көтеп алган... Егерме дүрт елга сузылган бәхет. Аларның гаилә тормышын, мөгаен, менә шушы кыска гына бер җөмлә белән дә тасвирлап буладыр. Әйе, Диләрәсе Рөстәмнең бар өметен, бар ышанычын аклаган. Рөстәмнең аңа язган хатларын аз гына соңрак укырбыз. Баштан ук башлыйк.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Аларны... безнең журнал таныштыра! Әйе, турыдан-туры булмаса да, «Азат хатын»ның моңа катнашы бар. 1985 ел. Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаган Диләрәне юллама белән эшкә Куйбышев (бүгенге Самара) шәһәренә җибәрәләр. Ә шул җәйне, журналның июль санында Куйбышев татарларының «Ялкынлы яшьлек» ансамбле турында язма басыла. Диләрә укый да, күңеленә салып куя: «Баруга эзләп табарга кирәк!»

Диләрә белән аның дус кызы Флёраны «Металлург» Мәдәният сараенда ул көнне ансамбльнең җитәкчесе Илгиз Колючев үзе каршы ала. Сентябрь уртасы гына була әле. Танышалар. «Татар телен сезнең кебек белгән кызлар безгә бик кирәк, бәлки алып баручы вазыйфасына алынырсыз?» – ди ул. «Азнакайда бию ансамбленә йөрдем, мин биим генә!» – ди Диләрә шунда ук өздереп. Репетицияләр башлана. Очраклы бер туры килү генә булмагандыр бу: ансамбльдә иң элек аңа «Вәлиева» дип дәшәләр. Туфлигә дип үзенә кергән кызга костюмер хатын: «Сез Вәлиевамы? – ди һәм Диләрә артыннан ук бүлмәгә кереп килүче Ренатка ымлый: – Менә бу еге-

тебезнең сеңлесеме? Бигрәк охшагансыз!» (Ренат – Рөстәмнең бертуган энесе, Диләрәгә ансамбльдә аның белән бергә парлап биергә дә туры килә әле.)

Ә бер көнне репетициядән соң Илгиз абыйлары зур яңалык җиткерә: «Шәһәребезгә концерт белән Илһам Шакиров килә! Безнең Рөстәм дә кайтачак». Аның исемен Диләрә беренче тапкыр шул көнне ишетә. Беренче күрүе исә концертта була. Баянчы икән Рөстәм дигән бу егет, ул шушында – Куйбышевта туып-үскән, «Ялкынлы яшьлек»кә дә йөргән. Хәзер Казанда – консерваториядә укый икән... Икенче көнне Илһам Шакиров ансамбльгә йөрүче егет-кызлар белән очраша, аннан залда утырып аларның чыгышларын карый.

– Шул концерт тәмамлангач, фойеда Рөстәм белән күзгә-күз очраштык. Сәхнә артыннан каршыбызга килеп чыкты ул, озын буйлы, бөдрә чәчле... Миңа карады да: «Нинди чибәр кыз!» – диде. Уйлаганын шунда ук әйтә торган гадәте бар иде аның... Икенче көнне Тольяттига концерт куярга киттек. Рөстәм дә безнең белән барды. Кичтән шулай дигәч, үземә күзе төште ахрысы дип уйлаган идем, ә ул минем ягыма борылып та карамады. Юл буе башка кызлар белән шаярды. Ялгыш та сүз кушмады... Концертта да үземә караганын сизмәдем. Соңыннан ул: «Ә мин сине көне буе күзәттем», – диде... Кире кайтканда, шәһәргә кергәндә генә көтмәгәндә яныма килеп утырды. «Сез бит бездә яңа кеше, кайдан килдегез?» – ди. Исемемне сорады, аннан фамилиямне. Яхина диюемне ишетүгә: «О-о-о, әгәр миңа кияүгә чыксагыз һәм мин сезнең фамилияне алсам, бөек композитор кебек Рөстәм Яхин булам бит», – дип көлде. Мин автобустан төшкәндә, ул артымнан: «Берәрсе бәйләнсә, егетем бар дип әйт!» – дип кычкырып калды... Рөстәм үзе игътибар итмәсә, гомеремдә дә аңа карарга җөрьәт итмәс, бигрәк тә үземә каратыйм әле дип нәрсәдер эшли алмас идем. Ул бит инде сәхнә кешесе иде...

Бу октябрь ае була, ә Рөстәмнән хатлар аңа Яңа ел бәйрәмнәре узгач килә башлый. Юк, юк, егет Куйбышевка кайткан булса да, Яңа елны бергә каршы алмый алар. Ул берничә тапкыр кызны шугалакта йөрергә чакырып карый – Диләрә эштән бушамый. Икәүдән-икәү калып сөйләшергә, аралашырга тагын җай чыкмый. Рөстәм Казанга китеп бара. Ә аннары аңардан беренче хат килеп төшә...

Хатларны бик еш яза ул. Ике-өч көнгә берне! Рөстәм туган шәһәренә кабат кайтканда инде апрель була. Ике арада йөргән хатлар инде аларны бер-берсенә шактый якынайтырга өлгергән... Беренче көнне үк ансамбльгә килә ул. Өстендә күн куртка, кулында дипломат. Күчтәнәчләр алып кайткан: һинд чәе, конфетлар... Шул кайтуында Диләрәне бер туганнарына алып керә ул, анда туган көн барганын, үзенең әти-әнисе, гомумән, барлык якыннары шунда җыелганын белеп алып керә. Танышалар.

Берсе – Куйбышевта, икенчесе – Казанда: укый да һәм шул ук вакытта гастрольләрдән дә кайтып керми. Очрашулар аларга, әлбәттә, сирәк эләгә. Берсе бик истә.

Мин үземне бәхетле дип саныйм – яраткан кешең белән яшәү бәхет бит ул.

– Җәй көне ялга әни янына Азнакайга кайттым. Рөстәм: «Без Актаныш районында гастрольдә, килсәң әйбәт булыр иде, шундый сагындым», – дип язды. Мин тәвәккәлләгәнче: «Мөслимгә күчтек», – дигән хаты килде. Киттем бит! Каршы алды, кунакханәгә урнаштырды. Илһам абый, Нәфисә Васыйлова, Володя Лапшин, Газинур белән эшләгән чагы. Табигать шундый матур Мөслимдә – Ык буенда йөрдек. Кич авыл клубында концертларын карап утырдым. Аннары бәлеш ашарга алып киттеләр. Мин дә алар белән бергә... Рөстәм: «Тагын бер көнгә кал инде, син булгач рәхәт», – ди. Нинди калу?!.

Тәкъдимне дүрт елдан соң гына ясый әле аңа Рөстәм. Бу вакыт Диләрә инде Брежнев (Чаллы) шәһәренә кайтып эшкә урнашырга өлгерә. 1988 елда Рөстәм консерваторияне тәмамлый, ә тагын бер елдан аңа, ниһаять, фатир бирәләр. Дөресрәге, «служебный» фатир. Кеше почмакларында, филармония урындыкларында йоклап йөрүләрнең дә бер азагы җитә... Туйлары Куйбышевта уза. Ярый әле Рөстәм аңа Бишкәктәге гастрольләреннән кайтып җитәргә өлгерә. Бер атнага гына кушылалар да тагын аерылалар: яшь кияү Казанда кала, ә яшь кәләш Чаллыга баручы автобуска утыра: иртәгә аны эштә көтәләр. Хәер, Рөстәмне дә чираттагы гастроль көтә.

– Шулай еллар буе яшәдек... Әле мин аңа кунакка киләм, әле ул миңа. Исламны Казанда таптым. Рөстәм Украинадан, Донецк шәһәреннән гастрольдән кайтып керде, ә минем тулгагым башланды. Бала тудыру йортыннан да үзе каршылады. Беренче балабызны кыз була дигәч, аңа Алия дип исем дә сайлап куйган идек. Улыбыз тугач Рөстәм: «Алияне дә алып кайтырга бит инде», – диде. Тагын өч елдан Алияле дә булдык... Ә Казанга... Ислам укырга кергән елны гына бөтенләйгә күчеп килә алдым. Фатир алуга, «эштән китәм» дигән гариза язарга тагын намус җитмәде... Иң зур үкенечем ул еллар. Гомернең шулай кыска буласын кем белгән?!.

Егерме дүрт елга сузылган бәхет. Язмамның башында шулай дигән идем. Рөстәм Вәлиевнең инде күмелеп иҗат иткән еллары бу. Егерме елдан артык Илһам Шакировның аккомпаниаторы була, бу хезмәттәшлек аңа уңыш һәм танылу китерә. (Бөек җырчыга уйнау аның яшьлектәге иң зур хыялы!) Баянда гына түгел, ул сәхнәдән сорнай, кубыз, флейта кебек халык уен коралларында да уйный, тальян белән чыгыш ясый. Үзе көйләр иҗат итә. Фирая Зыятдинова шигыренә язган бер җырында шундый юллар бар: «Бәхет өчен күп кирәкми, / Гел янәшә барсын юллар». Бу – аларның икесенең дә иң зур теләге була. Көнләшеп бер-берсенең җанын кыйнамыйлар. «Ул җитми, бу җитми», дип битәрләмиләр. («Вакчыл түгел иде ул. Миңа да синең вакчыл бул-

«Илһам абый сине «әйбәт», ди – ул кешенең ниндилеген шунда ук күрә».

мавың шундый ошый дия, иде».) Талашмыйлар! («Начар сүз әйтмәде Рөстәм миңа. Гомерендә дә! Хәтта ачуы килгәндә дә. Кая ул кычкырышу?! Талашу дигәнне белмәде ул. Берсендә кибеткә чыгып китте һәм бераздан буш кул белән кайтып керде. Чиратта ике хатын талаша башлады, түзмәдем, киттем, ди. Аның кешегә тавыш күтәргәнен күргәнебез булмады, дип искә ала бөтен танышлары».) Гаилә җанлы була Рөстәм, гастрольләрнең берсеннән дә буш кул белән кайтмый. Балаларын ярата, алар белән горурлана. (Алиянең чыгарылыш имтиханнарын йөзәр баллга тапшыруына, Мәскәү дәүләт университетында белем алуына, кытай, инглиз телләрен өйрәнүенә куана. Исламның баянга тартылуына сөенә, әмма бу юнәлештә югары белем алырга теләвен хупламый. Үзе кичергән авырлыклар әле онытылмаган була, күрәсең.) Эшен ярата! («Ул беркайчан да бер генә җырчы белән эшләмәде. Әйтик, Зөһрә Шәрифуллина белән төнлә гастрольдән кайтып керсә, иртән Рәсим Низамов белән чыгып китә. Энергиясе ташып торуына шакката идем!») Баяны белән дөнья гизә: фин татарлары каршында чыгыш ясый, Америка татарларын милли моңга күмә... Үзләре яшәгән йорт тирәсенә сиреньнәр, алмагачлар утырта, бакчасында ни генә үстерми?! Соңгы елларны ул берничә тапкыр: «Булдыра алганымның барысын да эшләдем инде», – дип кабатлый.

– Дус кызым Флёра кечкенә дога китаплары биреп кайтарган иде. Без февраль буе йокларга ятар алдыннан шул китапларны укыдык. Мин укыйм, Рөстәм тыңлый. Кайсы урында, мин әйтергә өлгергәнче, әйтеп җибәрә.



Әбидән хәтерлим, ди. Ул инде җомга намазларына йөри башлаган иде... 5 март көнне мин отчет биреп, Мәскәүдән кайттым. Бергә утырып чәйләр эчтек. Табын артында кайнатам турында сүз чыкты. «Әти бит сине ярата иде, Диләрә», – диде миңа Рөстәм. Аннан табыннан кузгалгач: «Беркайчан онытма, мин дә сине яратам», – дип өстәде. Бу аның миңа әйткән соңгы сүзләре булды... Тагын ярты сәгатьтән...

Ул кичне интернетта татар дөньясына кайгылы хәбәр тарала: «Бүген, 2014 елның 5 мартында күренекле баянчы Рөстәм Вәлиев көтмәгәндә арабыздан китте. Йөрәк... Аңа нибары 52 яшь иде...»

– Аның турында кайчан да булса күз яшьләрсез сөйли алырмын дип уйламый идем... Кайнанам да шулай ди. Аңа хәзер 85 яшь, Рөстәмнән соң кызын – Гөлфия апаны да җирләде әле әнәй. Әмма онытыла торган хәсрәт түгел бу, ул бары күңелеңнең түренә, эченәрәк кенә яшеренә...

Инде хатлардан өзекләр укырга да вакыт җиткәндер.

«Сәлам Казаннан! Дөресен әйтәм, сиңа карата битараф түгел мин, Диләрә. Беләсеңме, үзем өчен идеал тудырдым. Ул кызның нинди булырга тиешлеген беләм. Армиядән кайтканыма да ике ел инде, берәүгә дә күзем төшмәде. Һаман каядыр йөгерәм, укыйм, гастрольләр, гармуннар, китапханә... Ә син шундый табигый, кызларга хас булган тыйнаклык бар синдә. Хәтта ул күп тә. Гел елмаясың. Ул сиңа шундый килешә. Тизрәк үзеңне күрәсем килә. Ә алда гастрольләр: Устинов, Чабаксар, Йошкар-Ола... Безнең бригадада яңалыклар бар. Гөлзадә апа китте, Курамшин да... Мин сиңа шундый ышанам, Диләрә! Тизрәк синең белән кабат очрашасым, сөйләшәсем, якыннанрак беләсем килә. Без синең белән бер-беребезгә охшаганбыз кебек тоела. Ә тышкы яктан шулай охшаганда, кешеләр инде бер-берсен тапкан дип санала икән...»

«Сәлам, Диләрә! Яңа гына кайттым. Быелның беренче концерты Удмуртиядә, Можгада булды. Ни генә дисәләр дә, Илһам абый рәхәт кеше, акыллы да, бик сизгер дә, кайда нәрсә әйтергә яки дәшми калырга икәнен белә. Мәзәкчән! Минем чәчемне кисәргә уйлады әле ул – нәрсә килеп чыгар. Ә син кистермә, яме, сиңа озын чәч килешә.»

«Мари АССРдан сәлам! Почеркыңа караганда син бик пөхтә, җаваплы кешегә охшагансың... Хатым гел зарланудан гына тора инде. Бүген бер авылда чыгыш ясаганда ут сүнде. Юлларны кар күмгән. Тимер юл аша аппаратураны ничек ташуыбызны фотога төшереп, альбом төзергә кирәк әле... Илһам абыйның мине өйләндерәсе килә. Бу мәсьәләдә пәйгамбәр кебек ул: аның киңәше белән кавышкан өч пар бәхетле генә яшәп ята. Ә минем яратасым килә. Чын итеп! Мәхәббәтнең нинди икәнен татыйсым килә!»

«Казаннан язам, әле генә кайтып җиттем. Кичә концерттан соң юлда батып калдык. Көрәк кенә дә юк. Автобусның йөртүчесе исерек. Аннан кырда бензин бетте. Канистра белән күрше авылга барырга туры килде... Илһам абый миңа әти кебек. Мин бит группада иң яше, калганнар барысы да 35 тән өстә.»

«Бөгелмә аэропортыннан сәлам! Хәзер төнге сәгать ике. Артистлар барысы да йоклый, Зиннур Нурмөхәммәтов та. Көнгә бишәр концерт куеп кайтып киләбез... Шундый җылы хатларың өчен рәхмәт сиңа! Кәеф бөтенләй башка хәзер минем, ниндидер бер күтәрелеш тоям. Сине гел искә төшерәм. Миннән бик еш: «Берәр кешең бармы?» – дип сорыйлар. Ә мин сине уйлыйм да: «Әйе!» – дип җавап бирәм... Мөмкин булса, фоторәсемеңне җибәр әле. Кешене яхшырак белү өчен күрешергә, очрашырга кирәк, билгеле. Синең һәрвакыт, һәркайда, һәркемнән яхшырак булуыңны телим. Бөтен яктан да!»

«Казаннан сәлам! Бүген 8 Март. Сезнең көн! Әниләр белән һәм синең белән сөйләшәм дип «переговорга» бардым. Бер сәгать көттем, килмәдең. Мөгаен, син өеңә кайтып киткәнсеңдер, ә бәлки берәр мәшәкатең килеп чыккандыр. Мондый көнне шалтыратасым да булмагандыр. Котлыйсым һәм тавышыңны ишетәсем килгән иде... Ренат сине һәр хатында мактый. Ансамбльдә иң әйбәте ул ди... Сессияне инде тәмамлап киләм. Рус музыкасы тарихы буенча әзерләнәм. Әмма Глазунов балетларына караганда миңа күбрәк татар музыкасы ошый шул.»

«Казан мине май аенда яуган кары белән каршы алды. Өйдә үзем генә, мичкә ягып җибәрдем. Фатир хуҗам инде берничә көн өйдә юк. Тирә-юнемдә тараканнар гына чабыша, салкында туңганнар бугай. Аш пешерергә куйдым. Ә син шундый тәмле әзерлисең!.. Гармун һаман ясамыйлар әле, күн дә, картон да юк, ди. Урамда Хәмдүнә Тимергалиеваны очраттым. Аңа 38 яшь, һаман тулай торакта яши. «Халык ярата да бит, тик ул булыша алмый», – ди. Һәркайсыбызның үз проблемасы инде... Поездда да сине уйладым, гомумән, көн саен синең хакта уйлыйм. Гомер буе сине яратасым килә. Әгәр ошыйм икән, син миннән беркая да китмәячәксең. Әгәр яраткан кешем буласың икән, мин дә гел янәшәңнән барырмын.»

«Исәнме, Диләрә! Без хәзер Киров өлкәсендә эшлибез, инде егерменче көн. 120 шәр чакрым барып концертлар бирәбез... Кайтсам, иң элек синең янга йөгерер идем. Янәшәмдә мине ярты сүздән, карашымнан ук аңлаучы кеше булуын телим. Беләсеңме, аның нәкъ шулай булачагына үземне инандырдым инде.»

«Ә фотода син башкача күренәсең, Диләрә... Без бүген Березняк дигән авылда чыгыш ясадык. Мондагы табигатьнең матурлыгын күрсәң! Халык концертка күрше авыллардан йөк машиналарына төялеп, җырлый-җырлый килә. Кызык күренеш! Иртәнге дүрттә генә ятабыз. Сандугачлар өздерә генә... Кочаклап үбәм үзеңне, күрәсем килә.»

«Бүген концерт булмады, Шакиров авырып китте, тавышы белән нәрсә булгандыр, белмим. Ул, билгеле, герой, халыкка хезмәт итәм дип, юлдан кайтып керми. Юллары да юк бит әле аның... Көне буе китапханәдә шөгыльләндем, гаилә турында мәкаләләр укыдым. Ярый әле син бар, Диләрә. Синең белән аралашу һәрвакыт шатлык миңа. Тизрәк кайтасы, яныңа барасы, шундый тыйнак, оялчан кызны күрәсе иде. Гел шундый булып кал, яме. Аннан, беләсеңме, без синең белән беркайчан да ачуланышмаска тиеш... Чәчәкләрем күптән сулгандыр инде. Кайтуга яңаларын бүләк итәрмен.»

«Килүең өчен рәхмәт, Диләрә! Миңа күпме шатлык алып килүеңне үзең дә белмисең. Илһам абый бүген дә синең хакта сорашты. Тыйнаклыгыңны бик ошаткан. Тәртипле икәнеңне дә күргән, тугры дип тә тапкан... Син янәшәмдә булганда күңелемдә йөргән сүзләрнең берсен дә әйтергә өлгермәдем.»

«Дәрес вакытында язам. Танеевның «Иоанн Дамаскин» кантатасын тыңлыйбыз. Яңа гына Актерлар йортыннан килдем, конкурс булды – филармониягә артистлар сайлап алдылар. Барысы да әйбәт! Ренат Ибраһимов тыңлады, чыгыш ясаганнан соң килеп гармунымны да карап китте. Аны миңа Куйбышевта бер кеше бүләк иткән иде... Консерваториягә йөгергәндә кинәт сине күрәсем килде, Диләрә. Синдәй чиста кешеләр, мөгаен, аздыр. Гел шундый булып кала алсаң иде. Әнәй: «Тәүфыйк булса, бәхет булыр», – ди...»

«Сүзлек сатып алдым әле, сиңа татарча яза башлармын дип уйлыйм.»

«Ераклардан сәлам сиңа! Хәтта нинди шәһәрдә икәнемне дә белмим – Фирганә тирәсендә без. Сорагач язармын. Яңа гына телевизор карадым. Флёрада чак янәшә утырып телевизор каравыбыз искә төште... 100% ышанам – син менә дигән әни булырсың!»

«Ике көнгә генә өйгә кайтып килмәкче булам. Әти авырып киткән анда. Көн-төн эштән бушаганы юк бит аның, бөтенләй ял итә белми. Белсәң иде син минем әти белән әнинең нинди әйбәт икәнлекләрен. Ә икесе арасындагы мөнәсәбәтләр! Менә кемнән үрнәк алырга кирәк. Аларга, икесе арасындагы мәхәббәткә сокланам, алар беркайчан бер-берсеннән туймый. Алла теләсә, һичшиксез, танышырсыз. Яшь чактагы фоторәсемнәрен дә күрсәтермен... Синең белән бергә Идел буенда йөрисем килә. Бәлки инде анда булгансыңдыр да. Безнең йорт урман янында ук бит. Тиздән анда сиреньнәр, шомыртлар чәчәк атар. Табигатьне һәм яхшы кешеләрне яратам.»

«Мин һаман гармуннар артыннан йөрим әле. Тагын бер гармунчыны очраттым. Мостафа бабай Сәлахетдиновны. Өендә дә булдым. Дүрт сәгать сөйләштек. Үз гармуннарымда уйнап та күрсәттем. Аның инструментларының тембрлары искиткеч! Тик хәзер ясамый инде: күптән түгел хатыны үлгән, күзләре дә начар күрә башлаган. Ул миңа тагын бер авылның адресын бирде әле, анда кайбер инструментлар сакланып калган булырга мөмкин ди... Шатлыкта да, кайгыда да бергә булыр кешемне таптым дип саныйм. Бу – иң мөһиме. Син мине көт кенә, яме, Диләрә».

«Чүпрәле районыннан сәлам сиңа! Бүген якшәмбе. Яратам бу көнне! Бигрәк тә җәен. Гаиләмне алып машина белән шәһәр читенә чыгар идем... Хатынымның әнигә охшавын телим. Ул һәрвакыт без дип – балалар дип яши... Мин әлегә вакытлыча Биктаһиров белән эшлим. Бригадада Флера апа Сөләйманова һәм Фирдәвес Җәмилов та бар.»

«Әни бары тик сиңа өйләнүемне тели. Сагындым, тын алуларыңа кадәр сагындым. Трамвайда Илгиз абыйны очраттым. «Бер-берсенә охшаган парлар бәхетле була, диләр. Шундый акыллы кызны ычкындырдың», – ди. Белми...»









Эльмира ЗАКИРОВА

Әти белән әни укытучылар булгач, бик күп газета-журналларга язылалар. «Социалистик Татарстан», «Совет мәктәбе», «Учительская газета», «Иностранный язык в школе», «Физкультура и спорт», «Роман-газета», «Пионерская правда», «Ялкын», «Яшь ленинчы», «Весёлые картинки»лар... Ә Гөлсинәләргә менә «Азат хатын» килә! Шул журнал безнең өйдәге бөтен журналларны бәреп егадыр кебек тоела миңа. Тышлыгында һәрвакыт матур апалар елмаеп торыр. Журнал килгән көн аларда әллә нинди бәйрәмгә әйләнер. Мөхлисә апа сөенеченнән почтальон Рәмзия апаны чәйгә кыстап утыртыр. Журнал түгел, Казаннан бик затлы кунак кайтып төшкән диярсең! Менә-менә журнал-чемодан ачылыр да, ул бүләкләр белән сөендерә башлар: аш-су серләре, табиб киңәшләре, хикәяләр, яңа җырлар, көтеп алынган артистлар, мода, яңа күлмәк өлгеләре... Ни генә юк! И кызыгам, и көнләшәм! Кыз бала бит, хатын-кыз дөньясына тартылуым булгандыр инде үземчә. Берсендә түзмәдем: «Нигә безгә «Азат хатын» килми», – дип, өйдәгеләргә үпкәмне белдердем. «Синең үз журналың бар. «Азат хатын» – әниләр өчен», – дисәләр дә, тәки язылдылар бит! Яңа елдан безгә дә «Азат хатын» килә башлады! Башыннан ахырынача укып, баш редактор Асия Хәсәнова икәнен дә, анда эшләүче журналистларны да белеп торабыз...
Әти белән әни бер җәйне Ленинградка киттеләр. Аулак өйдә сеңлем белән икәү дөнья көтәбез: көтү дә каршылыйбыз, кайтмый калган бәрәннәрне дә елый-елый юллыйбыз, тавык-казларны да карыйбыз, бәрәңге бакчасында чүп тә утыйбыз. Беркөнне үзебезнең оч балалары җиләккә чыгып киттек. Кем тизрәк банканы тутыра дип, ярыша-ярыша җыябыз. Каяндыр яңгыр җилләре исә башлады, кояш та болытлар арасына кереп качты. Көн дә моңсу, үзебез дә боек. Өйдә дә беркем көтми. Җитмәсә, яңгыры да куып тотты. Әниләрне сагынудан, үзебезне җәлләүдән күздән дә яшьләр тама. Үкереп елыйсым килә: сеңлемнән оят. Җиденче классны бетергән җиткән кыз елап торсын инде! Шәбәя барган яңгырдан чак качып, өйгә атылып керсәк... өстәлдә – өр-яңа «Азат хатын»! Тышлыгында – Әлфия апа Авзалова! Кызыл күлмәк, кызыл алкалар! Ул причёскасы тагын... Үзе елмайган! Мин, сөенечтән очып китәрдәй булып, журналны кочаклап сикергәлим. Әллә тизрәк укый башлыйсы, әллә кызларга күрсәтеп мактанасы?.. Яңгыр гына туктасын, хәзер чыгып чабам... Бу көн әнә шулай гомергә онытылмаслык булып күңелемә кереп калган икән: 1970 елның июне иде ул.
Менә шул тылсымлы дөнья, журналист булам дигән хыял мине үзенә тартты. Ә инде соңрак, үзем редакциядә эшли башлагач, «Азат хатын»нан исемнәрен генә укып белгән журналистлар, баш редакторлар белән якыннан аралаштым.
Кызганыч, баш редактор Асия Хәсәнова белән күрешү насыйп булмады миңа. «Безнең Асия Фәридовна бик таләпчән иде. Бик затлы, эрудицияле чын интеллигент. Обкомнан җыелышлардан кайтуын аның туфли үкчәләре тавышыннан ук танып алабыз. Ул журналны дөнья мәйданына чыгарган көчле җитәкче. «Азат хатын»ның тиражы 400 меңгә җитте ул елларда», – дип искә төшерә хезмәттәшләре. Ә калган баш мөхәррирләр белән якыннан таныш булдым. Һәркайсы турында матур истәлекләр саклана күңелдә.

9 нчы КАТТА, КҮРШЕ БҮЛМӘЛӘРДӘ...

Венера апа

Безнең балачакта кызларның, малайларның яратып укый торган «Яшь ленинчы» газетасы бар иде. Ә аның баш редакторы – Венера апа Ихсанова. Юк, ул вакытта әле үзен күреп белмибез, газетада да редактор фотолары белән чыкмый. Соңгы битендә, иң аста «редактор Венера Ихсанова» дигән язудан гына аның кем икәнлеген чамалыйбыз. Гаҗәп, ул газетаны сеңлем белән мин генә түгел, әти белән әни дә кызыксынып укый. Ул почта көтүләр!.. Көтәкөтә көтек булып, инде почта янына әрҗәле машина туктаганын күреп, чыдый алмыйча шунда йөгерәбез. «Яшь ленинчы» килдеме?» – дип, почтадагыларның теңкәсен корытабыз. Менә ул яраткан газетабыз! Мәкаләләр, хатлар, рәсемнәр... Һәм иң ахырда – редактор Венера Ихсанова. Әйтерсең ерактагы шул апа безнең ни уйлаганны, нәрсә укырга теләгәнне Казаннан ук белеп тора! Тылсымчыдыр ул апа! Без ул чакта тимурчылар да, яшь эзтабарлар да, әллә нинди кызыклы эшләр уйлап табучылар да. Җыелма отрядлар оештыруыбыз турындагы беренче мәкаләм 6 нчы класста укыганда басылып чыкты. Газетада исем-фамилиям чыгу ул инде әллә нинди бер могҗиза сыман! Мине үз күреп язылган хатлар да килә башлады редакциядән. Венера Ихсанова кулы белән имзаланган «Яшь ленинчы» грамоталары хәзер дә саклана әле өйдә. Мәктәбебездәге үрнәк хәрби-патриотик тәрбия өчен редакциядән этигә Мактау кәгазе җибәрделәр. Шуннан бирле Венера апа безнең бер туганыбыз, якын кешебез кебегрәк кабул ителде. Ул вакытта класс, отряд, дружина белән «Яшь ленинчы»га язылу була иде. Әнием класс җитәкчесе булган алтынчылар да әнә шулай рапорт биргән, һәм көннәрдән бер көнне газетаның Мактау кәгазе килеп төшмәсенме! Тагын шул – Венера апа Ихсанова кулы белән. Сеңлем газетадан «Яшь химиклар мәктәбе» биремнәрен көтеп ала, җаваплар язып җибәрә. Актив катнашканы өчен аңа да «Яшь ленинчы»ның Мактау кәгазе эләкте. Ә миңа «Яшь хәбәрче» таныклыгы белән бергә килде Мактау кәгазе! Мәктәп линейкасында директор абый зур вакыйга итеп тапшырды аны. «Венера Ихсанова үзе җибәргән!» – дигән сүзләрне дә әйткәч, үземне әлләкем итеп тойдым! Бу апаны бик тә күрәсем килә башлады. Бик матурдыр, бик ягымлыдыр, мөгаен. Җитмәсә, аның балалар язучысы, без китапларын егылып китеп укыган Ләбибә Ихсанованың бертуган сеңлесе икәнен дә белә идек инде. Мәктәптән соң Казанга килеп, университетка керер өчен юллама алырга дип «Яшь ленинчы»га киттем һәм шунда беренче тапкыр Венера апаны күрдем. Абау! Шундый да ягымлы елмаю! Миңа исемем белән дәшә! (Бөтен яшь хәбәрчеләрне дә шулай танып белә микән?) Үз итеп сөйләшә. Мәктәбебез турында сораша, имтиханнарда уңышлар тели...

Университетта укып йөргәндә мин «Ялкын»да эшли башладым. Ә Венера апа ул вакытта инде күршедә генә – «Азат хатын»ның баш редакторы иде. Көн саен исәнләшеп узабыз. «Азат хатын»нар алдында бер башка үсеп киткәндәй булам әле: аларның баш редакторы минем белән үз итеп сөйләшә бит! Елмаюлары, хәлләремне сорашулары, мактап куюлары – барысы да бик җылы, ихлас килеп чыга иде. Эре бизәкле, чәчәкле күлмәкләре аеруча килешә. Бергә эшләргә туры килмәсә дә, мин ерак та китмәдем: гел Венера апаның күз уңында булдым.

Мәдинә, Кояш, Диләра йолдызлыгы

Менә бәхет! Әсәрләре, язмалары белән тәмам сихерләгән, БАМ, КамАЗлар төзүче, Себер магистральләрен сузучы татар кызлары янына ук барып чыккан Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова, Диләра Зөбәерова белән бер бинада, тугызынчы катта, күрше бүлмәләрдә утырабыз. Мәктәптә укыганда ук без, кызлар, шул Диләра Зөбәерова геройлары Назирә, Ленизаларны үз иттек бит инде! Мәктәп, укытучылар дөньясы белән якын иде аның әсәрләре. «Куш өянке шаһит»ын кулдан-кулга йөртеп укыдык. Ә мин үземне Ленизага охшатып, аның кичерешләрен үземнекенә куштым...

...Диләра апа артык гади, артык беркатлы тоелды. Бер күрүдә үк. Зәңгәр күзле, сары чәчле, почык борынлы... Гел елмаеп тора. Миңа беренче күрүендә үк «матурым» дип эндәште. Юк, анысын да үзенчә, авызларын бөрештереп, сүзне көйләбрәк, «маотурем» дип әйтте ул. «Матурым, син кайлардан? Кем буласың?» – дип сорады. Мине тиң күреп сөйләште. Диләра апа кичә генә редакция коридорында очрар, иртәгә инде ерак юлга чыгып киткән булыр. Аның командировкалардан кайтуы үзе бер вакыйга! Шаккатып, сокланып, яратып, күреп кайтканнарын сөйли. Журналистика кысаларына сыеп бетә алмаганнары әдәби образлар булып повестьларына кереп китә...

...Кояш апа – сылу! Фирүзә төсендәге костюм-чалбары, муенына бәйләгән ефәк косынкасы, артка җыеп куйган коңгырт чәчләре – ба-



рысы да бик килешле. Үзе шаян, үзе тәвәккәл. Кунак җыярга, бүләк өләшергә ярата, дип сөйлиләр аның турында. Кемгә – алкалар, кемгә – йөзек, кемгә – муенса... Бервакыт Кояш апаның Дубултыдагы иҗат йортына китәсен ишеттем дә, йомыш белән мөрәҗәгать иттем. Ригадагы коллегама – журналист Лиенага туган көненә чәкчәк җибәрәсем килгән иде. Киң күңелле Кояш апа һич авырыксынып тормады, күчтәнәчемне алып китте. Балтыйк илләреннән урап кайткач, шалтырата: «Кызый, әманәтеңне үтәдем. Сиңа посылка да алып кайттым, кереп ал!» – ди. Кояш апа алып кайткан гәрәбә муенсаны әле дә яратып тагам. Ә Кояш апа Лиена белән очрашуга роза чәчәкләре дә күтәреп барган икән. Әйтәм бит, башкаларны сөендерергә ярата торган Кояш бит ул!

...Мәдинә апаны мин мәктәптә укыганда ук «Азат хатын»дагы «Чаллы баскычлары» хикәясе аша яраткан идем. Аннары «Кар сулары»н укыдым, аннары «Юлдашлар»ны... Ул үзе бер легенда. Журналның җаваплы секретаре булып, таләпчән, кырыс күренеп йөрсә дә (күзлектән тагын да җитдирәк, укымышлырак күренә!), барыбер хатын-кыз җылылыгы, әниләр йомшаклыгы саркып килеп чыга аңардан. Үзенең белмәгәне юк. Парашюттан да сикергән, пединститутның шахмат чемпионы да булган, салкын көзләргәчә Казансуда йөзә дә икән. Татарның романнары белән таң калдырган беренче хатын-кыз язучысы! Төнгә каршы язарга утырып, башлаган әсәрен машинкада сигез-ун биткә арттырмаса, йоклый алмый торган Мәдинә Маликова. Аның белән артык якынаеп сөйләшкәнем юк иде. Декрет ялына китәргә җыенып йөргән көннәрем. Каршыма Мәдинә апа очрап, бүлмәсенә алып кереп китте дә, миңа, булачак яшь әнигә әллә никадәр киңәшләр бирде. Аннары «Сөйкемле Эльмирага бәхетле әни булуын телим», дип язып, табиб киңәшләре язылган китап та бүләк итте әле. Тамчы да кырыс түгел икән!

...Ә Эльмира апа Әдиатуллина журналның техник редакторы иде ул елларда. Редакция белән типография арасында йөгереп кенә йөри. Бик ачык. Матур җырлый. Кайчак аның «Ашказар»ны моңлы итеп җырлаганын ишеткәлибез. «Бала, син минем якташым икән бит», – дип, мине шундук якын итте. Ул Башкортстанның Илеш районыннан, ә минем туган авылым ике республика чигенә урнашкан. Байсардан Эльмира апаның Сәеткулына 40 чакрым гынадыр. Һәм менә мондый бер истәлек сөйли. «Берчак Сәеткулга кайтырга чыктык. Юл ерак, төнгә калдык. Бик арыдык. Байсарда Сөн күпереннән чыгып, Чишмәбаш урамыннан узабыз. Кап-караңгы. Бердәнбер өйнең тәрәзәсендә ут яна. Машинадан төшеп, шул тәрәзәне шакыдым. Яшь хатын ишекне ачып, түргә уздырды. Исеме Әлфирә икән. Тракторчы ире Фирдәвеснең эштән кайтуын көтә иде. Без – юлчыларга чәй куеп җибәрде. Ә өстәлдә – «Азат хатын» ята! Әчкә җылы йөгерде. «Бала, бездән курыкма. Мин менә шушы журналда эшләүче Эльмира апаң булам», – дип, «техник редактор Э. Әдиатуллина» дигән язуга төртеп күрсәтәм. Әлфирә йөгерә-йөгерә табын әзерли. Баздан әллә ничә төрле варенье алып менә, бал, сөт өсте, кызыл эремчек куя. Үзе пешергән ипине кисә... Көтмәгәндә әнә шулай кунак булдык!»

Эльмира апа мине күргән саен: «Бала, кайтсаң, Әлфирәгә сәлам әйт!» – ди торган иде. Бер җәйдә фотограф Рөстәм Мөхәммәтҗанов белән безнең авыл Сабан туеннан фоторепортаж әзерләргә кайттык. Сабан туенда Әлфирә апаны да күреп, сәламнәр тапшырдым. Икенче көнне Казанга китәр алдыннан зур өч пакет күтәреп Әлфирә апа килеп керде. Һәр пакетта мичтә үзе пешергән түгәрәк ипи, банкада яңа аерткан каймак. «Берсе сиңа, берсе Рөстәм абыйга, ә монысын Әлмира апага тапшырырсыз», – ди. Ә Эльмира апа белән бер тирәдә яшәгән Рөстәм көне-сәгате белән үк авыл күчтәнәчен адресатына кертеп тапшырган.

Роза апа

Венера Ихсанова «Азат хатын»га баш редактор булып китүгә, декрет ялында утырган шәкерте Роза Туфитуллованы аның урынына «Яшь ленинчы» редакторы итеп билгелиләр. Сөйкемле, яшь, чибәр Роза балалар дөньясында йөзә генә! Газетага әллә никадәр яңалык кертә, берсеннән-берсе кызыклы идеяләре ташып тора. 1986 елның җәй ахырында аны безгә – «Ялкын»га баш редактор итеп куйдылар. Беренче сөенче хәбәрен шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов җиткерде. Бу вакыйганы үзе хәл иткән кыяфәттә җил-җил атлап кереп, вәкарь генә: «Редакторыгыз Туфитуллова булачак!» – дигән җөмләсен ыргытып кына чыкты да, «Азат хатын», «Чаян» редакцияләре тарафына китеп югалды. Белеп-ме-белмиме юраганы юш килде: без читтән генә сокланып йөргән Роза апа сигезенче каттан – «Яшь ленинчы»дан – тугызынчы катка менеп кенә утырды. Дөресрәге, Мәскәүдән, ВЛКСМ Үзәк Комитетыннан баш редактор итеп раслап кайтардылар аны. Тәвәккәл, тынгысыз, яңалыкка омтылучан, үтә нечкә тоемлы, зәвыклы... Әнә шундый сыйфатларга ия редакторыбызга карап, хатын-кыз журналист менә шундый булырга тиештер дигән кагыйдә бөреләнде күңелдә. Башка газета-журнал редакторлары да, аерым журналистлар да гел аңа киңәшкә керә, Роза апаның сүзе кайда да үтә! Еш кына үзен Мәскәүгә зур киңәшмәләргә чакыралар. Шул елларда аны комсомолның XX съездына, Яшьләрнең һәм студентларның Мәскәүдә узган Бөтендөнья фестиваленә делегат итеп озатабыз. Үзен «Вожатый» журналына да, Бөтенсоюз пионер оешмасының Үзәк Советы аппаратына да эшкә чакырып карадылар. Республикадагы балалар дөньясын, пионер, комсомол оешмалары эшен аннан башка күз алдына да китереп булмый иде бит. Шул хәбәрне ишеткәч нәүмизләнеп калганыбызны күреп: «Юк, кызлар, сезне ташлап беркая китмим», – ди торган иде. Бездән сорап тормадылар, ике елдан аны «Азат хатын»га баш редактор итеп билгеләп куйдылар. «Уйладым-

уйладым да, минем тәҗрибәм бүген монда кирәгрәк дигән фикергә килеп, ризалык бирдем», – дип аңлатты ул безгә бу гамәлен. Хатын-кызлар дөньясы да колач җәеп көтә булып чыкты үзен. Ә бераздан журнал Роза апа тырышлыгы белән «Сөембикә» исеме белән тарала башлады. Төрле яклап уйлап, редколлегия әгъзалары, аксакал язучылар белән киңәшеп, исем үзгәртү өчен Мәскәүләргә барып, Президент фатихасын алып, әнә шундый зур эшне башкарып чыкты: халкыбыз каршында җаваплы имтихан тотты Роза апа.

Фирая

Үзем белән иң күп аралашкан, күп тапкырлар бергә командировкаларга йөргән «Сөембикә» редакторы, әлбәттә, Фирая Бәдретдинова иде. Башта икебез дә пионерлар тормышы бүлегендә эшләдек әле. Ул – «Яшь ленинчы»да, мин – «Ялкын»да. Шунысы кызык: икебезне дә Роза апа Туфитуллова Мәскәүгә, ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршындагы Югары комсомол мәктәбенә укырга җибәрде (туры килүен әйт: Фирая – Роза апа газетадан китеп өлгергәнче, мин исә берничә ай үтеп, Роза апа безгә килгәч...) Без аның шәкертләре идек. Хәзер дә ул көннәрне редакторыбызга рәхмәтләр укып искә алабыз.

Мәскәү. Юность урамы. ВКШ. Кунакханәне хәтерләткән тулай торак вахтасында үзем урнашасы бүлмәне белешкәндә: «Сезне инде эзләп керделәр», – дип, серле елмая ачкыч бирүче хатын. Ә бераздан спорт киемнәреннән генә Фирая кочаклап та ала үземне. (Ул күрше тулай торакта яши иде.) «Менә бәхет! Син мондагы тормышымны бизәячәксең! Камал театрын сагынып, бер генә көнгә Казанга кайта идем. Синең белән Мәскәү театрларына йөрибез болай булгач!» – ди... Һәм Мәскәүне яуларга керешәбез. Фирая минем экскурсоводка әйләнә. Без яшәгән Юность урамы тирәсе атаклы граф Шереметевлар утары булган икән бит. Бер көнне шунда Петр патша чорлары турында фильм төшерүләрен күрдек. Озын буйлы актёр тезгә кадәр постау кафтаннан, паригының чәч бөтеркәләре өчпочмаклы киңкырлы эшләпә – треуголкасыннан чыгып тора, кюлот дигән кыска ыштан, ак гольфылар, аеллы туфлиләр... Менә ул, эре-эре атлап, безнең «Молодежная» кафесына сок эчәргә кереп китте. XVIII гасыр дворяны XX гасырга кереп чыкты дип көлештек. Әле Лужникида «Московские новости» газетасы призына узган фигуралы шуу турнирын тамаша кылабыз, әле Арбат буйлап йөрибез, әле Маяковский исемендәге театрда утырабыз. ВКШдагы киоскта һәрвакыт журналистларны кызыктырырлык, беркайдан да табып булмый торган китаплар сатыла кайчак. 12 яшьлек Америка кызы Саманта Смитның безнең илгә сәяхәте турындагы «Путешестие по Советскому Союзу» дигән китабына чират тезелде. Бер кулга икене генә бирәләр. Фирая белән икәүләп чиратта торабыз һәм үзебезгә, Роза Туфитуллловага, Фоат Хәмидуллинга (ул «Яшь ленинчы»да эшли, «Пионерская правда»ның үз хәбәрчесе иде) дип атап затлы китапны кулга төшерәбез. Безгә «Литературная газета», «Комсомольская правда», «Московский комсомолец» журналистлары лекцияләр укый, «Пионер», «Пионерская правда» редакцияләренә йөрибез. Ә Фирая «Пионерская правда»да стажировка уза. Кайтып китәр көннәр җиткәч, блокнотымда дилбегә буе сузылган заказлар исемлеген барлап, редакциядәгеләргә кайсына күлмәк, кайсына косметика, кайсына фотопленкалар, кемгәдер босоножкалар, «Красная Москва» хушбуйлары... сайлашып йөрүләре, сумкаларым шыплап тулып та, әйберләр һаман сыеп бетмәгәч, якындагы «Вешняки» универмагыннан юл сумкасы күтәреп кайтуларым, чемодан тотыру остасы дигән даны таралган Фираяның төргәкләрне җайлап, кыл узар ара да калдырмый сала барулары, «Татарстан» поездына утыртып, озатып калулары...

Еллар узгач, Роза Туфитуллова депутат булып киткәч, Фирая Бәдретдинованы «Сөембикә»нең баш редакторы итеп билгеләделәр. Тугызынчы катта, икебез ике редакциянең баш редакторлары булып күрше бүлмәләрдә эшләп утырган матур еллар. Бергәләп юл йөрүләр, командировкаларга барулар, журналистлар фестивальләрендә катнашулар... Ә Мәскәүгә барган саен, үзебез өчен кадерле урыннардан урап кайтмый калмыйбыз...

* * *

...Ә инде чынлап торып «Сөембикә»дә эшли башлавыма Ләйсән «гаепле», ул чакырып алды. Язучылар, журналистлар гаиләсендә туып, кечкенәдән иҗат тәмен һәм газапларын тоеп үскән, мәктәп елларында ук шигырьләр язып, балалар матбугатының «Яшь хәбәрчесе» булган, Казан университетының журналистика факультетын тәмамлаган, редакцияләрдә, матбугат үзәкләрендә тәҗрибә туплаган Ләйсән Юнысова «Сөембикә» журналының баш редакторы иде...

Һәр баш мөхәррирнең үз чоры, үз эш алымнары. Яшь редакторлар булып журналны җитәкләгән Ләйсән Юнысова, Гөлнара Сабирова, Лариса Маликова... Яшьләре белән миңа сеңел генә булсалар да, өзерлекләре белән апа кебек иде алар миңа. Ләйсәнне Гөлнара алыштырды һәм тиз арада үзен күрсәтеп, республиканың иң зур газетасы «Ватаным Татарстан»га баш мөхәррир булып китте. Хезмәт юлын «Сөембикә» редакциясендә башлап җибәргән Лариса инде бүгенге көнгә журналның баш мөхәррире булып өлгерде. Алар эшләгән еллар турында да сагынып сөйләрләр, онытылмас хатирәләрне барларлар. Монысы инде киләчәк журналистлары вәкаләте.

■ «Азат хатын» редакциясендә һәрчак затлы кунаклар була. Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Диләрә Зөбәерова, Мәдинә Маликова, Эльмира Әдиатуллина, Әлифә Сафина, Габдулла Шәрәфи, Венера Ихсанова, Мостай Кәрим, Кояш Тимбикова. 1980 нче еллар. Архив фотосы.
■ Роза Туфитуллова белән редакциядә. 2003 ел, июль. Марат Мөхәммәтҗанов фотосы.
■ Фирая Бәдретдинова белән Дагомыста, Бөтенроссия журналистлары фестивалендә. 2006 ел, сентябрь. Илдар Закиров фотосы.

СЕБЕРНЕҢ ЗӘҢГӘР КҮЗЕ





Алсу ШАКИРОВА

Күңелемә кереп калды ул минем. Ымсындырып калды… Берничә ай элек командировкага Бурятия Республикасы Улан-Удэ шәһәренә барырга туры килде. 4000 чакрымга якын араны узып, инде Байкалга кул сузымы гына диярлек – 200 километр гына калгач… Кавыша алмый калдык. «Борчылмагыз, әле сезоны түгел, Байкалны ике тапкыр күрергә кирәк – февраль һәм июль айларында», – диделәр Бурятиядә. Ярар, димәк, мин монда өч айдан әйләнеп кайтам, дип ниятләп куйдым…

Чынга ашкан хыял

Тә-ә-әк, җылы носкилар, маркетплейста заказ биреп алган олтыраклар, җылы тотучы эчке киемнәр чемоданга салынды. Иң мөһиме – туңмаска!

Менә без инде Казан–Иркутск очкычында һава диңгезен гизәбез. Байкалга барабыз бит! Бу юлы сине күрмичә кайтмыйм инде мин, Байкүл! Монысында Улан-Удэ ягыннан түгел, Байкалны икенче яктан колачлаучы Иркутск өлкәсенә юл тоттык. Шуны әйтергә кирәк, Байкалны күрергә теләүчеләр елдан-ел арта икән. Әле кайчан гына, шул исәптән, миңа да тормышка ашмаслык хыял булып тоелган Байкал бүген күпләрнең хәтер сандыгына иң матур хатирәләрнең берсе итеп салып куелган инде.

Вакыт аермасы биш сәгать, кызганыч, минем исәпкә түгел... Биш сәгатькә иртәрәк «яшисе» була бу сәяхәттә. Казаннан төнге унике тулганда очтык. Иркутск шәһәренә барып җиткәндә безне офыкта сызылып килүче таң каршылады.

Байкалны күрергә теләүче туристларга тукталыр өчен иң популяр урын – күлнең иң зур утравы Ольхон. Шунда – гаҗәеп күлнең нәкъ уртасында яшәргә дип хыялланган идек тә... Без билет алганчы бер генә кунакханәдә дә урын калмаган. Иркутскиның үзендә тукталмыйча чара калмады, ләкин бу борылыш без уйлаганнан да хәерлерәк булды! Иркутск шәһәрендә яшәп, өч көн дәвамында өч юнәлешкә сәяхәт итеп, шәһәр белән дә танышырга өлгердек. Аннары безнең татарда «керереңне уйлаганчы, чыгарыңны уйла» дигән әйтем бар. Без тукталган кунакханә аэропортка якын иде. Кире Казанга очканда бик уңайлы булды. Югыйсә аэропортка килеп җитәр өчен Ольхон утравыннан 300 чакрым тирәсе юл үтәргә кирәк булыр иде. Шәһәрдәге 9 баллык бөкеләрне дә өстәсәң...

Ярый, Иркутск шәһәренә килеп кенә төштек бит әле! Бер минут вакытны да әрәм итмәс өчен, һәр көннең маршрутын алдан төзеп, планлаштырып, гидлар белән сөйләшеп бардык. Шунысы кызык: өстәмә җылы киемнәр дә, олтыраклар да чемоданнан чыкмады. Байкал безне бик җылы һава торышы белән каршы алды.

Байкал кызы Ангара

Көндезге унбердә кунакханәдә чемоданнарны калдырып, Листвянка бистәсенә юл тотарга әзер идек. Листвянка – Иркутск шәһәреннән Байкалга иң якын урнашкан нокта. Арасы нибары 70 чакрым. Байкал белән беренче танышуыбыз нәкъ шуннан башланачак! Маршрут автобусына утырып барсаң, билет 200 сум тора. Ләкин ул очракта кире кайтуы да проблема булырга мөмкин, чөнки без Листвянкага барган көнне анда Май чабу бәйрәме уздырыла иде. Җирле халык та, туристлар да күп булачак. Шуңа күрә алты кешелек минивэн автобус ялларга хәл иттек.

Листвянка бистәсе тирәсендә элек-электән карагачлар үскән. Исеме дә шуннан килеп чыккан. Бу бистәгә туристлар Ангара елгасын күрер өчен килә. Байкалга агып керүче өч йөздән артык елга-инешләр арасында бердәнбер агып чыгучы елга ул. Аның легендасы да бик кызыклы, «Сөембикәчә» икән бит әле.

...Байкалның кызы Ангара Енисей исемле көчле, гайрәтле, зур елгага гашыйк була һәм аның янына качып китәргә тели. Байкал бу хакта белеп ала һәм Ангараны тотып калу өчен каршысына таш кыя ыргыта. Ләкин гашыйк йөрәкне бернинди киртәләр дә тыеп кала алмый. Ангара барыбер сөйгәне – дөньядагы иң озын һәм күп сулы елгаларның берсе – Енисей белән кавыша. Ангара Енисейны тулыландыра, ә Енисей аның көчле агымнарын тынычландыра, йомшарта. Икәүләшеп, йөзләрчә чакрымнар үтеп, Карск диңгезендә (Төньяк Боз океанының кырый диңгезе) ирек таба гашыйклар...

Ангара каршына ыргыткан ташны (аның очы гына чыгып тора) Шаманташ дип атыйлар. Табигатьнең бер хикмәтле урыны бу. Нык холыклы атаның эремәс туң йөрәгенә кызы үзенең йомшаклыгы белән юл салырга, ачуын юып төшерергә омтыла сыман. Байкал гына бирешми... Иркутск шәһәре буйлап агучы Ангара кышын да катмый. Салкын көннәрне пар чыгарып, елга тирәләрен бәскә күмә.

Листвянканың туристлар өчен тагын бер байлыгы – җирле базар! Байкалдан, гадәттә, күчтәнәчкә омуль балыгы алып кайталар. Кызыл китапка «кертелгән» балыкны ыслап та, тозлап та, турап та саталар. Базарда уңга карасаң да, сулга карасаң да шул омуль. Уртача зурлыктагы бер балык 250–300 сум тирәсе тора. Омуль балыгын алганчы аны ничек сайларга кирәген өйрәнегез. Омуль дип, еш кына башка балык саталар. Омульнең аскы канатлары үтә күренмәле диярлек, ак була. Канаты киселгән булса, димәк, сезне алдарга телиләр. Шуны әйтергә кирәк, Листвянкада омульнең иң тәмлесе, яңа гына әзерләнгәне сатыла. Туристлар күп йөрү сәбәпле, мондагы балык искерергә өлгерми, гел яңа әзерләнгәне белән тулыландырыла.

Листвянкага җитәрәк, ачык һавада урнашкан «Тальцы» этнографик му-



■ Боз булып каткан Байкал шушында шаулап торган Ангарага тоташа. Боз белән су кушыла.



■ Омуль балыгы – Байкалның визит карточкасы. Аны Кызыл китапка керткәннәр дигән сүзләр әллә дөрес, әллә юк, чөнки базарда бу балыкның күплегенә шаклар катасың.

PRESSA

зеена кереп чыгарга да җай булды. Әлеге музейда XVII–XX гасырлгы Байкал буе җирле халыкларының тормышкөнкүрешен чагылдыручы корылмалар, йортлар урнашкан. Экспонатларның күбесен Иркутск өлкәсе буенча табып, сүтеп алып килеп, монда төзегәннәр. Музейга билет бәясе – 250 сум.

Байкалның мин күрергә хыялланган, төрле чыганаклардан карап өйрәнгән метан күбекләре, ярылган бозы Листвянка яр буенда юк диярлек. Монда бозны кар каплаган. Боз күрер өчен квадроцикллар белән эчкә керергә кирәк. Һәм... шунда күргән матурлыктан кычкырып җибәрдек хәтта! Үтә күренмәле, карсыз бозга килеп җитүгә боз өстенә сибелдек, фотога төштек. Менә нинди икәнсең бит, Байкүлнең кабатланмас бозы! Ләкин иң матур бизәкле боз безне алдагы көннәрдә көткән икән...

Татарлар бит!

Сәяхәтнең икенче көне иң ерак юл белән истә калды. Ольхон утравына – 300 чакрым. Безнең вакыт белән төнге икедә йокыдан уяндык инде ул көнне. Дима исемле гид безне минивэн машинасына утыртып алып китте. Ашамлыклар кибетенә туктап, стаканнар, трубочкалар, сөт алып чыкты.

– Хәзер «бурханить» итәбез, шәһәрне генә чыгыйк, – диде Дима. Түземсезлек белән әлеге сүзнең асылын аңларга тырышып бардык. Иркутск өлкәсендә яшәүчеләр арасында шаманизм, буддизм дине таралган. «Бурханить» итү – юлга чыкканда, ниндидер эш башкарыр алдыннан изге рухларның күңелен күреп алу, аларга бүләк ясау дигәнне аңлата. Моның өчен юл буендагы изге урынга – бөркет сыны ясалган багана янына тукталдык. Багана тирәсенә, агач ботакларына догалар язылган яулыклар бәйләнгән.

Дима кибеттә алган сөтне стаканнарга салды: «Иясез бармакны шул сөткә манып, дүрт ягыңа чәчрәтеп чыгасың, стаканда калганын күккә чөеп җибәрәсең», – дип аңлатты. Диманың сөте безнең өскә төшәсенә әзер түгел идек. Ул үзе дә уңайсызланды. Шулай да, ак эчемлек чиста ул, киемгә берни булмый, дип тынычландырды. Аннары ул эшләгәнне без кабатладык. Булды, җирле кагыйдә буенча, бөтен җайлыйсы рухларны да көйләп бетердек, үзебезчә «бисмилләһ» белән мөһер сугып, юлга кузгалдык.

Ольхон утравына илтүче юл боз өстеннән салынган. Аны боз калын булып яткач кына, 10–15 февральдә генә ачалар. Бозның калынлыгы кыш азагына бер метрга җитә. Кайбер култыкларда ике метр тирәнлеккә кадәр ката. Бу юл буйлап Ольхон утравына бер ай гына йөреп була, аннары, куркынычсызлык кагыйдәләре буенча, ябалар.

Менә без дә Байкал өстеннән җилдерәбез. Кулда – телефон. Машина тизлеге белән күз алдыннан узып китүче матурлыкны, бозны төшереп калырга ашыгабыз. Нинди генә рәсемнәр ясамагансың, Байкүл! Юл ике якка да киң итеп полосаларга бүленгән. Урыны белән зәңгәр боз караңгы төскә керә. Бу урыннарда тирәнлек зур икәнен аңлап, куркыныч та булып китә. Байкал – җирдәге иң тирән күл. Аның тирәнлеге 1600 метрдан артып китә. Монда яшәүче халык «бөек, борынгы, чиксез, тирән, кабатланмас, изге» эпитетларын кулланып, юкка гына 636 чакрымга җәелгән Байкалны диңгез дип атамый, күрәсең...

Ольхон утравына барып җиткәнче, матур урыннарга тукталабыз. Аждаһа (дракон) койрыгы кыясына Байкалның дулкыннары бәрелеп, аның аскы өлешен бозга катырган. Су ярга бәрелеп чәчрәгән сыман катып калган. Калын боз катламыннан матур бизәкләр ясап, эшен төгәлләгәч кенә Байкал үзе дә боз астында йокыга талган.

Кыяның иң матур урынына басып фотога төшәр өчен чират торырга да туры килде. Икенче ягыннан, башка туристларга комачауламый гына төшеп китәргә уйлаган идек, аларга бу ошамады. Көтеп торуыбызны сорадылар. Безнең кулдагы Татарстан әләмен күргәч: «Үзебезнең татарлар икән әле!» – дип сөенеп куйдылар. Казаннар! Әнә шулай ике татар Аждаһа койрыгы астында урын бүлеп ятканбыз. Фотога төшәр өчен якташларга үзебезнең әләмне биреп торгач, барысы да җайланды.

Ольхон утравына барып җиткәндә көн кичкә авышкан иде. Ә безнең әле мондагы боз сыннары күргәзмәсен, Шаманка тавы янындагы Бурхан борынында (мыс) кояш баеганын күреп өлгерәсе бар. Алдан ук Байкалда булган туристларның видеоларын карап, үзебез өчен кызыклы идеяләр белән килгән идек. Шуларның берсе – күлдә ярымшар формасында ясалган чокыр-





■ Легенда буенча, Бурхан борынына Күкләр алласы Тенгри кешеләрне хөкем итәр өчен җиргә үзенең унөч улын җибәргән. Иң олы улы Хан Хутэ-Баабай шушы Бурхан борынында яшәп калган.

■ Аждаһа койрыгы кыясы – туристларның яраткан урыны.



дан чыгу. Шулкадәр шома була ул! Шуның эченә кереп бас та, чыгып кара! Үрмәләп тә, ятып та, шуышып та карыйсың, кире тәгәрәп төшеп китәсең. Мин алга-артка «разгон» ала-ала гына чыктым!

Шушы урында булса да кисәтим әле: Байкалга кайсы яктан керсәң дә, бәдрәф табуы җиңел түгел. Алар бөтенләй юк, дисәм, бәлки, табучылар булгандыр. Кысталып йөрмәс өчен экскурсия алдыннан ук хәстәрен күрегез.

Кояш баерга ярты сәгать кала, Бурхан борынына менеп киттек. Туристлар анда кояш баешында матур фотолар төшерергә, теләкләр теләргә әзер торалар. Бурхан борыны шаманистлар өчен изге дип санала. Аның башында 13 агач багана – сэргэ утыртылган.

Бик күп хис-кичерешләр белән кайтыр юлга чыкканда караңгы төшкән иде инде, ә безнең «Байкал белән үбешү» йоласын үтисе бар! Хыялыбызны тормышка ашырыр өчен, Дима, юл полосаларын чикләүче билгеләрне кисеп чыгып, кеше аягы басмаган чиста бозга алып китте. Туктауга, машинадан отверткалар алып килде. Ирләребез тиз генә бозда рюмка тирәнлеге чокырлар тиштеләр. Шул чокырга эчемлек салып, трубка ярдәмендә эчеп кую – Байкал белән «үбешү» дип атала. Караңгыга калдык дип борчылган идек, әйтәм бит, һәр эшнең хәерлесе була дип! Төнге Байкалны күрдек! Аның бозы тагын да серлерәк күренә икән! Юкка гына кайбер туристлар Байкалда палаткалар белән төн кунарга калмыйдыр...

Ничек сулыйсың, Байкал?

Байкалга терәлеп урнашкан Большое Голоустное бистәсенең бер үзенчәлекле ягы бар. Монда елның 300 көнендә кояш яктырта. Кырым диярсең! Бистәгә җиткәнче туристларны Зирәклек тавына (Ак тау дип тә атыйлар) алып менәләр. Анда Байкалның каршы як тавына искиткеч манзара ачыла.

Большое Голоустное бистәсенә Байкалның куыкларын күрергә киләләр. Иң чиста, иң гаҗәеп рәсемле боз күрү бәхете шушы көнгә калган икән! Байкалның сулыш алуын сирәк кешеләр генә ишетә, диләр. Ә безгә ул бәхет тә елмайды! Матур ярылгылар эзләп күлнең эченә кереп киттек. Бу юлы – алты кеше сыярлык «Хивус»ка утырып. Әлеге транспорт чарасы боз өстендә йөрер өчен ясалган. Һава мендәрендә җилдерүче бу амфибияләргә туристлар чират тора. Аны йөртүче ирләр – шушы бистәдә яшәүчеләр – бозның иң матур урыннарын белә. Монда дөньяны онытып, башны да күтәрмичә бозны өйрәнәсең, йотасың, исеңдә калдырырга тырышасың. Басып тору мөмкин түгел: үрмәләп йөрдек, ятып шуыштык, битне терәп боз астын күзәттек. Шул чакта «пух» итеп куйган тавышка як-ягыбызга каранып алдык. Беркем егылмаган, бер авыр әйбер дә төшеп китмәгән, хивус та шартламаган... Байкал сулышы бит бу! Сәяхәтебезгә матур нокта куелды.

Рәхмәт, Байкүл! Җылы каршы алуың өчен... Безнең белән сөйләшүең өчен... Иксез-чиксезлегең өчен... Көчең, рухың өчен!

Кызыклы фактлар

- Күлнең төбендәге кайбер тарлавыклар температура үзгәрү сәбәпле, йә кысыла, йә киңәя. Шуның нәтиҗәсендә кыш көне күлдәге боз ярыла. Байкалны сулый, диләр. Галимнәр аңлатуынча, көндез күл углекислый газны йота, кояш баеганнан соң кире чыгара. Шуңа күрә шаманнар да, кайбер галимнәр дә Байкалны исән, тере дип саныйлар.
- Төптәге термаль чыганаклар агышы бозга тулысынча катарга ирек бирми – боз ярыла.
- Нерпа – Байкалдагы бердәнбер имезүче хайван. Алар бары тик монда гына яшиләр. Бары тик байкал нерпасы гына йоклелек чорын туктатып торырга сәләтле хайван икән. Икенче кушылу чорына кадәр анабиоз кичергән эмбрион аннары яңасы белән бергә үсә һәм нерпаның ике баласы туа (гадәттә, нерпа бер генә бала китерә).
- Җирле кухня белән танышырга теләүчеләргә омульдән һәм башка балыклардан әзерләнгән төрле ризыкларны авыз итәргә тәкъдим итәм. Мәсәлән, без ат ите һәм омульдән ясалган позы ашадык. Позы (буузы) – бурят халык ризыгы. Безнең – мантый, грузиннарның хинкаленә охшаган.



Байкалга сәяхәткә җыенучылар өчен киңәшләр

- **Ачык, кычкырып торган төсләрдәге өске киемнәр киегез. Һичьюгы башлык, шарф булса да шундыйны сайлагыз. Бертөрлелек, соры таулар, ак кар фонында фотоларыгыз яктырак һәм күңеллерәк чыгачак.**
- **Әләм алып барсагыз, шулай ук бик матур фотолар ясарга була.**
- **Күзлек алырга онытмагыз! Кояштан, кардан күзләр бик нык чагыла.**
- **Экскурсияләрдә чәй эчеп җылыну өчен термос алсагыз уңайлырак.**
- **Салкында телефон тиз утыра, үзегез белән аккумулятор йә пауэр банк йөртегез.**





Байкал – дөньяда метан газының гидрат тупланмасы табылган бердәнбер төче сулы күл. Метан бүленеп чыгу сәбәпле, бозда төрле зурлыктагы куыклар барлыкка килә.



СОРАУ—ҖАВАП



Сорауларга Дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең «Казан эндокринология диспансеры» табиб-эндокринологы Екатерина ДЕВИЦКАЯ җавап бирә.

Күпләр хәзер диеталар белән мавыга, дөрес туклануга күчә. Мин дә бавырны чистарту буенча бер детокс программага керергә уйлыйм. Табиб белән киңәшләшмичә, анализлар бирмичә төрле детокс программалар үтәргә ярыймы?

Диеталар кыска вакытка гына нәтиҗә бирә. Озак вакытка нигезләнгән туклану тәртибен формалаштырырга кирәк. Туклану тормышның сыйфатына зур йогынты ясый бит. «Заманча яңа» ябыгу методикасын куллана башлар алдыннан белгеч киңәше кирәк.

Соңгы вакытта начар йоклап китәм. Башта төнге уникегә кадәр йоклый алмый ята идем, хәзер икегә кадәр боргаланып ятам. Бер ел шулай дәвам итә инде. Калкансыман бизнең эшләве белән бәйлеме бу? Йокы режимын ничек көйләргә?

Калкансыман биз патологияләренең, гормоннар җитмәүнең аерым күзгә бәрелеп торган билгеләре юк. Йокы кермәүнең сәбәпләре күп. Беренче чиратта йокы режимын көйләргә кирәк. Бер үк вакытта йокларга ятарга һәм уянырга гадәтләнегез. Хәтта ял көннәрендә дә шулай эшләгез. Кичке ун-унбердән дә калмыйча ятарга тырышыгыз, йокы алдыннан 2–3 сәгать телефон һәм башка гаджетлар кулланмагыз. Сигез сәгатьтән дә ким йокламагыз. Йокларга ятарга ике сәгать кала ашагыз. Кичке һавада йөреп керү дә файдага булыр. Әлеге киңәшләрне үтәгәннән соң да йокыгыз көйләнмәсә, эндокринологка мөрәҗәгать итегез.

Эндокринологка күренер алдыннан алдан ук анализлар тапшырып, УЗИ үтеп барырга кирәкме яисә табибның киңәшләрен көтәргәме? Аларны табиб барыбер билгели бит.

Эндокринолог пациентның нәрсәгә зарланганын тыңлап, тикшерү үткәреп, анамнез җыйгач, проблемаларына күрә диагностика һәм алдагы дәвалау өчен бөтен кирәкле анализларны билгеләячәк. Табиб киңәшләрен көтәргә, ул кушканча эшләргә кирәк.

Артык авырлыгым аркасында бер диетадан икенчесенә күчәргә туры килә. Хәзер бик күптөрле марафоннар тәкъдим итәләр. Ләкин алардан соң авырлык барыбер кире кайта. Аннары ул авырлыктан арыну тагын да катлаулырак. Мондый марафоннар белән мавыгу нәрсәсе белән куркыныч?

Кыска вакытлы марафоннар тәмамлану белән авырлык кире кайта, һәм тагын да күбрәк булып кайта әле ул. Ашауны кисәк чикләүнең, физиологик булмаган чикләүнең, ач торуның тискәре йогынтылары бар. Бөтен гаиләнең ашау культурасын булдыру, туклану кагыйдәләрен озак вакыт куллану мөһим. Ашауга гына түгел, физик күнегүләргә дә игътибар бирү зарур. Якыннарыгыз белән һавада йөрегез, бию, йөзү белән шөгыльләнегез. Тиз арада нәтиҗә күрер өчен андый марафоннарга кызыкмагыз. Дөрес туклану процессы рәхәтлек китерә торган булсын.

Кадерле укучылар!
«Сорау–җавап» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Үзегезнең һәм балаларыгызның сәламәтлегенә кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.

Фото: ru.freepik.com



Сорауларга Республика клиник туберкулезга каршы диспансерының баш табибы урынбасары, Татарстанның төп штаттан тыш балалар фтизиатры Рәмзия ФАТЫЙХОВА җавап бирә.

Ике балада да Диаскинтест уңай реакция күрсәтә. Бу ун еллап дәвам итә инде. Табиб өстәмә дәвалау курсы билгеләде, учетка бастырдылар. Гаиләдә авыручы кеше булса, бу вакыт эчендә ул кеше билгеле булмас идеме? Бәлки, минем балаларга гына хас ниндидер бер кичерә алмаучанлыктыр бу?

Бер гаиләдә берничә балада уңай Диаскинтест булса, бу латент туберкулез инфекциясе бар дигәнне аңлата. Йоктыру чыганагы да бер үк. Мөмкин кадәр күбрәк балаларга якын кешеләрне тикшертергә кирәк. Бер фатирда яшәүчеләрне генә түгел, туганнарны да. Йортка килеп йөрүче ярдәмчеләрдән, ремонт ясаучылардан йоккан очраклар да бар. Табиб барысын да дөрес эшли, зинһар өчен, аның киңәшләрен төгәл үтәгез.

Кызыбызга 3 яшь. Ел саен Манту ясатабыз. Ел саен нәтиҗәсе 2 миллиметрга зуррак. Педиатр Диаскинтест ясатырга кушты. Бу яшьтә баланы өстәмә травма белән җәфалап, ул тестны ясатуның кирәге бармы? Кечкенә балага каян йоксын ул туберкулез? БЦЖ йогынтысы да булырга мөмкин бит әле бу күрсәткечтә...

Әлбәттә, һәр очракны аерым карарга кирәк. Манту нәтиҗәләрен күреп, педиатр йогучанлыкны кисәтергә уйлагандыр. Диаскинтестның сиземлелеге бик югары, ул ялган уңай нәтиҗә бирми. БЦЖ вакцинасы Мантуга реакция бирсә дә, Диаскинтест организмда исән авыру тудыручы (живой возбудитель) турында мәгълүмат бирә.

Бала әле бик кечкенә, дисез... Кызганыч, әлеге чир бер яшьлек балага да йоккан очраклар бар. Шуңа күрә, сәламәтлек ягыннан тыюлар булмаса, прививканы да мөмкин кадәр иртәрәк ясатырга киңәш итәм.

Уңай Диаскинтесттан соң бик күп анализлар билгеләделәр. Шул исәптән, рентген ясатырга, томография узарга куштылар. Бу тикшеренүләрне башкасы белән алыштырып буламы? 5 яшьлек балага бу кадәр нурланыш зыянлы булмасмы?

Диаскинтест уңай реакция бирсә, баланың организмында авыруны кузгатучы бар дигән сүз. Табиб тагын бер сорауга җавап табарга тиеш: туберкулезның латент формасымы, актив формасымы бу? Беренче очракта «Кох» таякчыклары организмга эләккән, алар арта, ләкин әле бер органга да утырырга өлгермәгән дигән сүз. Организмда туберкулезның актив фазасы булса, сулыш органнары, үпкә зыян күрә башлый. Шулай ук бөерләр, сөякләргә дә йогынтысы булырга, хәтта туберкулез менингиты да булырга мөмкин. Авыруның нинди стадиядә булуын ачыклар өчен рентген-компьютер томографиясе үткәрелә. Аның альтернативасы юк. Бу очракта нурланышның йогынтысы акланган, чөнки тикшеренү авыруны вакытында табарга, кисәтергә, дәваларга ярдәм итә.

Манту һәм Диаскинтест уңай реакция күрсәтте. Рентген нәтиҗәләреннән күренгәнчә, баланың үпкәсе чиста. Химик дәвалаудан (таблеткалар эчүдән) баш тарту мөмкинме? Киләсе елга динамиканы күзәтеп карау яклы мин...

Диаскинтест уңай булып, снимок үпкәләрнең чиста булуын күрсәтсә, димәк, балада латент инфекция. Профилактик дәвалау, һичшиксез, кирәк! Әгәр дә дәваланмасагыз, туберкулез актив фазага күчәчәк. Организмга инфекцияне җиңәргә ярдәм итәргә кирәк. Шулай ук баланың янәшәсендә булган кешеләрне тикшерергә, йогышлы авыруның кемнән ияргәнен ачыкларга кирәк. Юридик яктан карасак, әти-әниләр дәвалаудан баш тартырга хокуклы. Әмма бу очракта баланың сәламәтлеге куркыныч астына куела. Сез бер ел көткән арада, авырту актив фазага күчәргә мөмкин. Тәҗрибәдә андый очраклар бар. Бер кызны шулай ел буе дәваламыйча көттеләр. Нәтиҗәдә, ул кыз туберкулезның ачык формасы белән авырый башлады. Инфекция берничә ел флюорография узмыйча йөргән әнисеннән күчкән.

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



СҮЗСЕЗ СӨЙЛӘШҮ

Сүзсез аралашу әңгәмәдәшләр сөйләшкәнче үк башлана. Игътибар итегез, сөйләшүләр алып бару өчен кешеләр башта уңайлы поза, әңгәмә өчен дистанция ала, бер-берсенә борыла. Шул ук вакытта ук гәүдә хәрәкәтләре телен аңлаучы әңгәмәдәшен «укый башлый». Шуңа күрә дә сүзсез, ягъни вербаль булмаган аралашу үтә дә мөһим, һәм уңайсыз хәлдә калмас өчен, аның кагыйдәләрен белү зарур. Сүзсез сөйләшүгә гәүдә тотышы, ишарә, мимика керә. Этикет һәм аралашу культурасы буенча тренер-консультант Марина ШӘМСЕТДИНОВАдан мастер-класс.



Эшлекле әңгәмә барышында дөрес гәүдә тотышы

Әңгәмәдәш турында иң беренче тәэсир берничә секунд эчендә формалаша. Шуңа күрә дә әңгәмә вакытында ачык булу мөһим. Үзебезнең кызыксынуыбызны күрсәтәбез. Гәүдә тотышында агрессия дә, кыюсызлык та чагылырга тиеш түгел. Басып торасыз икән, гәүдә төз булсын. Хатын-кыз үз гәүдәсенең сыгылмалылыгын ассызыкламый. Баш туры, ияк бераз гына күтәрелгән. Идәнгә, читкә карамагыз. Утыргансыз икән, аякны аякка кую да, терсәкләрне өстәлгә җәю дә дөрес булмас. Бигрәк тә аякларны селкетеп утыру әдәпсезлек. Кулларны күкрәккә кушыру, гомумән, гәүдәнең өске ягын капларга тырышу – «ябыклык» билгесе. Җилкә колакка таба күтәрелеп тормый, алга да чыкмаган. Әңгәмәдәш белән кул сузымы ераклыгында басып торасыз. Бу ара үзегезне куркынычсызлык халәтендә тотар өчен кирәк. Аралашу ышанычлы, дусларча мөнәсәбәттә булса гына әңгәмәдәшегезгә якынрак килергә мөмкин. Кулларны теләсә ничек болгау да – әдәпсезлек. Әңгәмә вакытында аяк киемегезнең очы әңгәмәдәшегезгә карап торса – аның белән кызыксыну билгесе. Әгәр дә ике кеше басып сөйләшеп торганда берсенең аягы читкәрәк чыгып тора икән, алар әңгәмәгә кемнеңдер килеп кушылуына риза. Ә инде аяк киемнәренең очлары бары бер-берсенә генә карап торса, һәм алар бер-берсенә таба бераз иелгән дә булсалар, бик мавыктыргыч сөйләшү алып баралар, аларга комачауламагыз.

Ишарәләр

Ишарәләр сөйләүчегә үз фикерен әңгәмәдәшенә җиткерергә ярдәм итә, әмма алар артык күп булу – әдәпсезлек билгесе. Эшлекле этикетта өстенлекле алырга теләгән ишарәләр урынсыз. Мәсәлән, кул биреп исәнләшкәндә учны ачып һәм өскә каратып сузасыз икән, бу сезнең өстенлекне алырга теләвегез турында сөйли. Кул горизонталь рәвештә сузылырга тиеш. Кулларның кесәдә булуы да килешеп бетми. Бигрәк тә куллар кесәдә килеш исәнләшү әдәпсезлек.
Бу – исәнләшкән кешегә карата хөрмәт күрсәтергә теләмәү турында яшерен ишарә. Эшлекле этикетта хатын-кызларның нәфислеген күрсәткән ишарәләр урынсыз. Эшлекле сөйләшүләр ул – профессионаллар мәйданы. Анда мин – хатын-кыз дигән фикерне ассызыкларга ярамый. Киресенчә, сексуаль ресурсларны кулланмыйча да куелган бурычларны хәл итәргә минем һөнәри компетенциям җитә дигән сигнал бирү кирәк. Шуңа күрә дә нәфислекне күрсәткән ишарәләрне кулланмагыз.

Мимика

Эчке тойгыларны, психик хәлне чагылдырып, бит мускулларының төрлечә хәрәкәтләнүе дә тәрбияле булырга тиеш. Мимика аша үзебезнең эмоциональ интеллектны чагылдырабыз. Аның белән идарә итә белмәүчеләр кайвакыт битлек кия. Мимика аша килешмәгәнлек эмоцияләрен күрсәтү эшлекле этикетта урынсыз. Әңгәмә вакытында баш кагып алу, ачык караш, җиңелчә генә елмаю мөһим. Иң кыйммәт елмаю сере, беләсезме, нәрсәдә? Һәрвакыт елмаеп тору түгел, ә сөйләшү барышында әңгәмәдәшегезгә игътибар белән караганнан соң, аңа елмаеп кую.

Хатын-кызга бервакытта да кулланырга ярамаган ишарәләр

Ишарәләрне кулланырга ярамый дигән кагыйдә юк. Бөтенесе дә мөмкин, әмма аның нәтиҗәсе нинди булачагын уйларга кирәк. Алдан әйткәнемчә, эшлекле этикетта «мин – хатын-кыз» дигән уен уйнаганда кулланган барлык ишарәләр компетентлы булмауны күрсәтә. Гәүдәнең сыгылмалылыгын күрсәтеп утыру, кыска итәк кию, итәкне тарткалап тору әдәпсезлек билгесе булып санала. Әңгәмәдәшеңә кагылып алу да урынсыз. Бигрәк тә аягына, кулына тиеп алу агрессив ишарә булып санала. Бармаклар, кул чугы белән уйнау, җилкәләрне сикертү дә килешми. Кыланчыклану эшлекле этикетта, гомумән, провокацион булып санала. Бу инде эшлекле сөйләшү алып барган кешенең профессиональ сыйфатлары бик түбән булуын күрсәтә.
Эшлекле сөйләшүләр вакытында әңгәмәдәшеңә бердәнбер кагылу – кул биреп күрешү.

КҮЗЛӘРНЕ АЧАБЫЗ

Төшеп торган күз кабакларын кисеп, күзләрне ачар өчен хәзерге заманда блефаропластика ясыйлар. «Пычак астына» керергә куркучылар өчен махсус массаж да бар. Дөрес, ул операцияне алыштыра алмый, әмма күпмедер күләмдә күз кабакларын күтәртә, күз тирәсендәге җыерчыкларны киметә, карашны ачыграк итә. Күз, маңгай тирәсендәге мускулларның киеренкелеген бетерә. Матурлык экспертыбыз Ләйсән САБИТОВА массаж күнегүләрен өйрәтә.



■ Иң элек бармаклар белән башны массажлап чыгабыз. Йомшак кына итеп чәчләрне төбеннән тартабыз. Шундук рәхәт булып китәр. Баш тиресе баш сөягенә ябышып торырга тиеш түгел.

■ Колак тирәсен массажлыйбыз. Аны төрлечә ясарга мөмкин, күнегүләрнең берсе – имән һәм урта бармаклар белән колак алдын һәм артын ышкыйбыз.

■ Дүрт бармак ярдәмендә астан өскә таба маңгайны массажлыйбыз.

■ Баш һәм имән бармаклар белән кашларны тотып, кыскалап чыгабыз.

■ Күз тирәсеннән алып чигәгә кадәр тирене вертикаль рәвештә чеметкәлибез.

■ Күз сөяге буенча имән бармак белән баскалап чыгабыз.

■ Күзнең эчке почмагындагы сөяккә баш бармакны куябыз да астан өскә йөртәбез.

■ Борын тирәсеннән күзнең эчке почмагына кадәр бармаклар белән басып, селкетеп чыгабыз.

■ Күз белән чигә арасындагы тирене бармаклар белән дерелдәтә-дерелдәтә өскә таба тарттырабыз.

■ Шул ук урындагы тирене бармаклар белән җыйдыртып, өскә таба алып барабыз. Һәр күнегүне 10–15 тапкыр эшлибез.

Бу күнегүләрне ясаганнан соң күз алларыгыз тагын да яктырып киткән кебек булыр. Көзгегә игътибар белән карасагыз, күз кабакларыгызның күтәрелүен күрерсез.

QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.





Тутырган каз муены

Борынгы рецепт белән пешерелгән бу ризыкны безгә Саба районы Иләбәр авылында яшәүче Рамил ХАФИЗОВ әзерләп күрсәтә. Элек аны әбисе Мөгаззәдә апа еш пешерә торган булган. «Күп кеше муен тиресен ашамый, ә менә болай әзерләсәң, ул бәйрәм сыена әверелә, – ди сәхифәбезнең кунагы. – Тутырмага охшаган бик тәмле кабымлык килеп чыга».

Рамил – ун елдан артык инде иләбәрлеләрнең мәдәни тормышы өчен җаваплы – Мәдәният йортын җитәкли ул. Җиденче сыйныфта укыганда беренче тапкыр спектакльдә катнашкан булган, шуннан бирле сәхнәдән төшкәне дә юк. Җыр-биюгә генә түгел, йорттагы бар эшкә кулы ята аның. Аш-суны да телеңне йотарлык итеп әзерли. Гаҗәпләнмәгез, һөнәре буенча, чыннан да, аш-су остасы ул. Ашчы булып берара – Казанда, аннары туган авылына кайтып, үзләренең «Көек» хуҗалыгы ашханәсендә эшләгән. «Күңелемә якын эш», – ди Рамил әлеге һөнәре турында. Былтыр Мөслимдә узган Бөтенроссия Каз өмәсендә шушы рецепт белән катнашып, аның беренче урынны яулаганын да беләбез.

Суыткычыгызда казның муены, бүтәкә-йөрәге әлегә кадәр сакланган булса, сез дә безгә кушылыгыз. Әлегә инде өлгермәсәгез, рецептны ерак алып куймагыз, көз күз ачып йомганчы килер дә җитәр ул.





Кирәк

2 муен / 8 бүтәкә / 8 йөрәк / казның эч мае / 3 баш суган, 3 тырнак сарымсак / 100–120 г дөге (бүрткәч, 300 г була) / төменчә тоз-борыч.

Камыр өчен ярты стакан су һәм он.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия

Эш барышы:



■ Бүтәкә, йөрәк, суган, сарымсакны иттарткычтан чыгарабыз. Бүтәкә майсыз булса, бераз гына казның эч маен да кушабыз. Иттарткычлар барлыкка килгәнче, борынгылар ит белән суганны махсус тәпке белән тапаганнар.



■ Кайнап торган тозлы суга салып дөгене бүртгерәбез. Әзер дөгене салкын су белән чайкатып, тарттырылган бүтәкә белән кушабыз. Тәменчә тоз белән борыч өстибез.



■ Муенны суыткычтан алып, башта яхшылап җебетәбез. Аннары муенның тиресен сул ягына кайтарып салдырабыз. Артык майларыннан, бизләрдән арындырабыз.



■ Энәгә нык җеп саплап, муенның аскы өлешен вак атлатып тегеп куябыз. Эчлек таралып китмәсен өчен кирәк бу. Пешкәч, ул җепне кисеп алачакбыз. Муенны уң ягына әйләндерәбез.



■ Әзер муен тиресенә эчлекне тыгызлап тутырабыз. Моны борыны киң бүрәнкә белән эшләве җайлырак. Андый бүрәнкә булмаса, кашык белән тутырырга була.



■ Тутырып бетергәч, муенның очын нык җеп белән бәйлибез.



■ Су белән оннан токмачныкы кебек камыр басабыз. Камырны ике өлешкә бүлеп, уклау белән җәябез. Зурлыгы бер муенны төрерлек булсын. Камыр урынына фольга да куллана аласыз.



■ Камырга төрелгән муен 180 градус кызулыктагы мичтә 1 сәгатьләп пешә. Пешкәч, камыр эченнән алып, чак кына суытабыз да, тәгәрмәчләп турап, тәлинкәгә матурлап тезәбез. Янына тозлы кыяр белән помидор куярга була.





Кузгалак – ашарга яраклы күпьеллык үсемлек. Яфракларының әчкелтем тәме калий тозлары һәм кузгалак кислотасы булу белән аңлатыла. 100 грамм кузгалакта С витаминының тәүлек нормасының 68,7 проценты, бета-каротинның – 50 проценты, К витаминының – 37,5 һәм лютеинның 15 проценты бар.
Әлеге үсемлек бор, магний, калий, никель, тимер, бакыр, йодка бай. Кузгалак мондый составы белән иммун һәм нерв системасы эшчәнлегенә уңай йогынты ясый.
Анда ризык җепселләре кандагы шикәр һәм холестерин күләмен киметергә булыша, бавырдагы токсиннарны чыгара, бөерләр эшчәнлеген яхшырта.

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА

Яз сые – кузгалак

Яшел борщ яки кузгалак ашы

Кирәк: сыер ите; 3 бәрәңге; 2 баш суган; 2 кишер; 150–200 г кузгалак; тәменчә тоз-борыч; бизәү өчен 3 йомырка; үзегез яраткан аш тәмләткеч үләннәр.

Эш барышы:

- Башта шулпа кайнатабыз. Бәрәңгене вак шакмаклап турап, әзер булганчы пешерәбез. Суган белән кишерне кыздырып, шулпага кушабыз. Тәменчә тоз, борыч өстибез.
- Кузгалакны турап, аш пешеп чыгарга 5 минут кала гына кушабыз. Ахырдан аз-азлап кына күпертелгән йомырканы агызабыз. Пешкән йомырканы тәлинкәгә генә дә сала аласыз.
- Аш әзер. Табынга чыгарганда яшел аш тәмләткеч үләннәр һәм каймак өстибез.

Кузгалак салаты

Бик тә файдалы һәм җиңел бу салатны әзерләр өчен тәлинкәгә яшь кузгалак яфракларын, шпинат, руккола салып, өстенә туралган ярты авокадо тезәбез, киндер яки чиа орлыгы сибеп, зәйтүн маен кушабыз. Үзегез яраткан башка төрле орлык һәм чикләвекләр дә куллана аласыз.

Соус

Үзенчәлекле соуслар ятратсагыз, кузгалактан песто әзерләп карый аласыз. Блендер савытына кузгалак, петрушка, зәйтүн мае, сарымсак, тоз-борыч, кырылган лимон кабыгы салып, куе соус хәленә килгәнче ваклыйбыз. Куерак булса, су өстибез.
Ашларыгыз тәмле булсын! Сәламәтлек телибез сезгә!



Кузгалакның яфрагы һәм орлыгы бөрештерү һәм сызлауны басу үзлегенә дә ия. Яфраклары яраларның тизрәк төзәлүенә ярдәм итә, ялкынсынуны баса. Әлеге үсемлекне борын-борыннан зәңгелә (цинга) авыруыннан дәва буларак кулланганнар.
Файдасы күп булса да, бәвел юлларында ком яки таш булганда, подагра, ревматоидлы артрит, кискен гастрит, холецистит белән авырганда, кузгалакны ашаудан тыелырга кирәк.
Кузгалакны әзерләгәндә беренче кагыйдә – аны озак пешерергә ярамый. Ризык пешеп чыгарга берничә минут кала гына кушсаң, андагы файдалы матдәләр таркалып өлгерми.
Искәрмә! Оеган сөт ризыклары кузгалак кислотасын нейтральләштерә. Сөттәге кальций кислотаның оксалатка әверелүенә юл куймый. Дөрес, шул рәвешле кальций үзе дә үзләштерелми.

тест: вакытыгызны дөрес бүлә беләсезме?

Вакыт җитми, дип зарланырга яратабыз. Вакытны җиткерер өчен, аны дөрес итеп бүлә белергә кирәк. Тәүлекнең сәгатьләрен дөрес файдаланасызмы икән, тикшереп карыйк әле.

1. Эшкә әзерләнү, планлаштыру өчен һәрвакыт алдан вакыт бүлеп куям.

2. Кайсы эшне тапшыра алам – шуларын да башкаларга тапшырам.

3. Үз алдыма куйган бурычларны һәм максатларны, аларны башкару өчен кирәк булган вакытны алдан ук кәгазьгә язып куям.

4. Һәр документны кулыма алу белән ахырына кадәр эшләп бетерергә һәм кабаттан бу эшкә әйләнеп кайтмаска тырышам.

5. Һәр көнне эшлисе эшләремнең планын төзеп куям, мөһим эшләрне иң беренче чиратта башкарам.

6. Эш сәгатьләремдә телефоннан кирәксезгә сөйләшмим, алдан планлаштырылмаган очрашуларга бармыйм, планлаштырылмаган җыелышларда катнашмаска тырышам.

7. Көндәлек вазыйфаларымны башкаруны үз көчемә карап бүләм, катлаулыларын көчем күп булган чакта башкарам.

8. Кинәт килеп чыккан мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә бүленү өчен, көндәлек эш графигымда һәрвакыт аерым вакыт каралган.

9. Үтә дә мөһим булган мәсьәләләргә беренче чиратта игътибар итәм.

10. Вакытымны сарыф итәргә тырышучыларга «юк» дип әйтә беләм.

Балларны саныйк. «Беркайчан да» дигән җавап өчен – 0 балл; «кайчагында» – 2; «һәрвакыт диярлек» дигән җавапка 3 балл языгыз.

0–15 балл. Сез вакытыгызны планлаштыра белмисез, башкалар ихтыярына буйсынасыз. Беренче чиратта торган эшләрегезне алдан планлаштырып, шул планны үтәсәгез, зуррак уңышка ирешә алыр идегез.

16–20. Үз вакытыгызга үзегез хуҗа булырга омтыласыз, ләкин сезгә эзлеклелек җитеп бетми.

21–25 балл. Вакытыгызны дөрес итеп бүлә һәм куллана беләсез.

26–30 балл. Вакытны дөрес итеп бүләргә менә кемнән өйрәнергә кирәк! Бу мәсьәләдә сездән үрнәк алырлык, бер минутны да бушка сарыф итмисез.

йолдызнамә май

Кучкар. Энергетикасы белән катлаулырак ай. Ай башында яңа эшләргә керешми торуыгыз хәерлерәк. Көтелмәгән очрашулар, сөйләшүләр күп булыр, яңа мөмкинлекләр ачылыр. Планнарыгыз турында артыгын чәчелмәгез.

Үгезбозау. Әлеге йолдызлыкта туучылар өчен май ае – еллык яңа цикл башланган чор. Көчегезнең артып китүен үзегез үк тоярсыз. Яңалыкка омтылышыгыз көчле. Сәләтегезне күрсәтер өчен яхшы форсат туар. Активрак булыгыз.

Игезәкләр. Күбрәк ял итү, көчләрне тулыландыру турында уйланыгыз. Эшегездә үзгәрешләр булуы ихтимал. Максатчан Игезәкләр алдында зур гына мөмкинлекләр ачылырга тора.

Кысла. Кызыклы һәм вакыйгаларга бай чор. Уңышка ирешәсе килү теләге, азарт бик көчле. Яңа танышлыклар булдыру өчен яхшы вакыт. Ләкин саграк булыгыз, дус санаганнарның капкынына эләгүегез бар.

Арыслан. Яңа проектта катнашырга, яңа һөнәри юнәлештә эшләргә туры килер. Үзегезне күрсәтү җае чыгар, тәкъдимнәрегезгә колак салачаклар. Шул ук вакытта эшегезгә аяк чалучылар да үзен сиздерер.

Сөмбелә. Күңелегезнең җете хисләргә, рәхәт тойгыларга, үзгәрешләргә омтылган мәле. Үзлегеңнән өйрәнү, күңел офыкларын киңәйтү өчен яхшы вакыт. Янтыгыздагылар да сезне нәкъ менә шушы юнәлештә эшләргә әтәрәчәк.

Бизмән. Кичектергесез эшләр һәм яңа проектлар белән мәшгуль булырсыз. Очрашуларга да бай вакыт. Финанс тотрыклылыгына бик өметләнергә туры килмәячәк. Файдалана алмый калган мөмкинлекләр үзен сиздерәчәк.

Чаян. Энергия күтәрелешенең иң биек ноктасында сез. Бәйсезлеккә омтылышыгыз аерата көчле, төрле килешүләр, вазыйфалар ирегегезне чикли кебек тоелачак. Шул ук вакытта хезмәттәшлек итү өчен бу – иң яхшы вакыт.

Укчы. Үзгәрешләргә бай чор. Алар бөтен өлкәдә – эштә, шәхси тормышта, уй-фикерләрдә чагыла. Керемнәрегезне арттырырга, җәмгыятьтәге дәрәҗәгезне үстерергә тулы мөмкинлекләр ачылырга тора.

Кәҗәмөгез. Май ае шәхси үсеш, казанышлар белән истәлекле булыр. Иҗатка, матурлыкка омтылырсыз. Тормышыгызны үзгәртәсе килер. Теләкләрегезне тыймагыз: уңыш сезнең якта, бар да сез уйлаганча булачак.

Сукояр. Арулар, талчыгулар үзен сиздерәчәк. Сәламәтлегегез белән шаярмагыз, үзегезгә күбрәк игътибар бирегез. Туганлыкны, дуслыкны ныгыту өчен яхшы мөмкинлекләр ачылыр. Гаилә белән бәйле күңелле үзгәреш көтелә.

Балыклар. Уңышлы ай. Яңа белем алу, яңа һөнәргә өйрәнү отышлы булачак. Эшлекле сыйфатларыгыз өстен чыгар. Көчену, эш алыштыру өчен кулай чор. Бу айда башлаган эшләр яхшы төгәлләнәчәк.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.



МӘХӘББӘТЕМ АҢА БУЛЫШСЫН!..

(*Ахыры. Башы 82 нче биттә.*)

2013 елны Кытайда узган бу конкурска Илгиз тагын да җитдирәк итеп әзерләнде, тагын да күбрәк дулкынланды. Тыштан сиздермәде, әлбәттә, әмма күреп торам: ул беренче урын алу турында гына хыяллана. Мин исә дулкынланмадым дисәм дә була – аның уңышка ирешәчәгенә шикләнми идем. Алкалар һәм йөзектән торган җыелмасын ул «Күбәләкләр» дип атады. Сюжеты табигатьтәге сирәк күренеш – кояш тотышына корылган. Эмальнең эңгер-меңгерне хәтерләткән төсмерен булдыра алды ул. Бу төсмер кояш тотылгандагы табигать халәтенә туры килде, һәм күбәләкләр дә, кояш яктысы күренү белән, очып китәрләр төсле иде...

Эмаль дигәннән. Илгизне ювелирлар арасында «эмаль короле» дип атыйлар. Кайнар эмальне зәркәнчеләр һәрвакыт кыйммәтле ташлар белән бер рәткә куя: ул алардан төсе, балкышы, матурлыгы белән һич калышмый. Гаять катлаулы эмаль ысулына исә Илгиз үзлегеннән өйрәнә. Аның иҗатында техник ысуллар бихисап һәм ул аларның барысына да үзлегеннән төшенгән. Эш коралларын Илгиз үзе ясаган. Бүген ул башка ювелирлар хыяллана да алмаганны эшли: эмаль белән алтынны бергә куша. Эмаль – 850 градуста, ә алтын 900 градуста гына эри башлый. Монда иң мөһиме: мизгелне тотып алу – алтын артык эресә берни дә килеп чыкмый. Төсләр белән дә шулай: билгеле бер төс эмальнең калынлыгына, мичтә күпме яну вакытына да бәйләнгән. Зәркәнчеләр гомер-гомергә кызыл һәм ал төстәге эмальләрне урап узган, хәтта мәшһүр ювелирлар да аны бик кулланмый. Кызыл эмальнең мичтә үз-үзен тотышы бары тик останың эчке тоемлавына гына бәйле. Монда барысын да секундлар хәл итә. Ә Илгиз шушы катлаулы кызыл төсне дә бик рәхәтләнеп куллана. Ул – чын виртуоз! Бу биеклеккә аны таланты, тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге күтәрде.

Кайнар эмаль ысулы белән ясалган бизәнү әйберләрен беренче тапкыр 1997 елда, Пуатьедагы Халыкара антиквар салонда французларга тәкъдим итә ул. «Эмальне әле генә куллана башладым, дисезме?» – дип шаккаталар. Француз журналы аның хезмәтләрен узган гасырда ясалган эшләр дип аңлап: «Күптән мәрхүм бер талантлы Россия ювелирының әсәрләреннән торган күргәзмә ачылды», дип язып чыга. Ялгышуларын аңлагач, кат-кат гафу үтенәләр...

Ә Кытайда узган ул күргәзмәдә Илгизнең «Күбәләкләр»е кабат җиңде! Бу юлы инде призны алып кайттык та киштәгә куйдык һәм... Илгиз башка конкурсларда катнашмаска карар кылды. 2014 елда Гохранның «Россия. XXI гасыр» ювелир сәнгате конкурсы өчен генә искәрмә ясады ул. Коллекциясе кабат Гран-прига лаек булды һәм ике ай буе Мәскәү Кремлендә, Россиянең Алмаз фондында экспозицияләнде. Бу – бөтен Россия күләмендәге зур уңыш иде!

2014 ел ахырында «Мәскәү Кремле музейлары» Илгизнең биш әсәрен сатып алды. Иң мөһиме: аңа Мәскәү Кремлендә – Успенская звонница бинасында күргәзмә ачарга тәкъдим иттеләр! Могҗиза кебек булды ул. Ниһаять күптәнге хыялым чынга ашты... «Мәскәү Кремле» дәүләт музей-тыюлыгының генераль директоры Елена Гагарина чит ил кунаклары белән очрашканда, бер ханым Россиядәге танылган ювелир белән күрешергә теләвен белдерә. Шуннан соң Елена Юрьевна Илгизнең остаханәсенә килде. Һәм иремнең иҗаты белән танышкач, шәхси күргәзмәсен ачарга үзе тәкъдим итте. Бу гади очраклылык түгел, ә Аллаһы Тәгаләнең безгә ярдәме иде... Күргәзмәгә әзерлек ике ел буе барды. Ул Илгизне яңа коллекция иҗат итәргә этәрде. Гомумән, аның иҗат юлы «шушы күргәзмәгә кадәр» һәм «күргәзмәдән соң»га бүленде. Илгиз моңарчы дөньядагы иң мөһим ювелир форумнарында катнашты: Гонконг, Лас-Вегас, Базель, Виченца, Токио, Париж, Женева, Монако... Ләкин бер генә күргәзмә проекты да аны Мәскәү Кремленеке кебек илһамландырмады. Бу иҗат дәртенең әле күп елларга сузылуын телим.

Кайчак аның куллары тудырган эшләргә карыйм да, инде моннан да матуррак, нәфисрәк, моннан да тәэсирлерәк бизәнү әйбере булмас дип уйлыйм. Күпмедер вакыт уза, һәм Илгиз миңа яңа эшен күрсәтә: тагын да ныграк шаккатам! Аңардагы фантазиянең, ул күргән, тойган матурлыкның, аңа килгән илһамның чиге юк икәнен аңлыйм... Бик күпләрнең – матурлык яратучыларның, сәнгать белгечләренең, зәркәнчеләрнең һәм коллекционерларның һушын алырдай ювелир эшләнмәләре инде бик күп булса да, ул үзенең иң матур әсәрен инде иҗат иттем дип санамый. Безгә аны күрергә язсын. Ул гаҗәеп эшне тудырырга мәхәббәтем көч бирсен!

Динә НАСЫЙРОВА сөйләгәннәрне
Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА язып алды.

«Аккош», брошь; «Кош», брошь;
«Кошлар», йөзек; «Император йөзеге»;
«Зәңгәрсу күбәләкләр», йөзек; «Күк капкалары», йөзек;
«Тавис кошы», муенса. «Альп коңгызы», муенса.
Фото: гаилә архивыннан










ИЛГИЗ ФАЗЫЛҖАНОВ

КАРШЫЛЫКЛАРЫ БАР. БЕЛГЕЧ КИНӘШЕ КИРӘК.



Косметология һәм трихология
медицина клиникасы

«Аль-Варис»



Күрсәткән хезмәтләребез:

✓ Косметология: аппаратлы косметология, лазер/фото терапия, лифтинг, инъекцион терапия.

✓ Трихология (чәчне дәвалау, аны профессиональ тәрбияләү).

✓ Тәнне тәрбияләү: төренү, LPG массаж.

Шулай ук Германиянең BABOR косметикасын да сатып алырга мөмкин.



Казан шәһәре, Сибгат Хәким ур., 41
тел. 8 (902) 719-77-99
www.al-varis.ru

Реклама

